ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ
БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ”

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНӘ ЗАМАН ТАЛӘБЕ

КАЗАН
2017

ББК 74.268.1Тат+74.268.3Тат
Т23

ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә бастырыла

**Проектның җитәкчеләре:**
Бәдриева Р. Р., ТРМҮИ ректоры, икътисад фәннәре канд.
Һадиуллин И. Г., Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты мәгариф идарәсе башлыгы, пед. фән. канд., доцент, ТР атказанган укытучысы

**Редактор:**
Шәмсетдинова Р. Р., ТРМҮИның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент, РФ Югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре

**Төзүчеләр:**
Шәмсетдинова Р. Р., ТРМҮИның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент, РФ Югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре
Зиннатуллин Р.К., Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты, ТР атказанган укытучысы
Фәттахова Р. Ф., ТРМҮИның доценты, филология фәннәре кандидаты
Гыйләҗева Л. Г., ТРМҮИның доценты, филология фәннәре кандидаты
Хадиева Г. В., ТРМҮИның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы

**Рецензентлар:**
Мөхәрлямова Г.Н., ТР ФА Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият институтының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты
Шакирова Г.М., ТРМҮИның татар теле һәм әдәбияты лабораториясе өлкән хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты

Татар теле һәм әдәбияты дәресләренә заман таләбе / төз.: Шәмсетдинова Р. Р. һәм башк. – Казан: ТРМҮИ, 2017. – 94 б.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр укыту-тәрбия эшенең барлык өлкәләренә яңача якын килүне, аны яңача аңлауны таләп итә, мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдына яңа мәсьәләләр, яңа бурычлар куя. Бу методик кулланма татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә заманча технологияләрне, интерактив алымнарны куллану тәҗрибәсенә нигезләнеп төзелгән.

© ТРМҮИ, 2017

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЗАМАНЧА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

***Шәмсетдинова Рәсимә Равил кызы,***
*ТР МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире;*
***Зиннәтуллин Раиф Кәримулла улы,***
*Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты*

Укыту-тәрбия системасын яңарту – яңа идеяләр, ысуллар, чаралар эзләү дигән сүз. Яңача белем бирү системасы укытучының эшчәнлегенә дә үзгәрешләр алып керде. Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандарты нигезендә милли кыйммәтләр, универсаль уку гамәлләре һәм бәяләү системасы формалаштыру тора. Укытуда, предмет нәтиҗәләре генә түгел, ә шәхси һәм метапредмет нәтиҗәләр дә булдырылырга тиеш. Укытучы укучыда универсаль уку гамәлләре формалаштырып, мәктәптә алган белем-күнекмәләрне укыту-тәрбия процессында гына түгел, ә реаль тормышта да кулланырга әзерли.

Һәр укытучы укытуның сыйфаты, укучыларның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе өчен җавап бирә. Хәзерге көндә әзер белем биреп чыгару уку процессының төп бурычы була алмаган кебек, укытуны да традицион формада оештырып кына заман таләпләренә җавап бирерлек укучылар әзерләп чыгара алмый. Яңа технологияләрне һәм алымнарны куллану укытучыдан да үз өстендә эшләвен, интелектуаль үсешен таләп итә.

“Инновация” (яңа, заманча) термины әдәбиятта XIX гасырдан алып кулланышта йөри. Аны, төрле халыкларның мәдәниятләре бер-берсенә йогынты ясый, хезмәттәшлек итә башлагач, америка галиме Джеймс У. Боткин тәкъдим иткән. “Инновация” терминын педагогик тәҗрибәдәге махсус эшләнгән яисә “очраклы рәвештә генә алынган” яңалык итеп кабул итәбез. Фәнни әдәбиятта “яңалык” һәм “инновация” төшенчәләре төрлечә аңлатыла. Яңалык ул – укыту процессына караган яңа чара (яңа метод, яңа методика, яңа технология һ.б.). әлеге чараны үзләштерү процессын инновация дип саныйлар.

Технология – (грек теленнән алынган сүз; сәнгать, осталык дигән мәгънәне белдерә) фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланыла торган методлар, алымнар, ысуллар җыелмасы ул. Педагогик технология исә белем бирү барышын, белемнәрне үзләштерү нәтиҗәләрен, төрле чараларны, ысулларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Әлеге гамәлләрнең төп бурычы – укыту процессына яңалыклар кертү, даими камилләштереп тору. Бу билгеләмәне АКШтагы Педагогик ассоциация һәм технологияләр берләшмәсе белгечләре бирә. Танылган педагог-галимнәр педагогик технологияне белем бирүнең иң уңышлы юлларын өйрәнә торган фән буларак та, педагогик процесста кулланыла торган ысуллар, чаралар системасы буларак та, белем бирү

процессы буларак та билгелиләр. Заман таләпләренә туры килә торган белем бирү, заманча дәрес түбәндәге максатларны күздә тотып оештырыла:

- өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уяту;
- танып-белү активлыгын үстерү;
- аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохите тудыру; укучыларның иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу;
- көндәшлеккә сәләтле укучы тәрбияләү.

Белем бирү технологияләре күптөрле. Кайбер галимнәр йөздән артык, ә кайберләре бүгенге көндә ике йөздән артык педагогик технология бар, дип исәпли. Аларның саны киләчәктә дә арта барачак, чөнки яңа педагогик технологияләр барлыкка килүнең берничә сәбәбе бар: баланың шәхси һәм психофизиологик үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнүгә игътибар арту, яңа федераль дәүләт белем стандартлары таләп иткәнчә, белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем бирү процессын системалы-эшчәнлекле юнәлештә оештыру; белем бирүдә уңай нәтиҗәләргә ирешүне гарантияли торган укыту процессын, укучы һәм укытучы эшчәнлеген проектлаштыруның зарурилыгы. Максаты, эчтәлеге, кулланылган ысуллары, алымнары һәм чараларның охшашлыгы буенча технологияләрне берничә зур төркемгә берләштерергә мөмкин. Мәсәлән:

- укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр;
- уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр;
- уку материалын методик яктан камилләштерүгә, дидактик яктан үзгәртүгә нигезләнгән педагогик технологияләр;
- халык педагогикасына нигезләнгән педагогик технологияләр Һ.б.

Соңгы елларда белем бирү системасында заманча технологияләр дип түбәндәгеләр билгеләнә:

1. Уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр;

- терәк схемалар кулланып, алга китеп (опережающая) укыту технологиясе;
- белем бирүнең компьютер технологияләре;
- үстерелешле укыту технологиясе;
- проектлар методы;
- концентрик белем бирү технологиясе.

2. Укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр:

- уен технологиясе;
- проблемалы укыту технологиясе;
- аралашуга өйрәтү технологиясе;
- критик фикерләү технологиясе.

3. Шәхескә юнәлтелгән технологияләр:

- Ш. А. Амонашвиллиның шәхескә хөрмәт белән карау технологиясе;
- Үзара хезмәттәшлек педагогикасы технологиясе.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә бу технологияләрнең һәрберсен кулланырга мөмкин. Гадәттә, заманча технологияләр дигәндә, беренче чиратта, соңгы елларда кулланышка кергән технологияләрне күз алдына китерәләр. Безнеңчә, 60-90 нчы елларда, хәтта XX гасыр урталарында барлыкка килгән педагогик технологияләрне дә заман мәктәбендә максаттан чыгып, уңышлы кулланырга мөмкин. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эшчәнлегендә иң актив кулланылган, уңышлы нәтиҗәләргә китергән берничә технологиягә тукталып китү урынлы булыр дип уйлыйбыз.

## Үстерешле укыту технологиясе

XIX йөзнең беренче яртысында чит ил педагоглары И.Г.Пестолоцци, А.Дистервег, рус галим-педагоглары К.Д.Ушинский, Л.С.Выготский тарафыннан үстерешле укыту технологиясенә нигез салына. Аның асылын укучыларның танып белү мөмкинлеген активлаштыру һәм үстерү тәшкил итә. Үстерешле белем бирү теориясе алга таба Л.В.Занков, Д.Б.Эльконин, В.В.Давыдов һ.б. педагогларның хезмәтләрендә үстерелә-камилләштерелә. Хәзерге вакытта үстерешле укыту буенча берничә технология гамәлдә кулланыла. Л.В.Занков технологиясе шәхесне төрле яклап үстерүне күздә тота, Д.Б.Эльконин – В.В.Давыдов технологиясе акыл эшчәнлеге үсешен алга куя. Иҗади үсеш технологиясенең төп шарты – психологик уңай халәт тудыру. Проблемалы-үстерешле белем бирү методларын эшләүгә М.И.Мәхмүтов зур өлеш кертте. Ул үз хезмәтләрендә укучыларның интеллектуаль мөмкинлекләре үсешендә бу методның нәтиҗәле булуын раслады.

Дәресне иҗади үсеш технологиясе нигезендә үткәрүнең иң мөһим шарты – уку эшчәнелен төркемнәрдә алып бару. Ә. Рәхимов фикеренчә: “Аралашуга бары тик балалар эшчәнлеген төркемнәрдә оештырып алып барганда гына ирешеп була.” Эшлекле аралаша белү – төркем арасында килеп туган каршылыкларны җиңәргә өйрәнү дигән сүз.

Һәр төркемдә лидер билгеләнә. Лидер – иҗади эшләүче көчле укучы Ул өй эшләрен тикшерә, иң уңышлы өй эшен тәкъдим итә, төркемдә җавап бирүчене билгели, һәр укучының җавап бирүенә ирешә. Бу укучыда җаваплылык һәм мөстәкыйльлек тәрбияли. Лидерларны чирек саен алмаштырып тору мөһим. Уку эшчәнлеген, укучыларны белемле-белемсезгә бүлмичә, төркемнәрдә оештыру белем-күнекмәләр формалаштыруның төп шарты булып тора. Төркемдә укучы башкалар сөйләгәнне тыңларга, килешмәскә, үз фикерен дәлилләргә, кызыклы фикер әйткән иптәшенә хөрмәт белән карарга өйрәнә. Бу үз чиратында укучыларның иҗади активлыгын арттыра. Иҗади фикерли белү исә - теләсә нинди җәмгыятьтә иң кыйммәт бәяләнүче сыйфат. Балада иҗади үсешне аны шәхес итеп караганда гына күреп була. Үстерелешле технология буенча укытканда, моның өчен

бөтен мөмкинлекләр дә бар. Бу технология баланың иҗади сәләтен үстерүгә юнәлтелгән. Иҗади үзүсеш формалашуны әлеге технология тарафдарлары биш стадиягә бүлә: 1) укучының танып белү эшчәнлеге; 2) иҗади үзбилгеләнүе; 3) үзидарә; 4) иҗади үзкамилләшү; 5) укучының иҗат итүе.Үстерелешле технологиягә нигезләнгән дәрес түбәндәге өлешләрдән тора:

I. Ориентлашу этабы (ул үзе өч өлештән тора):

1. Психологик уңай халәт тудыру.

2. Белемнәрне тигезләү.

3. УМ кую.

II. УМ адымлап чишү этабы. Һәр бирем саен укучылар үзләренә бәя дә куя баралар.

Модельләштерү УМ чишүнең бер адымы булып тора.

III. Рефлексия.

Өй эше өч дәрәҗәдә бирелә: 1) мәҗбүри;

2) ярымиҗади;

3) иҗади.

Профессор Ә.З.Рәхимов болай дип язган: “Иҗади үстерелешле технология өч китта тора. Шуларның беренчесе – төшенчәнең эчтәлеген һәм аңа билгеләмә бирү буенча эш итү ысулын гомумиләштерү, икенчесе – укучылар эшен төркемнәрдә оештыру, өченчесе – модельләштерү.”


Без алга таба шушы мөһим компонентларның берсе булган модельләштерүгә тукталып үтәбез. Модель төзү – иҗади эш. Аның аша укучылар төшенчәнең үзенчәлекләрен, төп билгеләрен һәм эчке бәйләнешләрен ачалар. Модель – укытучы һәм укучыларның бердәм уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә туа. Укучылар төрле символлар, билгеләр, график модельләр белән эш итәргә өйрәнәләр. Модельләштерү бигрәк тә теоретик материалны кыска бер фикер итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Мәсәлән:

6нчы сыйныф. Тема: Ясалышы ягыннан сүз төрләре (алдагы сйныфтагы үткәннәрне кабатлау).

Бирем. Ясалышы ягыннан сүз төрләре турындагы белемнәрне модельгә салырга. (Модельдә сүзләр урынына символлар кулланырга).

Сүзләрнең ясалышы.
(ясалыш ягыннан сүз төрләре)



кыскарт

Мәсәлән: “Аергыч һәм аның белдерелүе” темасын өйрәнгәндә, модель төзү һәм төшенчәгә билгеләмә бирү этабын күзәтик:

1нче бирем. Аергычның моделен төзергә.

Аергыч.

↓

Иярчен кисәк

↓

Исемне ачыклый

↓

Нинди? Кайсы? Кемнең? Ничәнче?

↓

Белдерелә:

↓ ↓ ↓ ↓

Сыйфат сан алмашлык исем (и.к.)

2нче бирем. Модельгә таянып билгеләмәсен чыгарырга.

Көтелгән җавап: исемне ачыклап, нинди? кайсы? кемнең? ничәнче? кебек сорауларның берсенә җавап бирә торган иярчен кисәк аергыч дип атала.

3нче бирем. Дәреслектәге кагыйдә белән чагыштырырга. Модельдә ни җитми?

Көтелгән җавап: аергыч ачыклап килгән сүзне аерылмыш диләр (модель тулыландырыла.)

Әдәбият дәресләрендә дә модельләштерү уңай нәтиҗә китерә ала.

5нче сыйныф. Г. Кутуйның “Сагыну” нәсерен өйрәнү һәм анализлау.

Чит ил һәм туган ил турында автор ниләр яза? Чит ил нинди? Туган ил нинди?

| Чит ил | Туган ил |
|---|---|
| Гөлләр матур<br>Чәчәкләре хуш исле<br>Елгалары шаулы<br>Коелары тирән<br>Таулары биек<br>Кызлары елмая<br>Чәчәк бүләк итәләр | Әреме шифалы<br>Елгалары шигъри, мөкатдәс<br>Чишмә суы татлы<br>Таулары мәһабәт<br>Күлләре сихри |
| Матур | Матуррак, илаһи матур |

Сагыну хисенең сәбәбен, дәрәҗәсен, юануны билгеләүдә дә модель ярдәм итә ала. Мәсәлән:

| Сагыну хисе | | |
|---|---|---|
| Дәрәҗәсе | Сәбәбе | Юану өлеше |
| Кабатлау: Сагындым, бик сагындым сине, туган ил! | Туган илдән аерылу | Кайтырмын, кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем. |

Әдәбият дәресләрендә әдипләрнең тормышын һәм иҗатын күзаллау өчен материал бирелә. Бу материал белән эшләгәндә дә модельләштерү эшен кулланып була. Укучылар текст белән эшләгәндә аңлап уку, анализлау (аеру) һәм шул ук вакытта берләштерү күнекмәләрен дә үстерәләр. Бу эшне югары

сыйныф укучылары бик тиз башкарып чыгалар. Укучылар түбәндәге тәртиптә эшлиләр:

| Тормыш юлы | Иҗат үзенчәлекләре |
|---|---|
| Туган елы, урыны.<br>Укыган уку йортлары.<br>Эш урыннары һәм һөнәрләре.<br>Вафат булган урыны һәм вакыты. | Иҗат юнәлеше.<br>Иҗат иткән жанрлары.<br>Иҗатында өстенлек иткән темалар.<br>Әсәрләренең исемнәре.<br>Мактаулы исемнәре, бүләкләре. |

Модельләштерү эшен башкарганда үзбәя бирү критерийларын әйтеп куярга кирәк.

Педагогик әдәбиятта галимнәр модельләштерүнең берничә функциясен аерып күрсәтәләр:

1. Дәрестә уку максатын кую өчен башкарылган фикерләү гамәлен күрсәтмәле чагылдыру.
2. Материал арасыннан иң мөһимнәрен аерып алуны җиңеләйтү.
3. Укучыларда үз эшчәнлекләренә рефлексиф анализ ясауга ярдәм итү.
4. Укыту процессына файдлы яңалык кертү.

Модельләр, схемалар белән даими эш итәргә өйрәткәндә, фәнни сөйләм кыскара, автоматлаша һәм фикергә әверелә. Тулы бер бүлекне кабатлаганда, белемнәрне системага салганда, нигез белемнәрен калкытканда, модельләштерү бигрәк тә отышлы.

Модельләштерү ике төрле формада оештырылырга мөмкин:

1. Өйрәнелә торган материалның эчтәлеге һәм эш итү ысуллары дәреснең барлык этапларында, кирәгенчә, класс тактасында һәм дәфтәрдә модельгә салынып барыла. Дәрес ахырында балалар белән бергә әзерләгән тулы модель әзер була. Ул укучыга өй эшен әзерләгәндә дә, киләчәктә белемнәрне искә төшергәндә дә терәк чара булачак. (Модель дәфтәрен булдырырга мөмкин).

2. Модельләштерү дәреснең аерым бер этабы булып кертелә. Бу очракта да төшенчәнең гомуми ысулы модельләштерелә.

Укытучы модельләштерү гамәлен оештырганда түбәндәгеләргә игътибар итәргә тиеш:

- Укытучы нинди ситуация аша укучыларны модельләштерү гамәлен башкаруга китерә?
- Модельләштерүне уку максатын чишүдә ничек куллана?
- Бу дәрестә график, символ, билге һәм хәрефләр рәвешендәге модельләштерү чараларының кайсылары кулланылды? Бер төрлесеме? Әллә төрле типлардыгылармы?
- Модельләштерү этабында хезмәттәшлекнең төркемләп, парлап, индивидуаль, фронталь формаларының кайсылары кулланылды ? Алар ни дәрәҗәдә максатка ирешү өчен ярдәм итте ?

- Модельләштерү процессы дәрестәге башка эш-гамәлләр белән ничек бәйләнгән?

Димәк, модельләр белән эш итәргә өйрәнгән укучы проблеманы җиңелрәк чишә, бер төрле ысулдан икенчесенә тизрәк күчә, иҗади яктан үсә, модельләштерү белем сыйфатын күтәрүгә, иҗади шәхес тәрбияләүгә зур йогынты ясый.

## Тәнкыйди фикерләү технологиясе

Бу технологиянең актуальлеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Белем бирүдә формализмнан һәм авторитар стильдән котылу;
2. Укучының иҗади потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру.

Максатлары:

1. Укучыларның интелектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү;
2. Мөстәкыйль фикерләүнең төрле типларын кулланышка кертү;
3. Укыту һәм танып-белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән күнекмәләр системасын булдыру һәм продуктив иҗат югарылыгына күтәрелергә ярдәм итү.

Бурычлары:

1. Укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек булдыру;
2. Укучыны креатив эшчәнлеккә тарту;
3. Белем бирү һәм тәрбия процессын оптимальләштерү һәм белем алуга уңай омтылыш булдыру.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора:

1. Өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту;
2. Төшенү (аңлау);
3. Рефлексия.

Кызыксыну уяту һәр дәрестә була. Бу өйрәнелә торган тема яки проблема буенча укучының элекке белемнәрен актуальләштерү, гомумиләштерү һәм актив эшчәнлеккә ныклы кызыксыну уяту өчен кирәк.

Төшенү этабында укучы үзе өйрәнә торган материал буенча яңа мәгълүмат ала, төшенчәләрне, фактларны аңлап, элегрәк алган белемнәренә бәйли, тулыландыра.

Рефлексия этабында укучы өйрәнелгәннәрне бербөтен итеп күзаллый, аңлап гомумиләштерә, яңа мәгълүматны тулысынча үзләштерә, иҗади фикер йөртә һәм өйрәнелә торган материалга карата аның шәхси мөнәсәбәте формалаша.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенең яңалыгы – аның ысулларында, ягъни иҗади шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыруында.

Татар теле, әдәбияты дәресләрендә кластер, синквейн, “алты эшләпә”, инсерт һәм “кәрзин”ысулларын кулланып була. Һәр дәреснең үзенчәлеге бар, шуңа бәйле рәвештә укытучы бу ысулларның иң отышлыларын сайлап ала. Мисал өчен инсерт ысулы, ул укучыга укыганны аңларга ярдәм итә һәм, гадәттә, дәреснең икенче этабында кулланыла. Бу ысулны икенче төрле “текстны тамгалау” дип тә атыйлар. Иң элек укучыларны текстны тамга кую

билгеләре белән таныштырып чыгаргы кирәк, чөнки аларга үзләре укый торган текстның кырыена (поляга) тамгалар куеп барырга туры киләчәк. Аларга аңлатма:

**“V”** тамгасын укучы тексттагы мәгълүмат белән күптәннән таныш булган очракта куя. Ул моны белә.

**“+”** тамгасын укучы үзенә таныш булмаган яңа мәгълүматны очратканда куеп бара.

**“-“** тамгасын укучы текстта очраган мәгълүматның үзе моңарчы беләм дип йөргән фикер белән туры килмәвен күргәч куя.

**“?”** тамгасы белән укучы таныш булмаган мәгълүматны билгели. Ул моны белергә теләвен күрсәтә.

Бу ысулны куллануның уңышлы ягы шунда, укучы текстны пассив укымый, ә белергә, аңларга теләп, игътибар белән укый. Бу ысулны татар теле дәресләрендә изложение, сочинение-фикерләмә язарга өйрәткәндә, имтиханнарга әзерләгәндә куллану да уңай нәтиҗәгә китерә.

Мисал.

6нчы сыйныф.

“Алмашлык төркемчәләре” темасын өйрәнгәндә бу ысулны кулланып була. Алдагы сыйныфларда һәм дәресләрдә өйрәнелгәннәрне искә төшергәннән соң, укучыларның, гадәттә, алмашлыкларның 2 төркемчәсе турында күзаллаулары барлыгы ачыклана: зат алмашлыклары, сорау алмашлыклары. Башкаларын белү өчен һәм шул ук вакытта алдагы дәресләр материалын өйрәнүгә юнәлеш бирү максатыннан укучыларга алмашлык төркемчәләре турындагы дәреслектәге кагыйдә инсерт ысулы белән укытыла. Сыйныф белән бу материал тикшерелә. Аннары шул тамгаларга таянып дүрт баганадан торган таблица тутырыла. Таблицага тексттагы мәгълүматлар кыскача гына язып куела. Алдагы дәресләрдә укучылар бу таблицаны тулыландырып баралар. Шулай итеп, укучының элек алган белемнәре өр-яңа мәгълүматлар белән тулыландырыла.

Әдәбият дәресләрендә шулай ук инсерт ысулын куллап була. Мәсәлән, әдипләрнең тормыш юллары һәм иҗатлары турында дәреслекләрдә белешмә бирелә. Кайбер әдипләр укучыларга башлангыч сыйныфлардан ук таныш, шуңа күрә мондый темаларны өйрәнү барышында инсерт ысулы бик уңай нәтиҗәгә китерә. Алтынчы сыйныфларда М. Җәлил иҗаты өйрәнелә, әлбәттә, герой-шагыйрь турында укучылар инде башлангыч сыйныфлардан ук беләләр. Дәреслектәге мәгълүматны укучылар тамгалар белән билгеләп баралар, схемага тутыралар һәм үзләре үк нәтиҗә ясый алалар. Инсерт ысулының тагын бер уңай ягы булып укучыларның үзләрендә булган белемнәрне башка укучыларныкы белән чагыштыру мөмкинлеге тора, аларда “Ни өчен кемдер бу мәгълүматны белә, ә миңа ул таныш түгел? Белемнәремне ничек арттырып була?” кебек сорау туарга җирлек була, шулай итеп, теманы өйрәнүнең мотивациясен арттыра. Шулай итеп, Инсерт ысулы текстны кат-кат анализларга, фикерләү күнекмәләрен үстерергә, иң катлаулы мәгълүматны да җиңел һәм яхшы итеп хәтердә калдырырга ярдәм итә.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенә караган “Кәрзин”, “Синквейн язу”, “Алты эшләпә”, кластер ысуллары укучыларны фикерне ялгыш әйтүдән курыкмаска, мөстәкыйль фикер йөртергә, аны дәлиләү күнекмәләренә өйрәтә. Тәнкыйди фикерләүне үстерә торган технологияләргә Блум таксономиясе керә. Аны Блум ромашкасы, Блум кубигы дип тә йөртәләр.

Блум таксономиясе ул – педагогик максатларны классификацияләү варианты. Таксономия 1956нчы елны Бенджамин Блум җитәкчелегендә бер төркем АКШ галимнәре тарафыннан тәкъдим ителә. Икенче төрле әйткәндә, Блум таксономиясе – белем бирүнең уңышлылыгын бәяләү методикасы. Уку максатының төп категорияләре түбәндәгечә билгеләнә; белем, аңлау, куллану, анализ, синтез, бәяләү. Блум таксономиясендә терәк фигыльләр:

Белем: ачыкла, билгелә, истә калдыр, яз, исемлек төзе. Бу дәрәҗәдә материал кабатлана, мәгълүмат бирелә. Укучы сөйли, күрсәтә, исемлек төзи белә, аерып ала.

Аңлау: аңлат, фикер алыш, формалаштыр, сурәтлә, кабатла. Аңлау дәрәҗәсендә материалның мәгънәсенә төшенә. Укучы сурәтли, билгеләрен ачыклый, башкача формалаштыра, аңлата.

Куллану: күрсәт, чагылдыр, интервью ал, бастырып чыгар. Охшаш ситуациядә куллана ала. Укучы төшенчәләрне яңа ситуациядә куллана, чишә, практик ситуациядә теорияне, законнарны файдалана.

Анализ: интерпретация, обзор ясa; аңлат, эзлән, сораулар бир, төзе. Бу дәрәҗәдә элементлар, структура ачыклана. Укучы анализ ясый, тикшерә, эксперимент үткәрә, оештыра, чагыштыра, үзенчәлекләрне билгели, аерымлыкларны таба.

Синтез: иҗат ит, булдыр, оештыр, прогноз ясa, төзе, тудыр, тәкъдим ит, уйлап тап. Бу дәрәҗәдә элементларны, структураны үзгәртә ала. Укучы төрле планнар төзи, тирәнтен тикшерә, камилләштерә, үстерә, төрле өлкәдәге мәгълүматны куллана, сочинениеләр яза, төрле экспериментлар үткәрә.

Бәяләү: нәтиҗә чыгар, йомгак ясa, бәялә, төзәт, прогноз ясa, чамала, редакцияләп чык. Бу дәрәҗәдә критерийларга нигезләнеп, чагыштырып бәя бирә. Укучы аргументлар китерә, үз фикерен яклый һәм дәлилли, исбатлый, прогноз ясый.

Әдәбият дәресләрендә текст белән эшләгәндә дә Блум таксономиясен нәтиҗәле кулланып була.

Үткән гасырның 80 нче елларында яңача эшләүче укытучылар арасында новаторлык хәрәкәте башланды. Алар педагогик җәмәгатьчелеккә үзләренең методик алымнарын, ысулларын, табышларын тәкъдим итә башладылар. Алар арасында Санкт-Петербургның 84 нче мәктәбендә белем бирүче рус теле һәм әдәбияты укытучысы И.Н. Ильин, Мәскәү шәһәре 587 нче мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучысы С.Н. Лысенкова, Башкортостан Республикасы Белорецк шәһәреннән математика укытучысы Р.Г. Хазанкин, Одесса шәһәренең 1 нче һөнәри белем училищесеның физика укытучысы Н.Н. Палтышев, шул ук шәһәрдән химия укытучысы Н.П. Гузик, Санкт-Петербургтан педагог Н.А. Зайцев, Грузиядән күренекле педагог, га-

лим Ш.А. Амонашвили, Краснодардан мәктәп директоры М.П. Щетинин, Донецкидан математика укытучысы В.Ф. Шаталов һ.б. бар. Бу укытучыларны, галимнәрне педагогик хезмәттәшлек технологиясе берләштерде. Бу технологиягә коллективта эшләү, коллектив хезмәттәшлек, үзара ярдәм, демократик стиль, иҗади атмосфера, актив эш формалары, үстерешле коммуникатив күнекмәләр, бер-береңә ихтирам хас. Укытучылар һәм укучылар – тигез хокуклы партнерлар. Татар мәктәпләрендә, татар сыйныфларында әдәбиятны укытканда Е.Н. Ильинның гуманистик караштагы укыту системасын куллану отышлы булыр иде. С.Н.Лысенкованың комментарийлы укытуга, ялгышларны алдан кисәтүгә, терәк схемалар кулланып эшләүгә нигезләнгән укыту алымнарын башлангыч сыйныфларда уңышлы кулланып була. Укыта торган сыйныфта үзара ярдәмләшү мохите тудыру, балага индивидуаль якын килү, белем ягыннан көчле укучыларның көчсезрәкләренә ярдәм итүе, өйрәнелә торган материалны бирүгә системалы якын килү – бу технологиянең төп нигезләмәләре. Татар теле дәресләрендә бу технологияне куллану телдә сөйләм эшчәнлегенең белем һәм күнекмәләрен үзләштерүне яңа дәрәҗәгә күтәрүне тәэмин итә.

Әлбәттә, кыска гына мәкаләдә барлык технологияләргә анализ ясау мөмкинлеге юк һәм без аны максат итеп куймадык та. Иң мөһиме: теге яки бу технологияне уйлап, ныклы рәвештә өйрәнеп, әзерләнеп куллана башларга, кыенлыклар туган очракта аннан баш тартмаска кирәк. Бары тик системалы эш алып барганда гына көтелгән нәтиҗәне күрергә, эшеңнән канәгатьлек алырга мөмкин.

ТР телләрне, гомумән, шул исәптән, татар теле һәм әдәбиятын укыту сыйфатын күтәрүгә, камилләштерүгә юнәлдерелгән эзләнүләр шактый актив алып барыла.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәгарифне үстерү институты рус телле балаларга татар телен укытуны камилләштерүгә юнәлдерелгән ике проект өстендә эшләде. Беренчесе – методик сертификация. Бу проект Валерия Николаевна Мещерякованың авторлык программасына нигезләнеп алып барылды, ул коммуникатив һәм уен технологияләренә нигезләнгән система булып тора. Бу проектта ТР ның Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләреннән куелган критерийларга җавап бирә алган 98 татар теле һәм әдәбияты укытучысы катнашты. Алар белән автор җитәкчелегендә өйрәтү характерындагы 34 семинар үткәрелде. Теоретик материалны өйрәнү белән беррәттән, технологияне гамәлгә ашыруның практик өлешенә дә зур игътибар бирелде. Проектта катнашучы укытучылар семинарларда балалар белән дәресләр уздырдылар, һәр укытучы видеодәрес күрсәтте һәм ул видеодәрес укытучылар, җитәкче тарафыннан анализланды. Материаллар проектның сайтына урнаштырыла барылды. Икенче проект – мәгълүматикоммуникатив технологияләргә нигезләнгән яңа буын «Сәлам» УМК төзүне оештыру, авторлар белән эш һәм укыту-методик комплектны Казан шәһәренең 7 мәктәбендә 10 татар теле һәм әдәбияты укытучысы 1нче сыйныфларда апробация уздыру булды. УМК уңышлы рәвештә сынау

үткәннән соң аның белән эшләргә теләүче укытучылар белән гамәли юнәлешкә корылган өйрәтү характерындагы семинарлар үткәрелде, түгәрәк өстәлләр оештырылды, мастер-класслар үткәрелде. Катнашкан укытучылар, укучылар, аларның ата-аналары проектларны уңай бәяләде. Укытучылар дәресләрне укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларны коммуникациягә чыгарырлык итеп оештыруга ирешә алдылар. Укучыларда төрле ситуацияләрдә аралаша алу, грамматикага караган материалны дөрес куллана белү күнекмәләре барлыкка килде, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре формалашты.

Гомумән алганда, соңгы елларда Татарстан республикасы белем бирү системасында уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик тезнологияләр уңышлы кулланыла.

Бу җыентыкта татар теле һәм әдәбиятыннан кайбер педагогик технологияләргә, проектларга нигезләнгән дәрес эшкәртмәләре һәм технологик карталарның үрнәкләре бирелде.

## В.Н. МЕЩЕРЯКОВА АВТОРЛЫК ПРОГРАММАСЫ НИГЕЗЕНДӘ УКЫТУ

***Абдулбариева Тулкунай Абдулкаһар кызы,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы*
*М.С.Устинова исемендәге 102 нче*
*гимназиянең беренче квалификация*
*категорияле татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы, тьютор*

В.Н. Мещерякова авторлык программасының төп максатларының берсе – мәктәптә татар телен предмет буларак өйрәнүгә карата киеренкелекне киметү, уңай булмаган фикер-мөнәсәбәтләрне юкка чыгару, йомшарту.

Икенче максат – рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү, сөйләмгә чыгару, икенче төрле әйткәндә, коммуникатив компетенцияләрне булдыру. Ул татар телен уку-укытуда хәл ителмәгән үзәк проблемаларның берсе – рус төркемнәрендә татар телен өйрәнүгә каралган сәгатьләр санының гамәли нәтиҗәләр белән туры килмәвенә бәйле. Чыннан да, татар телен өйрәнүгә 11 ел вакыт бирелә, сәгатьләр саны канәгатьләнерлек. Әмма 11 ел мәктәптә татар телен өйрәнгән рус телле яшьләрнең бик азы гына татарча сөйләшә-аңлаша аладыр. Тестларны уңышлы тапшырсалар да, сөйләм күнекмәләре шактый түбән дәрәҗәдә кала. Тырышлары, акыллылары татарча укый, сүзлек ярдәмендә тәрҗемә итә ала, диалог яки билгеле бер темага монолог төзи, ләкин араларында татарча һич кенә тартынмыйча иркен

сөйләшә торганнары күп түгел. Дәресләрдә сөйләм барьеры формалашканлыктан һәм сөйләм күнекмәләре тиешле дәрәҗәдә үстерелмәгәнлектән, татар телендә сөйләшү мөмкинлеге булган очракта да алар аннан файдаланмый. Тел өйрәнүдәге кыенлыклар укучыларның мотивациясен тагын да киметә, уңышсызлык ситуациясен китереп чыгара. Телнең грамматик нигезләрен өйрәнү, балаларның логик фикерләве калыплашкач, максатка ярашлы. Телне (сөйләмне түгел) никадәр генә яхшы белсәң дә, ул, даими рәвештә гамәли куллануга кертелмәсә, бер авыр йөккә әверелә.

Билгеле, сөйләм формалаштыруны күздә тоткан технологияләр аз түгел. Әмма ни сәбәпледер, нәтиҗәләргә күз салсак, бүгенге көндә алар бик аз санлы укытучылар тарафыннан даими, системалы рәвештә кулланылышка кертелә.

В.Н.Мещерякованың авторлык системасы дәресләрнең эчтәлеген дә, формасын да, оештыру рәвешен дә тулысынча, бөтен нечкәлекләрен исәпкә алып яктырта һәм алда әйтелгән мәсьәләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә. Без моңа үзебез шул система белән эшли башлагач төшендек. Беренчедән, татар теле дәресләре 1 нче сыйныф укучыларының иң яраткан, көтеп алган дәресләренә әверелде, моны эти-әниләр дә бик хуплады. Икенчедән, бер ел нәтиҗәләренә караганда, әлеге технология буенча эшләгән укытучыларның балалары дәрестә билгеле бер күләмдә татарча аңлый һәм аңлаша ала.

Система психологик киеренкелек тудырмыйча, димәк, тел барьерын булдырмыйча укыту мөмкинлеге концепциясенә корылган һәм эзлекле рәвештә тыңлап аңлау – сөйләү – уку – язу – тел анализы аша сөйләм күнекмәләрен үстерүне күздә тота. Монда балаларның яшь һәм психофизиологик үзенчәлекләре бик нык исәпкә алынган. Ул да булса:

1) тел өйрәнүдә табигыйлеккә таяну;
2) ишетеп аңлау (аудирование);
3) психологик рәхәтлек;
4) тел мохитенә чумдыру;
5) чит телне өйрәнүне баланың шәхси үсешенә, иҗади сәләтен ачуга юнәлтү.

Нәрсә ул табигыйлеккә таяну? Ул – балаларның 9-10 яшькә кадәр предметларны, төрле образларны инстинктив рәвештә кабул итү, истә калдыру сәләтенә таяну. Бала үз туган телендә кечкенәдән үк ничек сөйләшергә өйрәнсә, шул рәвешле чит телне дә отып ала. Балаларның баш миендә, үзләштерелергә тиешле калыпларны кабат-кабат тыңлау, ягъни аудирование аша, өйрәнелә торган телнең төп структурасы-образы тудырыла. Ни рәвешле? 9 яшькә хәтле сөйләм механизмы сыгылмалы, шуңа күрә табигый, ягъни кат-кат ишетү аша, тел образын тудыру юлын сайларга кирәк. Ятлату, мәҗбүр итү, бер телдән икенче телгә турыдан-туры тәрҗемә итүгә дә юл куелмый. Кечкенә баланы, мәҗбүр итмичә, ничек сөйләмгә чыгарырга? Әлбәттә, уен аша. Чөнки уен – бу яшьтәге баланың төп эшчәнлеге ул.

Дәрестә уңайлы, рәхәт атмосфера тудыру бик мөһим. Дәрескә балалар теләп йөрергә тиеш. Мин моны кайчандыр бер хыял итеп кенә күз алдыма китерә идем. Әмма ул чынга ашты. Балаларны мавыктыру кирәк. Дәрестә киеренкелек булмасын өчен, тоташ төрле-төрле уеннарны алыштырып торабыз, сөйләм тән, кул, йөз хәрәкәтләре белән бергә аралаштырып барыла. Төп дәрес тибы – ул сөйләм телен үстерү дәресе, ә төп дәрес формасы – уен. Ул уку дәресләре һәм кереш дәрес, контроль дәресләр белән аралашып барыла Уку дәресләрендә без җырлыйбыз, келәмгә түгәрәкләнеп утырып, лото, домино уйныйбыз; кереш дәрестә аудиодәрес тыңлыйбыз, кайбер уеннарны уйнап карыйбыз; контроль дәрестә укучылар эш дәфтәрендә эшли: рәсем ясыйлар, рәсемнәрне төрле буяуларга буйыйлар, бераз язалар. Эшләрне папкага җыеп, уку елы ахырында әти-әниләре белән бергә балалар китапчыклар тегә.

Укытучының ялгыш җавап биргән укучының хатасына мөнәсәбәт белдерүе дә без гадәтләнгәннән аерылып тора. "Юк, дөрес түгел, утыр," – дигән сүзләр юк.

Дәрестә берничә кагыйдәнең үтәлүе мәҗбүри. Беренче кагыйдә – татарча гына сөйләшү. 4 нче дәрестән башлап, укучылар өчен "рус теле ябыла". Баштагы 3-4 атнада укытучы әле рус теленә мөрәҗәгать итә, чөнки яңа уеннарның кагыйдәләрен аңлатырга кирәк була. Рус телен дәрестә куллану акрынлап кими бара һәм 2 нче чиректә без инде тулысынча татар теленә күчәбез. Әмма шәхси тәҗрибәм шуны күрсәтә: балалар бу таләпне укытучы үзе әлеге кагыйдәне бозмаган очракта гына үтиләр, ул рус теленә күчсә, алар да шул телдә аралаша башлыйлар. Димәк, кагыйдәгә укытучы да буйсына.

Уенны кем алып бара, шул аңа җитәкчелек итә. Мәсәлән, балалар "мәктәп-мәктәп" уенын ярата. Без аны бик еш, дәрес саен диярлек уйныйбыз. Монда укытучы укучы ролендә булып, укучы урынына барып утыра, ә бала укытучы урынына баса.

Тел мохитенә чумдыру ничек башкарыла? Беренчесе - ул татарча гына сөйләшү мәҗбүриятен тудыру. Уенда катнашу өчен татарча нindider сүз әйтү кирәк. Һәм дәрестә русча сөйләшмәү таләбе дә эшли. Ә ничек сүз мәгънәсен җиткерергә соң? Моның өчен без күрсәтмәлелеккә басым ясыйбыз. Ул - рәсемнәр, уенчыклар да, тән, кул, йөз хәрәкәтләре дә. Аңлашу өчен, тел образын тудыру өчен бик кирәкле аралашу элементлары. Шуңа күрә ниндидер сүзне яки структураны хәрәкәт белән күрсәтәбез. Сүз, предмет, төшенчәләрне күрсәтү уңайсыз булган очракта, рәсем яки уенчык кулланабыз.

Тел мохитенә чумдыру гаҗәеп нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек тудыра. Мәсәлән, укучыларның дәрес тәмамлангач, укытучылар белән саф татарча исәнләшүләре, укытучыга татарча мөрәҗәгать итүләре:

- Ә синең песиең бармы? - *Минем песием бар.*

- Ул нинди?- *Ул ак, матур, ул зур, ул яхшы.*

- Ә ул кайда? - *Ул өйдә.*

- Син песиеңне яратасыңмы? - *Әйе, бик-бик яратам!*

Менә шундый диалоглар, кара-каршы сөйләшүләр бик еш була.

Сөйләм телен үстерү курсында укучыларның шәхси үсеше өчен шартлар тудыруга да әһәмият бирелә. Балаларда уеннан укуга күчү активлыгын формалаштырыла. Алар курыкмыйча такта янына чыгарга, төркем белән идарә итәргә өйрәнәләр. Даими рәвештә төрле рольләргә кереп уйнау (мәсәлән, сатучы, кибетче, укытучы һ.б.) социальләшүгә, ягъни төрле җәмгыяви структураларга кереп, шәхеснең продуктив үсешенә йогынты ясый.

Дәвамчанык һәм материалның гел кабатланып торуы материалның горизонталь тематик планлаштыруында чагылыш таба. Телнең теләсә кайсы берәмлеге, сөйләм структурасы өч этаптан тора: ишетү, камилләштерү, ныгыту. Шул рәвешле, өйрәнгән материал кыска хәтердән озын хәтергә күчә, онытылып калмый.

Дәрес структурасы укучыларның эчке һәм тышкы активлыкларын саклануны күздә тотарга, ягъни һәр ике категория дә дәрестә үзләрен җайлы итеп хис итәргә тиеш булалар.

В.Н. Мещерякова системасындагы лексик берәмлекләр, сөйләм структуралары шулай итеп сайланган ки, алар көндәлек тормышта да һәм сөйләмдә дә иркен кулланырлык. Әйтик, без укучылар белән савыт-саба, ашамлык темаларын өйрәнгәндә, ашханәдә аралашканда:

“Кайда кашык? - *Менә, ал!”*

“Ипи бирегез, зинһар”! - *“Рәхмәт”*.

“Аш тәмлеме?- *Әйе, тәмле*!” кебек структураларны кулландык. Иң элек мин укучыларымны сөйләмгә, аннан соң инде инициативалы балаларны, ягъни “тел бистәләрен”, сөйләшүгә этәрдем. Монысы бигрәк тә кадерле.

## ЯШЕЛЧӘЛӘР. КИРӘК. КИРӘКМИ СҮЗЛӘРЕ

(1 нче сыйныф, рус төркеме)

***Галиева Зөлфия Шамил кызы,***
*Казан шәһәре Идел буе районы*
*52 нче гимназиянең югары*
*квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*“Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы”*
*Бөтенроссия конкурсы номинациясе*
*җиңүчесе, тьютор*

**Максат:** Яшелчә исемнәрен *кирәк, кирәкми* сүзләре белән сөйләмдә дөрес куллану күнекмәсен үстерү.

**Бурычлар:**

- игътибарлылыкны үстерү;
- сәхнәләштерә белү сәләтен үстерү;

- танып-белүне үстерүгә ярдәм итү;

- интонация, ишарәләрне аралашуда куллана белү күнекмәләрен үстерү.

**Тәрбияви максат:**

- дусларыңа итагатьле эндәшә, бергәләп уйный белү күнекмәләрен үстерү.

**Җиһазлау:** дәреслек, методик ярдәмлек, мультимедиа, яшелчә рәсемнәре, кәрзин, пиктограммалар, уенчыклар.

**Дәреснең тибы:** белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

**Метод һәм алымнар**: күрсәтмә әсбаплардан файдалану, чагыштыру, әңгәмә үткәрү, төркемләп ярыш оештыру, диалогик сөйләм төзү.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

- Исәнмесез, укучылар.

- Исәнмесез, Зөлфия Шамиловна.

- Хәлләрегез ничек?

- Яхшы, рәхмәт. Ә сезнең хәлләрегез ничек?

- Минем дә хәлләрем яхшы, бик яхшы, рәхмәт, укучылар. Татар теле дәресен башлыйбыз. Бүген мин дәрескә дустым Мырау белән килдем.

*(Мырау балалар белән исәнләшә һәм һәр бала белән таныша.* Мин – Мырау. Син кем?)

– Укучылар! Мырау пока шел к вам на урок проделал огромный путь. Хотите узнать, что с ним случилось? Тогда слушайте, а слушать будем, играя в "Повторюшки". Это такие гномики, у которых вот такие ушки. Они повторяют всё, что слышат. Поиграем с ними? Вы должны повторять только тогда, когда я приложу руку к уху. Договорились? Әйдәгез, басыгыз.

**Фонетик күнегү.** (*Слайдта чишмә, кошлар, бал кортлары, черки рәсемнәре һәм тавышлары)*

Мырау юлга чыга. Бара, бара, чишмә тавышын ишетә: [шшшш]

Кошлар сайрый: [чүт], [чүт], [чүт], [чүт].

Бал кортлары тавышы ишетелә: [җҗҗҗҗ].

Черкиләр оча: [без].

Алар Мырауны тешлиләр. Мырау елый: [әәәәәәә].

Әйдәгез, аларны куып җибәрик әле: [көөөөөөш].

Мырау сөенә: [һи-һи-һи].

**II. Уку мәсьәләсен кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

– Булды, укучылар, бик яхшы. Мырау, ә бу нәрсә? Бу кәрзин .Бу синең кәрзинеңме? Әйе, бу минем кәрзинем. Ә кәрзиндә нәрсә бар? *(Кәрзиндә кыяр, помидор, суган, кишер, бәрәңге)* Әйтмим. Белегез.

*(Укучылар пиктограммалардан файдаланып сорыйлар).*

– Ул кызылмы? Ул яшелме? Ул сарымы? Ул тәмлеме? (Әйе, ул ..... . Юк, ул .... түгел.*)Ул кыярмы? ?(*Әйе, ул ..... . Юк, ул .... түгел.)

*(Белгән әйберләрнең исемнәре бергәләп кабатлана.)*

– Әйдәгез, Мырауга рәхмәт әйтәбез.

– Рәхмәт, Мырау.

– Укучылар, ә болар нәрсәләр? *(Укучыларның кыска җавапларыннан соң, укытучы тулы җавапны кабатлый).*

– Яшелчәләр.

– Әйе, болар яшелчәләр. Димәк, без бүгенге дәрестә сезнең белән нәрсәләр турында сөйләшәбез? .... Әлбәттә, яшелчәләр турында сөйләшәбез.

**III. Беренчел ныгыту.**

– Ә яшелчәләр кайда үсә?

– Бакчада.

– Әйе, яшелчәләр бакчада үсә. Укучылар, ә монда бакча бармы? (*Укытучы зур катыргы күрсәтә*).

– Юк.

– Әйе, монда бакча юк. Әйдәгез, бакча ясыйбыз. Безгә яшелчәләр кирәк. Ә яшелчәләр кайда бар?

– Кибеттә.

– Әйе, яшелчәләр кибеттә бар. Әйдәгез, "Кибет-кибет" уйныйбыз. Бу - яшелчәләр кибете. Ә кибеттә нәрсәләр бар? *(Укучылар кибеттәге яшелчәләрне санап чыгалар)*

*(Укытучы кирәк, кирәкми сүзләренең мәгънәсен искә төшерә).* Помидор һәм суган рәсемнәрен ала, суган рәсемен балаларга күрсәтеп: "Миңа суган кирәкми", – ди һәм рәсемне өстәлгә куя. Помидор рәсемен күрсәтеп: "Миңа помидор кирәк", – ди һәм рәсемне үзендә калдыра. (*КИРӘК, КИРӘКМИ сүзләре тактага эленә)*

– Хәзер мин укытучы апа түгел, мин - сатучы. Әйдә, Артем, кибеткә кил!

– Исәнмесез.

– Исәнмесез.

– Сиңа нәрсә кирәк?

– Миңа .... кирәк. .... бирегез әле, зинһар.

– Мә сиңа .... .

– Рәхмәт. Сау булыгыз.

– Сау булыгыз.

– Хәзер мин сатучы түгел, мин укытучы апа. Кем сатучы була?

(*Сатучы ролендә дә балалар. Сатып алган яшелчәләрне катыргыга ябыштырып, "Бакча" аппликациясен төзиләр.)*

- Ооо, укучылар, карагыз әле, нинди матур бакча. Матурмы? Матур. Әйе, бакчабыз бик матур. Күп эшләдек. Ә хәзер нишлибез? Ашыйбызмы? Юк. Саныйбызмы? Юк. Уйныйбызмы? Әйе. Әйдәгез, уйныйбыз. *(Балалар парлап басалар. "Бу – мин, бу – син, бу – ул" уенын уйнау*)

*(Шакыган тавыш).*

– Бу кем? Бу – без. Без? Сез кем? Бу – без – куян һәм кәҗә. Балалар, әйдәгез, куян һәм кәҗәне чакырабыз. Куян, кәҗә, керегез. Исәнме, куян!

Исәнмесез! Исәнме, кәҗә! Исәнмесез. (*Укучылар белән дә исәнләшәләр)*. (*Кунаклар як-якка караналар)*. Бу нәрсә? Бу кабинет. Бу – безнең кабинетыбыз. Безнең кабинетыбызга рәхим итегез. О, бу сезнең кабинетыгыз. Кабинетыгыз зур, матур.

– Куян, кәҗә, әйдәгез, уйныйбыз. Юк, уйнамыйбыз. Әйдәгез, җырлыйбызмы? Әйдәгез, санныйбызмы? Юк та юк. Ә нишлибез? Әйдәгез, ашыйбызмы? Әйдәгез, ашыйбыз. Куян, кәҗә, менә бу безнең бакчабыз. Куян, сиңа нәрсә кирәк? Әйтмим, белегез. Куян, сиңа кабак кирәкме? Юк, миңа кабак кирәкми. Укучылар, әйдәгез сез сорагыз әле, куянга нәрсә кирәк? *(Балалар сорый.*) Куян, сиңа кишер кирәме? Әйе, миңа кишер кирәк. Мә, куян, кишер. ("Бакча" аппликациясеннән кишер алып бирәләр.) Куян, син начармы, яхшымы? Яхшы. Рәхмәт, әйт. Рәхмәт. (*Шул ук тәртиптә кәҗә белән дә эшлибез*). *(Мырау елый.*)

– Мырау, нәрсә булды? Ник елыйсың? Әйдә, уйныйбыз. Юк, уйнамыйм. Ә нәрсә эшлибез? Ашыйбыз! Укучылар, әйдәгез, сорыйбыз. Мырауга нәрсә кирәк икән? Әйдәгез, сорыйк әле. Мырау, сиңа шалкан *(кыяр, суган, бәрәңге) кирәкме?)* Юк, миңа шалкан (кыяр, суган, бәрәңге) кирәкми. Мин яшелчәләр яратмыйм.

– Укучылар, нишлибез, Мырау яшелчәләр яратмый. Ә минем сумкамда туңдырма бар. Укучылар, сорагыз әле, Мырауга туңдырма кирәкме? Мырау, туңдырма кирәкме? Әйе, кирәк. Мин туңдырма яратам, рәхмәт, укытучы апа, рәхмәт, балалар.

**IV. Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану һәм эзләп табу.**

– Булды, ашадык. Куян, кәҗә, ә хәзер нишлибез? Әйдәгез, уйныйбыз. Балалар, уйныйбызмы? Уйныйбыз. *(Ике яклы баскыч уены: куян, кәҗә.)*

– Карина, син хәзер кыз түгел! Син кәҗә. Артем, син дә кәҗә. Алена, ә син кем? Сез кәҗә булырсыз. Игорь, ә хәзер син малай түгел! Син куян. Маша, сез дә куян булырсыз. *( Балалар шул тәртиптә ике командага бүленә.)*

*(2 өстәл. Өстәлдә яшелчәләр, төрле төстә, төрле санда.)*

– Монда помидор бар, ә тегендә помидор бармы? Әйе, бар. Бу өстәлдә помидор бар, тегендә дә помидор бар. Аерма бармы? (*Уен)* Монда помидор кызыл, ә тегендә помидор яшел. Монда өч помидор, ә тегендә бер помидор. *(Шушы тәртиптә укучылар ике өстәлдәге яшелчәләрне чагыштыралар. Дөрес җавап биргән команда баскычтан күтәрелә. Беренче менеп җиткән команда - җиңүче.)*

**V. Рефлексия.**

– Укучылар, без бүген дәрестә яшелчәләр турында сөйләштекме?

– Әйе.

– Әйе, укучылар, без бүген дәрестә яшелчәләр турында сөйләштек. Без бүген дәрестә йокладыкмы?

– Юк.

– Дөрес, без бүген дәрестә йокламадык. Без бүген дәрестә "Кибет-кибет" уйнадыкмы?

– Әйе.

– Без бүген дәрестә бакча ясадыкмы?

– Әйе. ....

– Дәрес бетте, укучылар. Әйдәгез, дәрес өчен рәхмәт әйтәбез. Матур итеп басабыз. (*Ишарәләр белән*) Рәхмәт миңа! Рәхмәт сиңа! Рәхмәт барыбызга да!

Сау булыгыз, балалар.

## БОЕРЫК ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ӘЙТЕЛЕШЕ ҺӘМ АНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

(1 нче сыйныф, рус төркеме)

***Бикмөхәмәтова Ләйлә Зөлфәт кызы,***
*Казан шәһәре Идел буе районы 6 нчы гимназиянең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Дәреснең максаты:**

***Белем бирү:*** боерык фигыльләрне өйрәтү.

***Үстерелешле уку гамәлләре:*** укучыларга боерык фигыльләрнең әйтелеш белән эш-хәрәкәтен күрсәтү.

***Тәрбияви:*** балаларның сөйләмен көнкүрешкә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:*** уку материалына кызыксыну уяту; уку эшчәнлеген мотивлаштыру; күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасын күрсәтү.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

- ***танып-белү УУГ:*** бирелгән структураларны әйтә белү; тема кысаларында билгеләрне аерып күрсәтү; предмет һәм күренешләрне билге һәм символлар белән билгеләү; предмет һәм күренешләр арасындагы логик бәйләнешне билгеләү, аларны билге, ишарә аша күрсәтү; предметларны, чагыштыру, аермалы якларын билгели белү;

- ***коммуникатив УУГ:*** уку һәм танып-белү процессында позитив мөнәсәбәтләр булдыру; дәрестә актив катнашу; фикереңне дөрес әйтә белү; парларда эшләү;

- ***регулятив УУГ***: алган белемнәрне истә тотып, күнегүләр башкару; эш этапларын истә тотып, аларга ияреп, парлап эшләү; активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.

***Предмет нәтиҗәләре:*** сүзләрнең төшеп калган хәрефләрен дөрес урнаштыру; боерык фигыльләрне дөрес куллану; үткән лексикаларны кабатлату; тартымнарны актив кулланылышка кертү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне өйрәнү.

**Укыту формалары**: фронталь эш, төркемнәрдә эш, парларда эш.

**Предметара бәйләнеш:** музыка, математика.

**Җиһазлау:** пиктограммалар, рәсемнәр, уенчыклар, мультимедиа проекторы, ноутбук, таратма материаллар.

## Дәреснең технологик картасы

| Дәрес этаплары | Укучы эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге | Укыту һәм үстерү технологиясе. Дәрескә материал. | УУГ формалаштыру |
|---|---|---|---|---|
| **Оештыру моменты**<br>*Максат:* укучыларда психологик рәхәтлек тудыру; укучыларны уку хезмәтенә хәзер-ләү; исәнләшү. | Укытучы белән исәнләшү.<br>Укытучының хәлләрен сорашу. | Укучыларны тел мохитенә чумдыру.<br>Укучылар белән исәнләшү.<br>Укучыларның хәлләрен сорашу.<br>Дәресне башлау. | - Исәнмесез, балалар!<br>- Исәнмесез, укытучы апа!<br>- Сезнең хәлләрегез ничек?<br>- Яхшы, рәхмәт. Ә сезнең хәлләрегез ничек?<br>- Рәхмәт. Минем дә хәлләрем яхшы. Татар теле дәресен башлыйбыз.<br>- Менә ачкыч, рус телен ябабыз. | **КУУГ:** уку һәм танып-белү процессында позитив мөнәсәбәтләр булдыру. |
| **Актуальләштерү**<br>*Максат:* Үткән белемнәрне искәртү | Укучыларның сорауларга җавап бирүе.<br>Саннарны искә төшерү.<br>Гаилә әгъзаларын искәртү.<br>“Ә” һәм “Е” хәрефләрен кабатлау. | Укучыларның игътибарын туплау.<br>Фронталь эш алып бару. | - Безнең кабинетыбыз нинди?<br>- Безнең кабинетыбызда песи бармы?<br>- Ә сезнең өегездә песи бармы?<br>- Аның исеме ничек?<br>- Ә хәзер монда карагыз, бу гаилә.<br>- Гаиләдә ничә кеше, әйдәгез саныйбыз.<br>- Алар сигез.<br>- Менә әни, менә әти, менә апа ....<br>- Ә хәзер тактага карагыз, монда сүзләр. Ә болар нинди сүзләр, мин белмим.<br>(*Тактада:т..р...з..., ...ни, с..ң...л, д...фт...р, гаил...).*<br>- Ә хәрефе кайда бар? (төшеп калган хәрефләрне куябыз). | **Танып-белү УУГ:** бирелгән структураларны әйтә белү.<br>**РУУГ:** алган белемнәрне истә тотып, күнегүләр башкару.<br>**КУУГ**: укытучы һәм сыйныфташларыңны тыңлый белү, дәрестә актив катнашу. |
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү**<br>*1) Максат:* дәрестә яңа мәгълүмат үзләштерергә әзерләнү. | Укучылар пиктограммаларга карап боерык фигыльләрне үтәргә тиеш;<br>Мин бүре, син кем? конструкциясен куллана белергә тиеш. | Проблемалы ситуациядән чыгу юлын күрсәтергә тиеш. | - “Генерал” уены. Боерык фигыльләр: ела, йокла, алай итмә, шулай ит. Генерал һәм солдат чыга, генерал солдатка пиктограммалар ярдәме белән төрле хәрәкәтләр әйтә.<br>-“Куян-бүре” уены. Укучыларга рәсемнәр таратыла, бүре рәсеме булган укучы һәр бала янына килеп: “Мин бүре, син кем?”,- дип сорап чыга һәм куянны тапкач, аны тотарга тиеш. | **Танып-белү УУГ:** тема кысаларында билгеләрне аерып күрсәтү.<br>**РУУГ:** максатка ирешү юлларын билгеләү.<br>**КУУГ**: уку һәм танып-белү процес-сында позитив мөнә-сәбәтләр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | булдыру. |
| 2)*Максат:* Яңа лексика белән таныштыру. | Укучылар, белгән сүзләрне кулланып, сораулар бирергә тиеш.<br>Укучылар яңа сүзләрнең кулланылышын аңларга тиеш. “Дус” сүзенең эчтәлегенә төшенергә тиеш. | Укытучы яңа кунак белән таныштыра, яңа лексик сүзләр кертә. | - Ишектә кем бар? Әйдәгез, сорыйбыз, син кем?<br>- Әйтмим, белегез.<br>- Син куянмы, син төлкеме, син песиме...?<br>- Әйт әле, зинһар, син кем?<br>- Мин бака.<br>- Бака кер монда.<br>- Бу сезнең кабинетыгызмы?<br>- Әйе, бу безнең кабинетыбыз.<br>- Кабинетыбызга рәхим ит!<br>- Рәхмәт! Гафу итегез, сезнең исемегез ничек?(*исемнәрне һәр баладан сорап чыга)*<br>- Әйдә хәзер дус булабыз.<br>- Миша, син кем белән дус?<br>- Мин Олег белән дус. | **Танып-белү УУГ**: предмет һәм күренешләрне билге һәм символлар белән билгеләү; предмет һәм күренешләр арасындагы логик бәйләнешне билгеләү, аларны билге, ишарә аша күрсәтү. |
| 3)*Максат:* Гаилә әгъзалары белән таныштыру, минем тартымын дөрес куллану. | Укучылар “минем” тартымын дөрес куллана белергә тиеш. | Укытучы “синең” тартымы белән таныштыра.<br>Яңа лексик сүзләр кертә. | - Бака, синең гаиләң бармы?<br>- Әйтмим, белегез!<br>- Синең әниең бармы?<br>- Әйе, минем әнием бар!<br>- Синең әтиең бармы?<br>- Әйе, минем әтием бар!*(Шул рәвешле калган кешеләр турында сорашабыз)*<br>- Ә хәзер әйдәгез җырлыйбыз! | **РУУГ:** эш этапларын истә тотып, нәтиҗәле эшләү.<br>**КУУГ**: фикереңне дөрес әйтә белү. |
| *Максат:* Ял итү (*Хәрәкәтләр ярдәмендә җырлыйбыз).* | | | Минем әтием бар. Минем әнием бар.<br>Минем апам юк. Минем абыем бар.<br>Минем энем юк. Минем сеңелем бар.<br>- Ә хәзер уйныйбыз: “Сез миңа әйтегез”.<br>- Кемнең кулы чиста? (*Бу сүзләр үзенә туры килә, дип санаган укучы “минем кулым чиста” дип әйтсә, урыннан торып, тиз генә башка укучы урынына утырырга тиеш. Урынсыз калган укучы алып баручы була. Шушы үрнәктә уйныйбыз).* | **КУУГ:** күршең белән хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ**: активлык кебек сәләтләр формалашу. |
| *4) Максат:* Укучыларга | Укучылар “яратам” һәм “яратмыйм” | Укытучы “яратам” һәм “яратмыйм” | - Ә хәзер нәрсә эшлибез? Уйныйбызмы?<br>- Юк, уйнамыйбыз. | **КУУГ**: тыңлый белү; диалог төзүдә һәм кол- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| “яратам” һәм “яратмыйм” сүзенең әһәмиятенә төшендерү. | сүзләрен йөрәк һәм квадрат пиктограммалары аша аңларга тиеш.<br>Җылы-салкын сүзләренең аермасына төшенү;<br>Җыр: Бака,бака,ба-ка-ка, Бака җылы ярата. | сүзләрен йөрәк һәм квадрат пиктограммалары аша төшендерергә тиеш.<br>Монда, тегендә структурасын кабатлату. Җылы-салкын сүзләренең аермасына төшендерү. Җыр өйрәнү: Бака, бака, ба-ка-ка, Бака җылы ярата. | - Җырлыйбызмы?<br>- Юк, җырламыйбыз.<br>- Йоклыйбызмы?<br>- Юк, йокламыйбыз.<br>- Сезнең ашыйсыгыз киләме?<br>- Безнең ашыйсыбыз килә.<br>- Әйе. Минем эчәсем килә.<br>- Әйдәгез, буфетка. Буфет ачыкмы, ябыкмы?<br>- Ачык.<br>- Син аш яратасыңмы?<br>- Әйе, мин аш яратам.<br>-Ул аш ярата. (*Укучылар ашамлыкларны ике тартманың берсенә куярга тиеш*)<br>- Ә син, Илдус, туңдырма яратасыңмы?<br>- Юк, туңдырма яратмыйм. Ул салкын. Мин җылы яратам.<br>- Ә монда җылымы? Юк монда салкын, ә кайда җылы?<br>-Тегендә җылы, батареядә. (*Баканы батарея өстенә куябыз)*<br>- Ай, рәхмәт. Мин җылы яратам. Җыр җырлыйбыз: Бака,бака,ба-ка-ка, Бака җылы ярата. | лектив белән эшләүдә катнашу.<br>**ШУУГ:** күршеңә ярдәм итү. |
| *5)Максат:* “Әйтмә, бел, ул..мы” структураларын ныгыту. | Укучылар сорау бирә белергә тиеш “Ул аюмы?”....<br>Укучылар уенда актив катнашырга тиеш.<br>“Минем” структурасын актив кулланылышта йөртү. | Укытучы “Кара, әйтмә, белегез” кебек структура белән таныштыра. “Минем” структурасын актив кулланылышка кертү. | - Бу нәрсә? Бу яулык. Яулык астында нәрсә? Миша, кара. Әйтмә. Ә хәзер Миша белә. Ә сез сорагыз.<br>- Ул куянмы? Ул аюмы? Ул бүреме?<br>- Юк, ул сәгать.<br>- Сәгать ничә?<br>- Сәгать 9.<br>- Илдус. Караватка бар! Ят! Йокла! *(Илдус елый.)*<br>- Нәрсә булды, Илдус?<br>- Минем эчәсем килә.<br>- Сөт эчәсеңме?<br>- Әйе, мин сөт яратам! (*Сөт ялгыш түгелә)*. Сөт бака өстенә түгелә, Бака елый башлый “Минем чал- | **КУУГ**: парларда эшли алу.<br>**ТУУГ:** предметларны, чагыштыру, аермалы якларын билгели белү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | барым пычрак”.<br>- Бака елый, гафу ит, зинһар. Менә яңа чалбар.<br>- Рәхмәт. Минем күлмәгем чиста, минем чалбарым яңа, минем бүрегем матур. | |
| **Рефлексия**<br>Җыр: “Мин, син, ул.” | Җырны кабатлау, бергә җырлау. | Укытучы җырны кабатлатырга тиеш. | - Сез акыллы балалармы?<br>- Сез дуслармы?<br>- Әйдәгез, җыр җырлыйбыз:<br>Мин, син, ул, без, сез, алар,<br>Без акыллы балалар.<br>Мин, син, ул, алар, сез, без,<br>Без дуслар бөтенебез.<br>- Дәрес бетте, сау булыгыз. | **ШУУГ**: әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. |

# ҖИЛӘК-ҖИМЕШ, ЯШЕЛЧӘЛӘР.
# ТАРТЫМ КУШЫМЧАЛАРЫН СӨЙЛӘМДӘ КУЛЛАНУ

(1нче сыйныф, рус төркемнәре өчен татар теленнән технологик карта
(В.Н. Мещерякова системасы буенча дәрес)

***Гаязова Фәния Камил кызы,***
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы*
*117 нче урта гомуми белем мәктәбенең*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:** үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләренең кирәклеген аңлау, бер-береңә дустанә мөнәсәбәт булу, татар теленә карата ихтирамлы караш барлыкка килү.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

**Танып-белү УУГ**: дәрестә алган мәгълүматлардан файдаланып, сорауларга җавап бирү, объектларны чагыштыру, аңлап һәм ирекле сөйли белү.

**Коммуникатив УУГ**: диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үсү; коммуникатив максатка нигезләнеп, сүзләрне дөрес, урынлы куллану; үз фикереңне җиткерә белү, парларда һәм төркемдә эшли белү.

**Регулятив УУГ**: уңай халәт, дустанә мөнәсәбәт тудыру, укытучы ярдәмендә дәреснең максатын һәм темасын билгели белү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.

**Предмет нәтиҗәләре**: тартым кушымчаларын сөйләмдә кулланырга өйрәнү, “Яшелчә, җиләк-җимеш” темасына караган лексик берәмлекләрне сөйләмдә куллануны активлаштыру, камилләштерү, телдән аралашу күнекмәләре булу.

**Дәреснең төре**: бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы**: белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

**Метод һәм алымнар**: әңгәмә, өлешчә эзләнү, сорау-җавап, фонетик күнегү.

**Предметара бәйләнеш**: татар әдәбияты, музыка.

**Материал һәм җиһазлау**: рәсемнәр, сәгать, муляжлар, карточкалар, компьютер.

## Дәреснең технологик картасы

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре. |
|---|---|---|---|
| Оештыру, мотивлаштыру. | Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.<br>- Исәнмесез. Хәлләрегез ничек? Әйдәгез, дәресне башлыйбыз.<br>- Әйдәгез, укучылар, җырлыйбызмы?<br>-Дәрестә кем юк? Ул кайда? Ул өйдәме? Әйдәгез, Егорга шалтыратабыз. *(Телефон уены.)* | Исәнләшү. Дәрескә әзерлекне күрсәтү. Укытучыны сәламләү, сорауларга җавап бирү, сөйләм эшчәнлегенә кушылу.<br>Аудиодәрестәге "Исәнмесез" көенә җырлау.<br>- Егор юк. Ул өйдә. (*Бер укучы Егор, бер укучы аның дусты, берсе Егорның әнисе булып сөйләшә.)* | ШУУГ: дустанә мөнәсәбәт, укучыга хөрмәт тудыру, үзмаксат кую.<br>КУУГ: сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. |
| Белемнәрне актуальләштерү.<br>Фонетик күнегү. | - Укучылар, тактага карыйбыз. Анда сүзләр бирелгән. У хәрефе яки ү хәрефе язабызмы?<br>- Ә хәзер сүзләрне дөрес итеп укып күрсәтәбез (*үрдәк, бүлмә, ул, муен, күз, бүрек, бүләк, утыр, уйна).* | Укучылар сүзләрдәге тиешле хәрефләрне карточкалар ярдәмендә күрсәтәләр, сүзләрне дөрес итеп укыйлар. | КУУГ: дөрес әйтелеш кагыйдәләрен үтәү.<br>РУУГ: үз фикерләрен һәм җавапларын телдән дөрес итеп әйтә белү. |
| Лексик-грамматик күнекмәләр камилләштерү. | - Укучылар, тактага карыйбыз. Анда гаилә рәсеме бирелгән һәм бер яклы баскыч. (*Баскыч өстендә өчле, дүртле, бишле билгеләре беркетелеп куелган*). Балалар, карагыз, болар кешеләр. Мин сезгә бер минут вакыт бирәм, сез шул вакыт эчендә дөрес җавапларыгыз өчен, билге аласыз.<br>Шулай итегез. (*Укытучы билге алу өчен нәрсә әйтергә кирәклеген күрсәтә. Һәр дөрес җавап өчен укытучы кечкенә кеше рәсемен бер баскычка югарырак күтәрә. Һәр бала, ничә җөмлә әйтүенә карап, тиешле билге ала).*<br>Хәзер өстәлгә карыйбыз. Монда сумкалар һәм рәсемнәр бар. (*Шулай ук сумкаларга төрле язулар язылган һәм рәсемнәр ябы-* | Укучылар гаилә рәсеме буенча җөмләләр төзиләр. Лексик һәм грамматик берәмлекләрне бирелгән ситуациядән чыгып кулланалар. (*Бу – малай. Ул зур түгел, ул кечкенә. Аның башы зур. Аның бите чиста. Аның борыны озын. Аның күзләре мәрхәмәтле. Аның чәче кара. Аның авызы зур. Аның колаклары матур. Аның тешләре кечкенә. Аның муены кыска*).<br>Һәр командадан берәр кеше килеп, бер рәсем ала һәм җавап бирә. Мәсәлән, бу машина. Ул – уенчык. Дөрес җавапны әйт- | ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау, белем алу процессына уңай караш белдерү.<br><br>КУУГ: коммуникатив максатка нигезләнеп, сүзләрне дөрес, урынлы куллану, парларда эшли белү, монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләрен булдыру.<br><br>ТБУУГ: диалогик сөйләм төзү, аңлап һәм ирекле сөйли белү, объектларны чагыштыру, үз фикереңне төгәл итеп җиткерә белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *штырылган. Мәсәлән, киемнәр, җиһазлар, хайваннар, кошлар, кешеләр, ашамлыклар, уенчыклар, җиләк-җимешләр, яшелчәләр.)*<br>- Әйдәгез, балалар, ярышабыз! Ике командага бүленәбез. Бу команда – яшелчә командасы, ә теге команда – җиләк-җимеш командасы. Мин сезгә өч минут вакыт бирәм, сез шушы өч минутта рәсемнәрне сумкаларга саласыз. Башлыйбыз. (*Укытучы дөрес җавапларны билгеләп бара, нәтиҗә чыгара).*<br>- Хәзер, "Колбаса" уены уйныйбыз. Әйдәгез, матур, зур колбаса ясыйбыз. Карагыз! Мин басам. Укытучы артына кем баса?<br>Оля артына кем баса? Катя, син басасыңмы? Монда кил. Оля артына бас. *(Укытучы шушы тәртиптә балаларны тезә.)*<br>- Әйдәгез, хәзер җырлыйбыз.<br>- Укучылар, тактага карагыз. Анда ике яклы баскыч, кишер, кыяр, ике гаилә рәсемнәре. *(Һәр командадан берәр кеше сайлана. Җавапларны командадагы башка балалар да әйтә алалар, ләкин сайланган баланың җавабы гына санала).*<br>- Хәзер сез балалар түгел. Син кыяр. Тәмле кыяр. Ә син зур, баллы кишер. Бу синең гаиләң, ә теге аның гаиләсе. Алар нинди? Аерма бармы? (*Җиңүче билгеләнә).*<br>- Карагыз! Бу кем? Караватта кем?<br>- Ул нишли?<br>- Ә сәгать ничә?<br>- Шәвәли, тор. (Тормыйм. Ә сәгать ничә?) | кәннән соң гына рәсемне сумкага салалар. Уен шулай дәвам итә.<br><br><br><br><br><br><br><br>- Мин басам!<br>- Мин басам!<br>- Әйе, мин басам.<br><br>Мин басам, син басасың, ул баса! Нинди матур, нинди озын колбаса! *(Җырны берничә тапкыр кабатлап, сыйныф буенча түгәрәк ясыйлар).*<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>- Бар. Минем дәү әнием бар, ә синең дәү әниең юк. (*Һәр дөрес җавап өчен команда бер баскычка югары күтәрелә).*<br>- Бу – Шәвәли. | РУУГ: биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү.<br>РУУГ: башкаларның сөйләмен тыңлый белү, уку мәсьәләсен дөрес аңлау, үз эшчәнлекләрен планлаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Сәгать тугыз. (Тугызмы? Ай, торам, торам).<br>- Хәзер юын! (Юынам). Кулларыңны ю, битеңне ю, колакларыңны ю, муеныңны ю, җылы су белән ю! (Юам! Җылы су белән юам). Хәзер киен.(Нәрсә киим? Хәзер нәрсә эшлибез?)<br>- Әйдәгез, “Генерал” уены уйныйбыз. (*Бер укучы генерал, берсе солдат итеп билгеләнә. Һәр бала рәттән берничә команда бирә*).<br><br>- Шәвәли, хәзер нәрсә эшлибез? (Әйдәгез, ашыйбыз!). Ә син нәрсә яратасың? (Мин яшелчә һәм җиләк-җимеш яратам!) Ә яшелчә һәм җиләк-җимеш кайда? (*монда. Менә.*) Әйдәгез, кибеткә барабыз! | -Ул йоклый.<br>- Сәгать тугыз.<br><br>- Күлмәк ки, чалбар ки, ботинка ки. Әйдәгез, уйныйбыз!<br>Генерал укучы командалар бирә, солдат укучы үти. Бас! Йөгер! Сикер! Ела! Йокла! Шулай ит! Алай итмә! Юын! Киен! Яз! Аша! Эч! һ.б.<br>Укучылар укытучы белән бергәләп, “Кибет-кибет” уены уйныйлар. Аннан нәрсә яратулары, ә нәрсә яратмаулары турында әйтәләр. | |
| Рефлексия. Укучыларны бәяләү. | - Укучылар, хәзер алмаларны саныйбыз. Кемдә ничә алма бар? (*Укытучы дәрес барышында укучыларга дөрес, тулы җаваплар өчен кечкенә алма рәсемнәре биреп бара. Хәзер алмалар саны буенча укучыларның эшчәнлегенә нәтиҗә ясала.)*<br>- Дәрестә актив катнаштыгыз, сез бик акыллы балалар. Дәрес бетте, сау булыгыз. | Укучылар дәрес барышында алган алмаларын саныйлар, үзүзләрен бәялиләр. | РУУГ: бәяләү, хаталарны төзәтү<br>ШУУГ: үз уңышларын\уңышсызлыкларын турында фикер йөртү. |

# “СИНЕҢ... ? МИНЕМ...” ТӨЗЕЛМӘСЕ.
# -МЫ, -МЕ СОРАУ КИСӘКЧӘЛӘРЕН СӨЙЛӘМДӘ КУЛЛАНУ

***Габделбариева Тулкунай Абдулкаһаровна,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы*
*М.С. Устинова исемендәге 102 нче гимназиянең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*филология фәннәре кандидаты*

**Максатлар:**

**1.** Укучыларның сөйләменә “Синең...? Минем...” төзелмәсен кертү һәм активлаштыру; -мы, -ме сорау кисәкчәләре ярдәмендә сорауларны дөрес формалаштыру.

**2.** Сорау төзеп, сорауга җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү, сөйләм телен үстерү һәм баету.

**3.** Парларда эшли белү, хәтерне, игътибарлылыкны һәм аралаша белү сәләтен үстерү.

**4.** Укучыларда этик һәм әхлак нормаларын булдыру, җәмгыятьтә көндәлек тормышка әзерләү.

**Дәрес тибы:** сөйләм телен үстерү дәресе.

**Җиһазлау:** күрсәтмә әсбаплар (Җ, Ч хәрефләре төшерелгән карточкалар, “Гаилә”, “Гаилә һәм киемнәр” рәсеме, ашамлыклар һәм эчемлекләр рәсемнәре: сөт, лимонад, чәй, кофе һ.б., 18-20 төрле уенчык хайваннар һәм кошлар, уенчык керпе, 2 сумка, тартма, генерал һәм солдат баш киемнәре, уенчык итекләр яки итек рәсеме, костюм (яки рәсеме), уенчык карават, “Генерал” пиктограммасы, сәгать, телефон, “Мин, син, ул, без, сез, алар” пиктограммасы).

Дәреслек: “Татар теле –илем теле” аудиокурсының дискы. УМК: “Татар теле – илем теле” / В.Н.Мещерякова, Р.Р. Нигъмәтуллина. – Казань, Институт развития образования РТ, 2016.

## Дәрес барышы

**1. Оештыру. Уңай психологик халәт тудыру.**

- Исәнмесез, балалар! – *Исәнмесез, укытучы апа!*
- Сезнең хәлләрегез ничек? – *Яхшы! Ә сезнең хәлләрегез ничек?*
- Бик яхшы, рәхмәт! Әйдәгез, дәресне башлыйбыз!- *Әйдәгез!*

**2. Актуальләштерү.**

- Балалар, дәрестә кем юк? – *Полина юк! Карина юк! Юра юк! Егор юк!*
- Балалар, ә Егор кайда? Ул өйдәме? Әйдәгез, Егорга шылтыратабыз! *(Укытучы телефонны ала, шылтыраткан була).*

– Алло, исәнмесез! Мин укытучы апа. Бу Егормы? *(Балаларга.)* Бу Егор түгел, бу Егорның әнисе – Светлана Николаевна! (*Трубкага*.) Гафу итегез, ә Егор өйдәме? *(Укучыларга.)* Ул өйдә! – Егорга трубканы бирегез, зинһар!

*(Паузадан соң.)* – Егор, исәнмесез! Синең хәлләрең ничек? Яхшы түгел? *(Балаларга.)* Аның хәле яхшы түгел. (*Трубкага.)* Син мәктәпкә киләсеңме? *(Балаларга.)* Ул мәктәпкә килми! Аңа сәлам әйтәбезме? –*Әйе!* – Әйдәгез! – *Сәлам!* – *(Трубкага.)* Егор, балалар сиңа сәлам әйтәләр. – Балалар, Егор да сезгә сәлам әйтә! Егорга бергә рәхмәт әйтегез! – *Рәхмәт!*- *(Трубкага.)* Сау бул, Егор.

*(Укытучы балалардан сорый.)* – Минем песием бар. Ә синең песиең бармы? – *Әйе, минем песием бар.* – Ә аның исеме ничек? – *Мурка.* – Ә ул кайда? Мондамы? Өйдәме? – *Өйдә!* – Ә синең этең бармы? – *Юк.* – Минем дә этем юк.

– Сез яхшы балалармы? – *Әйе!* Ә сез акыллы балалармы? – *Әйе!*- Әйдәгез, җырлыйбыз! ( **Җыр)**:

Мин, син, ул, без, сез, алар –
Без акыллы балалар!
Мин син ул, алар сез , без –
Без дуслар бөтенебез!)

– Безнең кабинетыбыз нинди? – *Матур! Зур!* - Ул матур, ул зур. Тагын нинди? – *Ул чиста!* (*Һ.б. белгән сыйфатларны әйтәләр*). – Шкаф кайда? – *Менә!* - Тәрәзә кайда? – *Менә тәрәзә!* – Укытучы апа кайда? – *Менә укытучы апа!*

Укытучы шкаф пыяласына күрсәтә. – Ә сез беләсезме, бу нәрсә? – *Бу пыяла!* – Ә безнең кабинетыбызда пыяла тагын кайда бар? – *Менә пыяла! (тәрәзәгә күрсәтәләр)* – Әйе, тәрәзәдә пыяла бар! – *Менә пыяла!* – Әйе, күзлектә дә пыяла бар!

**3. Белем һәм күнекмәләрне формалаштыру.**

Укытучы бер укучыга:

– Синең бу кофтаң (чалбарың, күлмәгең...) бик матур! Синең тагын бер кофтаң бармы? – *Әйе, бар!* - Ул кайда? Ул өйдәме? – *Әйе, ул өйдә!* – Ә ул нинди? – *Ул матур, яңа,җылы.* – Ул сиңа ошыймы? – *Әйе, ошый.*

Тактага Җ һәм Ч хәрефләре төшеп калган сүзләр язылган: җыр, чынаяк, читек, җырлыйбыз, укучы, җиңел, җиде.

– Балалар, әйдәгез, **Кабатлау** уены уйныйбыз! Бу нинди хәреф? (*Җ хәрефен күрсәтә*). – Кабатлагыз! Җ! – *Җ!* – Ул кайда бар? - Җыр! – Әйе, җыр сүзендә бар! (*тактага җ хәрефен өстәп яза*). Хәзер монда карагыз! Бу нинди сүз? Диана, укы! – *Чынаяк!* – Яхшы! *(Шулай дәвам итә*).

Өстәлгә 18-20 уенчык (*барлык балаларга да җитәрлек*) куелган.

– Өстәлдә ничә уенчык бар? Әйдәгез, саныйбыз! – *бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш, уналты, унҗиде, унсигез...*(*Берничә укучыдан сорый.*) – Сиңа нәрсә ошый? – *Миңа эт ошый.*

– Әйдәгез, **Кибет-кибет** уйныйбыз! Хәзер мин укытучы апа түгел, мин сатучы. Рома, син кибеткә бар! – *Исәнмесез!* – Исәнмесез! Сезгә нәрсә кирәк?

*– Миңа аю кирәк. Бирегез, зинһар!* – Менә аю, алыгыз! *– Рәхмәт! (Берничә укучы белән шулай эшли).*

– Ә хәзер кем сатучы? (*Укучылар сатучы ролендә килә*). Уен ахырында һәр баланың бер уенчыгы була.

– Уенчыкларны яшерегез! Хәзер кемнең аюы бар? Белмим! Синең аюың бармы? – *Юк, минем аюым юк.* – Ә кемнең аюы бар? *(3-4 укучыдан сорый.) - Минем аюым бар!* (яки: *Минем бар!)*

– Укучылар, мин арыдым. Уенчыкларны өстәлгә куегыз, зинһар! *(Укучылар берәм-берәм уенчыкларны өстәлгә куялар).*

– Әйдәгез, **Генерал** уены уйныйбыз! Саша, монда кил! Хәзер син солдат буласың, ә мин – генерал. Мин сиңа команда бирәм. Ә син : “Тыңлыйм, иптәш генерал!” – дип әйт. – Бас! – *Тыңлыйм, иптәш генерал*! – Шулай ит! (*Бала команданы үти*). Утыр! Монда кил! Моннан кит! Аша! Эч! Утыр! Ят! Уйна! Җырла! *(Барлык таныш фигыльләрне боерык фигыльнең 2 зат берлек сан формасында кулланып, 2-3 укучы белән эшли)*.

– **Әле-гафу итегез** уенын уйныйбыз!

– Басыгыз! Укытучы фигыльләрне боерык фигыльнең 2 зат күплек сан формасында кулланып, команда бирә. Укучылар бу команданы, укытучы “әле” сүзен әйтмичә бирсә, аны үтәмиләр, хор белән: *Сез бит генерал түгел! Ә без солдатлар түгел! Әле, дип әйтегез*!- диләр. Команданы ялгыш үтәгән бала уеннан чыга. Укытучы гафу үтенә һәм команданы үтенү интонациясе һәм “әле” сүзе белән кабатлый.

– Гафу итегез, мин бит генерал түгел. Басыгыз әле! *(Команданы үтиләр).*

– Утырыгыз! *– Юк! Сез бит генерал түгел! Ә без солдатлар түгел! Әле дип әйтегез*!

– Гафу итегез, балалар. Мин бит генерал түгел, ә сез солдатлар түгел. Утырыгыз әле... (*һ.б. фигыльләр белән*).

<u>Әкияти керпе уенчыгы,</u> кулында сумкасы бар. Шакый. Укучылар:

*– Бу кем?*

<u>– Бу мин!</u>

*– Син кем?*

<u>– Әйтмим, белегез!</u>

*– Син куянмы (аюмы, Маратмы?...(Укучылар берәм – берәм сорыйлар).*

<u>– Юк, мин куян (аю, Марат....) түгел.</u>

*– Әйт әле, зинһар!*

– Мин әкияти керпе.

– Балалар, чакырабызмы әкияти керпене?– *Әйе! Әкияти Керпе, кер!*

– <u>Бу сезнең кабинетыгызмы?–</u> Әйе, бу безнең кабинетыбыз. Безнең кабинетыбызга рәхим ит, Керпе! – <u>Рәхмәт. Гафу итегез, сезнең исемегез ничек?</u> – Минем исемем ... (*укытучы әйтә*). Ә синең исемең ничек?– <u>Минем исемем Хәйдәр</u>. (*Балалардан сорый*). Ә сезнең исемегез ничек? – Минем исемем Полина... (*һ.б.балалар җавап бирә*).

– Әйдәгез, җырлыйбыз! (**Җыр):** Минем исемем Хәйдәр, минем исемем Хәйдәр,

– Әйт әле, кыз, әйт әле кыз, синең исемең ничек?

Бер–берсенә мөрәҗәгать итеп, түгәрәк буенча, җырны 3–4 бала парлап башкаралар.

– Әйдәгез, дус булабыз! (Бер–берсенең кулларын кысышалар).

– Әйдә, дус булабыз! – *Әйдә! –Хәзер без дуслар!*

– Керпе, синең гаиләң бармы? – Әйе, бар! – Ә синең әтиең бармы?–Бар! Менә минем әтием! – Ә син аны яратасыңмы? – Бик яратам! *(Сумкасыннан бер рәсем чыгара, ул тавык рәсеме).* Балаларга күрсәтә.:

– Балалар, карагыз әле! Аның әтисе керпеме? – *Юк, ул керпе түгел! Ул тавык!*

– Синең әниең (апаң) бармы? – Бар! Менә минем әнием (апам). – Син аны яратасыңмы? –Бик яратам. – Балалар, карагыз әле! Аның әнисе керпеме? – Юк, ул керпе түгел, ул песи... *(Укытучы барлык рәсемнәрне берьюлы түгел, ә бер–бер артлы чыгара).*

Укучыдан сорый:

– Сиңа кем күбрәк ошый? – *Әни (се).*– Аның әнисе.

– Әйдәгез, җырлыйбыз! (**Җыр**): Минем әнием бар, минем әтием бар,

Минем абыем бар, минем апам юк,

Минем сеңелем бар, минем энем юк.

**4. Ныгыту.**

Укытучы:

– Менә, менә минем борыным (*үзенең борынына күрсәтә*). Ә сезнең борыннарыгыз (*муен, колак, кул, бармак, авыз, бит, чәч, аяк*) кайда? – *Менә, менә минем борыным!* (*һ.б. сүзләр белән*).

Керпе укучылардан сорый:

– Кемнең борыны зур? – *Минем!* – Синең! – Кемнең бармаклары озын? – *Минем! –Синең!*– Кемнең колагы кечкенә?– *Синең!*

(***Гаилә*** *рәсеме*).

– Болар кешеләрме?– *Әйе, болар кешеләр.*– Монда ничә кеше бар?– *Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез...* – Бу кем? – *Әти.*– Бу кем? – *Апа...һ.б.*

– Әйдәгез, уйныйбыз! Аның күзләре зур, аның куллары озын...Ул кем? – *Ул әни!* – Аның чәче кара, аның борыны кыска. Ул кем? – *Ул әти.*

**Бүләк** уены. Керпе елый.

– Нәрсә булды, Хәйдәр? Әйдәгез, бергә сорыйбыз! Кабатлагыз! Нәрсә булды, Хәйдәр?– *Нәрсә булды, Хәйдәр?*

– Минем бүген туган көнем. Ә бүләкләр юк. Миңа бүләк кирәк! – Елама!

(*Балаларга пышылдап әйтә*): - Әйдәгез, Хәйдәргә бүләк бирәбез! Нәрсә бирәбез: итек бирәбезме, костюм бирәбезме? (*Балалар сайлыйлар*) – *Итек (костюм).* – Яхшы. Ә итекне кая куябыз? Тартмагамы, сумкагамы? Балалар сайлыйлар) – *Сумкага!*

– Менә бүләк!

– Бик зур рәхмәт! *(Бүләкне карый, шатлана*). – Ой, итек! Рәхмәт!

– Ә хәзер нишлибез? Ашыйбызмы?

– Юк, ашамыйбыз!

– Уйныйбызмы?– Юк, уйнамыйбыз!

– Эчәбезме? –Эйе, эчәбез! Минем эчәсем килә!

– Син лимонад (кофе, чәй) яратасыңмы? – Юк, яратмыйм!

– Син сөт яратасыңмы?– Яратам! – Менә сөт, ал! – Рәхмәт!

**5. Йомгаклау.**

– Сәгать ничә?– *Сәгать унике*.– Ай, өйгә кайтырга вакыт, йокларга вакыт! – Яхшы! Бар! – Барам! – Ят! – Ятам! – Йокла! – Йоклыйм! *(Керпе ятып йоклый).*

– Балалар, әйдәгез, җырлыйбыз!

**Җыр:** Керпе, ят, йокла, тыныч йокы бала!

**6. Саубуллашу.**

– Балалар, вакыт үтте. Дәрес бетте. Сау булыгыз!

## МИНЕМ, СИНЕҢ, АНЫҢ АЛМАШЛЫКЛАРЫН КУЛЛАНУНЫ СӨЙЛӘМДӘ НЫГЫТУ

(1 нче сыйныф, рус төркеме)

***Зарипова Лилия Фирдәүс кызы,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*161 нче урта гомуми белем мәктәбенең*
*беренче квалификацион категорияле татар*
*теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максатлар:**

1. Минем, синең, аның алмашлыкларын куллануны сөйләмдә ныгыту.

2. Сорау кую ысулларын һәм дөрес җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү, тартым кушымчалары турында белгәннәрне ныгыту.

3) Әти-әнигә, гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү.

**Эш формалары**: индивидуаль, парларда, төркемләп, фронталь.

**Дәреснең тибы**: катнаш.

**Җиһазлау**: рәсемнәр, пиктограммалар, уенчыклар.

**Дәрес барышы**

**I. Психологик уңай халәт булдыру.**

– Исәнмесез, балалар! – *Исәнмесез!*

– Безнең бүлмәбез чистамы?

– Минем урындыгым чиста, яхшы, яңа. Ә синең урындыгың чистамы? – *Әйе, чиста.*

– Минем урындыгым чиста, ә синең урындыгың чиста түгел. Гафу ит! Менә чиста урындык. Ал.

– Хәлләрегез ничек? – *Яхшы. Ә сезнең хәлләрегез ничек?* – Минем дә хәлләрем яхшы. Укучылар, дәресне башлыйбыз.

**II. Белемнәрне актуальләштерү.**

1. Әйдәгез, “телефон–телефон” уйныйбыз! Бу нинди номер? – *14, 17, 19.* – Номерны сорагыз! – *Миңа 15–16–17 номерын бирегез, зинһар. (Укытучы укучыларга номерлар тарата)* – Ника, хәзер син авыру бала. Бу синең гаиләң. Синең гаиләң дусмы? – *Әйе!*– Монда ят. Йокла! Син авырыйсың. Ә мин сиңа сәлам әйтәм. Менә, телефон номерлары. (*Укытучы телефон номерларын ала һәм теләсә кайсы бер номерны укый. Әгәр “абонент” җавап бирмәсә, укытучы:“Элемтә начар, телефон җавап бирми. Әйдәгез, тагын шалтыратабыз”, – ди һәм шул ук номерны ачыграк һәм әкренрәк әйтә.) Алло!* – Алло! Исәнмесез! – *Исәнмесез!* – Мин Лилия апа, Никаның укытучысы. Ә сез кем? – *Ә мин Никаның әнисе.* – Ника өйдәме? – *Өйдә.* – Трубканы Никага бирегез әле, зинһар. (*Әни–бала трубканы “авыру” балага бирә*) Исәнме, Ника! Синең хәлләрең ничек? Яхшымы? – *Яхшы түгел.*– Мәктәпкә киләсеңме? – *Юк!* – Сиңа балалар сәлам әйтәләр. – *Рәхмәт.* – Ә син балаларга сәлам әйтәсеңме? – *Мин дә сәлам әйтәм.* – Рәхмәт! Әниеңә дә, әтиеңә дә сәлам әйт. Сау бул, Ника! – *Сау булыгыз!*

2. Тактада ө,е хәрефләре төшереп калдырылган сүзләр: өч, төлке, муен, өй, өстәл, итек. Укучыларның кулында әлеге хәрефләр язылган карталар. Балалар дөрес хәрефне күтәрәләр һәм бергә укыйлар, хәрәкәтләр ярдәмендә әлеге сүзләрне күрсәтәләр.

3. – Укучылар, әйдәгез, уен уйныйбыз! Безнең кабинетыбыз җылымы, салкынмы? *(зур–кечкенә, чиста–пычрак, начар–яхшы, матур–ямьсез)* Шкаф (*тәрәзә, парта, ишек, өстәл, урындык, такта, сәгать)* кайда? – *Менә, шкаф.* – Пыяла кайда бар? *–Шкафта* (*лампада, күзлектә, рәсемдә, сәгатьтә*) дә бар. – Синең өйдә ничә бүлмә бар? Алар нинди? Аерма бармы? Ә зур бүлмәдә нәрсә бар? Тегендә нәрсә бар? (*Җиһазлар ясалган бүлмә рәсеме, ул тактада эленеп куелган*) – *Тегендә шкаф бар.* –Бүлмәдә шкаф бар. Тегендә тагын нәрсә бар?

**III. Әңгәмә. Уку мәсьәләсен кую.**

1. Пиктограммалар салынган сумка; пиктограммалар, укучылар укый алсыннар өчен, язулы якларын өскә каратып куелган. Кием, җиһаз, хайваннар, кошлар һәм башка кирәкле рәсемнәр.

– Монда ничә рәсем бар? *–Күп!*– Бу сумкага нәрсәләрне салабыз? Бу сумкага киемнәрне, кошларны, хайваннарны салабыз. Бу – шкаф. Ул – җиһаз. (*Укытучы рәсемнәрне тиешле сумкага салып бара*). Кирилл, хәзер син сал. – *Бу – куян. Ул – хайван.* (*Балалар бөтен рәсемнәрне дә тиешле сумкаларга бүлеп урнаштыралар).*

2. “Куян–бүре” уены.

3. “Генерал” уены. Вика, монда кил! Вика, хәзер син солдат, ә мин генерал. Мин сиңа команда бирәм, ә син “Тыңлыйм, иптәш генерал!”– дип әйт. Мин сиңа “Шулай ит,” – дип әйтәм, ә син команданы үтә. – Йокла! Шулай ит! Бар! Йөгер! Сикер! Тор! Юын! Киен! Яз! Укы! Аша! Эч! Алай итмә! Ела!

Жыр:
Бас! Йөгер! Бар! Сикер!
Шулай ит!
Яз! Ела! Укы! Йокла!
Шулай ит!

4. (*Бичура, кулына сумка тоткан. Сумкада – гаилә темасына рәсемнәр*). Балалар, тыңлагыз! Ишетәсезме? Кемдер тегендә кыштыр–кыштыр килә. Карагыз! Күрәсезме? Бу кем? *Син кем?* – Әйтмим, бел! – *Син куянмы?*– Юк, мин куян түгел. – *Син Шүрәлеме*? – Юк, мин Шүрәле түгел. – *Белмим, әйт!* – Әйтмим! – *Әйт, әле зинһар!(Сорауны дөрес итеп биргән укучының колагына –*Мин Бичура! *– дип әйтә*). Ә сезнең исемегез ничек? (*Укучылар хор белән һәркайсы үзенең исемен әйтә).*

– Әйдәгез, дус булабыз! (Бер–берсенең кулларын кысышалар.) Әйдә, дус булабыз! – *Әйдә! – Хәзер без дуслар!* – Ә хәзер, әйдәгез уйныйбыз!

5. Бичура:

– Синең бу чалбарың шундый матур, ә синең тагын бер чалбарың бармы? Ул өйдәме? Ул нинди? Синең ничә чалбарың бар? Аның өч чалбары бар! *(Берничә бала белән киемнәр турында сөйләшәбез).*

6. (*Бичура өчен яңа пәлтә шкафта яшерелгән. Бичура елый*) – Нәрсә булды? Нигә елыйсың? – Минем кием пычрак, ямьсез. Миңа чиста кием кирәк.– Бездә пәлтә бар. Ул кайда? Мин әйтмим. Бел! Балалар, ә сез аңа булышыгыз! – *Өстәл*! – Ул өстәлдәме? – Юк! Ул өстәлдә түгел.– *Шкаф!* – Ул шкафтамы? – Әйе, ул шкафта. Менә, пәлтә, ул сиңа бүләк. – Рәхмәт. Миңа бу пәлтә бик ошый!

7. (*Бер яклы баскыч+секундларны күрсәтә торган сәгать яки секундомер+пиктограммалар: чиста, яңа, матур*). Минем–синең киемең. *(Баскычтан югарыга күтәрелеп, “5”ле билгесе алу өчен,үзенең һәм Бичураның киемен чагыштырып, укучы бер минут эчендә 5 җөмлә әйтергә тиеш. “4” билгесе алу өчен – дүрт җөмлә. Һәр бала да бу тема буенча билге алырга тиеш*).

**Җавап үрнәге:** Минем киемем чиста, ә синең киемең пычрак. Минем күлмәгем кызыл, ә синең күлмәгең зәңгәр. Минем ботинкам яңа, ә синең ботинкаң иске. Минем күлмәгем чиста, ә синең күлмәгең пычрак. ...

**IV. Ныгыту.**

1. (*Сумка. Анда Бичураның гаиләсе рәсеме*) Сумкада нәрсә бар? – Бу минем гаиләм. – Ә синең гаиләңдә кем бар? – Әйтмим, бел! – *Синең әниең (әтиең, дәү әтиең, дәү әниең) бармы?* – Әйе! Минем әнием бар. – Синең гаиләң дусмы? – Әйе. Минем гаиләм дус. Ә сез дуслармы? – *Әйе! Без дуслар!*

2. Әйдәгез, җырлыйбыз. Тыңлагыз! Бу җырны кем җырлый? (*Укытучы бер персонажның җырын җырлый, балалар аны танып әйтергә тиешләр).*

| | |
|---|---|
| **Дәү әни**<br>Минем битем сары,<br>Күзләрем матур,<br>Борыным кыска,<br>Аякларым зур. | **Дәү әти**<br>Минем битем кызыл,<br>Тешләрем матур,<br>Борыным озын,<br>Кулларым бик зур. |
| **Әни**<br>Минем битем зәңгәр,<br>Чәчем бик матур,<br>Кулларым кыска,<br>Колакларым зур. | **Әти**<br>Минем битем яшел,<br>Авызым матур,<br>Кулларым озын,<br>Бармакларым зур. |

*Ул – әни (..)* - Әйе! Ул аның әнисе. Әйдәгез, аның җырын җырлыйбыз.

**V. Рефлексия.**

1. Кемнең борыны зур (кечкенә?) – *Минем!* - Кемнең чәче кыска? – *Минем чәчем кыска!*

2. Әйдәгез, бармакларны саныйбыз! Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш, уналты, унҗиде, унсигез, унтугыз, егерме.

**VI.Йомгаклау.**

Гафу итегез, балалар! Вакыт үтте. Дәрес бетте. Сау булыгыз!

## “СӘЛАМ” УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКТЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Бәхтиев Рөстәм Флүс улы,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы 2 нче лицей-интернатының татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Сәлам» укыту-методик комплекты авторы, филология фәннәре кандидаты*
***Якупов Рашат Нух улы,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы 2 нче лицей-интернатының татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Сәлам» укыту-методик комплекты авторы*
***Маркова Эльвира Марсель кызы,***
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 9 нчы урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Сәлам» укыту-методик комплекты авторы*

“Сәлам” укыту-методик комплекты (УМК) рус телендә башлангыч белем бирү оешмаларының 1нче сыйныф укучылары һәм татар телен башлап өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителә. Ул татар телен чит тел яки икенче тел

буларак укыту методикасы нигезендә, коммуникатив принципны алга куеп төзелде, шунлыктан башлангыч сыйныф укучылары татар телен тормышчан һәм мажаралы хәлләргә эләккән геройлар – яшьтәшләре һәм аларның дуслары белән бергә өйрәнәләр, күнегүләр башкаралар, бергә уйныйлар, җырлыйлар.

"Сәлам" укыту-методик комплектының төп бурычы – дәрестә укучыларны сөйләшергә өйрәтү. Моңа алар уеннар уйнап, аудиодиалог һәм монологлар тыңлап, тормышчан ситуациядә үз-үзләрен тотышлары аша ирешәләр. Укучылар, уйный-уйный, яңа сүзләр, җөмләләр өйрәнәләр. Грамматик кагыйдәләр ятламыйлар. Беренче сыйныфта укучылар үз көндәлек тормышларында иң актив һәм кирәк булган 160 сүз һәм 30 сөйләм калыбы өйрәнәләр. 15 теманы берләштергән дәреслек, укучыларга иҗади мөмкинлекләр биргән эш дәфтәре, сайт аша өйдә дә уеннар уйный алу, аудиоязмаларны тыңлау, дәрестә үзләштерелгән сүзләр нигезендә язылган җырларны өйрәнү, кирәк булса дәрестә тыңлаган аудиоязмаларны өйдә дә аудиоязма яки сайт аша тыңлый алу – укучыларга телне өйрәнүдә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

*УМК түбәндәге компонентлардан тора:*

- Дәреслек
- Интерактив дәреслек
- Эш дәфтәре
- Укытучы китабы
- Аудиодиск
- Лексик карточкалар
- www.selam.tatar - *сайты*

*Дәреслек* белән укучылар дәрестә эшлиләр. Ул төсле һәм матур рәсемле, балалар күңеленә хуш килердәй стильдә эшләнгән. Һәр дәрестә УМКның төп геройлары төрле вакыйгаларда катнашалар һәм укучыларны шул ситуациягә бәйле сөйләм калыплары белән таныштыралар. Дәреслек 15 темага бүленеп бирелә, һәр теманың үз эчендә дәресләргә бүленеш тә тәкъдим ителә. Укучыларны күнегүләр белән артык ялыктырмас өчен, дәрес саен 2-4 күнегү генә тәкъдим ителә, әмма "Укытучы китабы"нда бу күнегүләргә карата, сайлап алу һәм башкару өчен, төрле бирем үрнәкләре күрсәтелә.

*Интерактив дәреслек* укытучыга күнегүләрне укучылар белән күмәк эшләү, материалны зур планга чыгарып, дәрестә күрсәтмәлелекне арттыру, укучыга өйдә әти-әниләр белән бергә дәрес материалын кабатлау өчен уңайлыклар тудыра.

*Эш дәфтәре*ндәге иҗади биремнәрне балалар өйдә дә, дәрес вакытында да башкара алалар. Бу биремнәрне башкару балага үз фантазиясен күрсәтергә ярдәм итә, үз эшен бәяләргә өйрәтә. Укучылар эш дәфтәрендә рәсем ясый, үзе теләгәнчә аларны буйый, стикерлар ябыштырып, рәсемнәрне тулыландыра алалар. Эш дәфтәрендәге күнегүләрнең барысын да укучыга дәрестә яки өйдә эшләп бетерү максаты куелмый. Укытучы күнегүне баланың сәләте һәм

теләгенә карап сайлап ала. Эш дәфтәренең ахырында күнегүләрне башкару өчен стикерлар җыелмасы бирелә.

*Укытучы китабы*. Анда һәр дәреснең барышын тасвирлаган материал тәкъдим ителә "Укытучы китабы"нда дәреслектәге күнегүләр, аудиоязма текстлары, укучыларга бирелә торган сорау үрнәкләре, дәрестә башкарылырга мөмкин булган уен үрнәкләре, укучыларны ял иттереп алу өчен, хәрәкәтчәнлек таләп иткән биремнәр, эш дәфтәрендәге биремнәрне башкаруга күрсәтмәләр, җыр текстлары һәм алар белән эшкә тәкъдимнәр күрсәтелә. Бу биремнәрнең саны дәрес саен төрле. Гадәттә алар, 60 минутка җитәрлек итеп биреләләр.

"Сәлам" УМКсы 152 сәгатьлек дәрес материалын үз эченә ала. Төрле уку-укыту оешмаларында дәрес саннары төрлечә булганлыктан, укытучылар тематик һәм календарь эш программаларын үзләренә яраклаштырып төзергә тиеш булалар.

Дәреслектә күнегүләр татар теле һәм әдәби уку дәресләренә бүлеп бирелми. "Укытучы китабы"нда исә әдәби уку дәресләрендә файдаланылырга мөмкин булган материал укытучы өчен искәртелеп барыла, аудио һәм видео материалларга сылтамалар тәкъдим ителә, укытучы тарафыннан укылырга киңәш ителгән текстлар бирелә.

www.selam.tatar – сайты. Татарча сөйләшү, татар телен үзләштерү мәктәптә генә түгел, ә өйдә дә дәвам итсен өчен, УМКның махсус сайты - "Сәлам" сайты эшли. Аңа компьютер аша да, планшет аша да кереп була. Сайтта интерактив дәреслек, барлык уку-укыту материаллары бар, күнегүләрне уен форматында эшләү мөмкинлеге каралган, әти-әниләрнең сораулары яки тәкъдимнәре булса, кара-каршы язышып, күнегүләргә һәм биремнәргә карата комментарийлар калдырып була. Сайт периодик рәвештә яңартылып тора, кирәкле материаллар белән тулыландырыла. Дәреслек сәхифәсенә укучы да, укытучы һәм әти-әни дә махсус логин һәм парольләр аша кереп эшли. Әлеге парольләр укытучы тарафыннан таратыла.

*Карточкалар*. Алда әйтелеп үтелгәнчә, укучылар 1нче сыйныфта уку дәверендә татар теле дәресләрендә 160 лексик берәмлек өйрәнәләр. Аларны төрле сөйләм калыпларында файдалана һәм кирәкле ситуацияләрдә куллана белергә тиеш булалар. Бу эшне җиңеләйтү максатыннан, укытучыга дәрестә куллану өчен, рәсемле карточкалар тәкъдим ителә. Аларның электрон вариантлары сайтта да урын ала. Бу карточкаларны "Укытучы китабы"нда киңәш ителгәнчә, гадәти дәрес барышында да, контроль дәресләрдә дә, өйдә материалны кабатлау өчен дә файдаланырга мөмкин.

УМКның файдалы үзенчәлеге – аудиоматериалларның күп булуы һәм сайтта күнегүләрне интерактив форматта эшләп булуда. УМКның һәр модулендәге бик күп үрнәк диалоглар, монологлар, җырлар укучыларга телне яратып өйрәнергә ярдәм итәр дип ышанабыз.

# “ШӘҺӘР. АВЫЛ” ТЕМАСЫНА 1НЧЕ ДӘРЕС

“Сәлам” укыту-методик комплекты буенча төзелгән дәрес эшкәртмәсе.
(1нче сыйныф, рус төркеме)

***Кашафетдинова Гөлназ Вәсит кызы,***
*Казан шәһәре Вахитов районы*
*39 нчы урта мәктәпнең*
*1нче квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Дәреснең тибы**: яңа белем һәм күнекмәләр бирү.

**Дәреснең максаты**.

***Белем бирү***: “Шәһәр. Авыл” темасына кагылышлы сүзләр һәм сөйләм калыплары белән танышу, аларны диалогик, монологик сөйләмдә куллана алу күнекмәләрен формалаштыру.

***Үстерешле***: сүз байлыгын арттыру, логик фикер йөртү осталыгын, анализлау һәм чагыштыру күнекмәләрен үстерү, географик урынчалык, торак пунктлары турында аерманы белү.

***Тәрбияви:*** туган илгә, туган җиреңә мәхәббәт уяту; шәһәрең, авылың белән горурлану хисенә ия булу.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр***: яңа белемнәр алуга һәм уку материалына кызыксыну уяту, алган белемнәрне тормышта куллана алу сәләтләрен булдыру.

***Метапредмет нәтиҗәләре:*** укытучы ярдәмендә дәреснең максатын билгели һәм формалаштыра белү; дәрестә алган мәгълүматлардан, тормыш тәҗрибәсеннән файдаланып, сорауларга җавап бирү; үз фикереңне дөрес итеп әйтә һәм башкаларны ишетә–тыңлый белү, нәтиҗәләр ясый белү, үзбәя үткәрү күнекмәләре барлыкка килү.

***Предмет нәтиҗәләре:*** темага кагылышлы сүзләр һәм сөйләм калыпларын истә калдыру, аларны диалогик, монологик сөйләмдә дөрес куллана алу күнекмәләрен формалаштыру.

**Ресурслар:** дәреслек – “Сәлам” УМКсы. Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 1нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче укучылар өчен).

**Җиһазлау**: презентация, интерактив такта, компьютер, аудиодиск, рәсемле карточкалар, кушымчалар язылган карточкалар, эш дәфтәре.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру– ориентлаштыру.**

**1. Дәресне оештыру.**

***а) Дәрескә уңай халәт тудыру.***

– Исәнмесез, укучылар! Әйдәгез, матур шигырь әйтеп, дәресебезне башлыйбыз:

Хәерле иртә кояшка! (Слайд)
Хәерле иртә күк йөзенә!

Хәерле иртә дустыма!
Хәерле иртә үземә!
– Бик яхшы, укучылар, рәхмәт, утырыгыз!

***б) Дежур рапорты.***

– Бүген кем дежур? (*бүген мин дежур*)
– Бүген сыйныфта кем юк? (*Сыйныфта барысы да бар*)

***в) Һава торышы турында сөйләшү.***

– Бүген көн нинди? Кояш бармы? Салкынмы? Ә сез нинди көн телисез?

***г) Танышабыз.***

– Укучылар, бүген сезнең белән танышырга урманнан аю килде *(укытучы уенчык аю күрсәтә)*. Әйдәгез, танышабыз!
Ике укучы арасында диалог, бер укучының кулында уенчык аю:
– Хәлләр ничек? Синең исемең ничек? Сиңа ничә яшь?Син укучымы?

**2. Белемнәрне актуальләштерү.**

Укучылар белән үткән дәреснең, теманың лексик берәмлекләрен һәм лексик структураларын рәсемле карточкалар ярдәмендә искә төшереп китәләр.

***Фонетик күнегү***

– Укучылар, әйдәгез, авазларны әйтәбез (*укучылар укытучы артыннан татар теленә генә хас булган авазларны кабатлыйлар) – [Ә] – әби, [Ө] – өстәл, [Ү] – үрдәк, [А] – апа, [О] – борын, [Җ]–җәй, [Ч] – чәй, [К] – куян, [Г] – быргы, [W] – авыл, [Һ] – шәһәр,[ң] – киң)*

**3. Уку мәсьәләсен кую.**

– Рәхмәт, яхшы, укучылар! Тактага карагыз. Бу нәрсә?(*город)* <u>(Слайд)</u>
– Шәһәрләр нинди була? Города какие бывают?(*зур, матур)*
– Син кайда яшисең? Ты где живешь? *(укучыларның җавабы)*
– Шәһәреңнең исеме ничек? Как называется твой город?(*укучыларның җавабы)*
– Сезгә шәһәрегез ошыймы, нәрсә белән ошый? Вам нравится ваш город, чем нравится?(*укучыларның җавабы)*
– Ә бу нәрсә? (*деревня*)
– Авыллар нинди булалар? А деревни какие, по сравнению с городом? (*кечкенә)*
– Син авылда булдыңмы? Анда кем яши? Ты бывал в деревне? Кто там у тебя живет? *(укучыларның җавабы)*
– Укучылар, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? Ребята, сегодня на уроке мы о чем будем говорить? Какая наша тема? (*Город.Деревня*)
– Әйе. Дөрес. Ә ничек соң алар татар теленә тәрҗемә ителәләр? Тагын нинди яңа сүзләр өйрәнербез? Беләсегез киләме? Но, а как же они переводятся на татарский язык? Как же они правильно произносятся на татарском языке? Какие еще новые слова мы узнаем на уроке? Интересно узнать? (*Әйе*)
– Укучылар, дәрестә яхшы эшләгез, актив булыгыз. Киттек!

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

***<u>Беренче күнегү.</u>***

**1. “Яңа сүзләр”.**

<u>Аудио:</u> шәһәр, авыл, урам, юл, бина, кибет, урман, елга.

- Укучылар, тыңлыйбыз.

Аудиоязма бер тапкыр тыңлана. Аннан укытучы карточкалар ярдәмендә сүзлек эшен алып бара. Мәсәлән, укучыларга шәһәр рәсемен күрсәтә, сүзне русча һәм татарча әйтә, укучылар татарча тәрҗемәсен бергә кабатлыйлар: город-шәһәр, деревня – авыл...

Аннан аудионы яңадан тыңлата, карточканы күрсәтеп бара, ә укучылар диктор артыннан кабатлап баралар.

**2.”Бу нәрсә?”уены**.

Яңа лексиканы ныгыту өчен, рәсемле карточкалар белән эшне дәвам итәбез. Укытучы рәсемле карточкаларны күрсәтә, укучылар чиратлап яки кул күтәреп, сүзләрне әйтеп баралар.

- Хәзер, укучылар, алышынабыз (меняемся) мин сүзләрне әйтәм, сез карточкаларны күрсәтәсез *(укучыларның алларында үз рәсемле карточкалары ята.)*

– “Укучы–Укытучы” уенын уйныйбыз.(*Бер укучы укытучы була. Югарыда укытучы башкарган эшләрне укучы эшли).*

**3.“Шәһәрләр–авыллар”**

Исемнәрнең күплек санын кабатлап китү, кушымчаларын искә төшерү.

– Укучылар, бу нәрсә? (*шәһәр)* (Слайд )

– Ә болар нәрсәләр? (*шәһәрләр)*

– Бу нәрсә? (*авыл)*

– Болар нәрсәләр? (*авыллар)*

– Дөрес, когда много предметов, мы к словам что добавили*? (-лар/-ләр)* <u>(Карточка)</u>

– Әйе, дөрес. Когда слово мягкое, то добавляем -ләр, когда слово твердое

–лар.

Укучылар сүзләрне кушымчалар белән әйтеп чыгалар: *кибет-ләр, юл-лар, елга-лар,бина-лар*

– Укучылар, ә бу нәрсә? (*урман)*

– Болар нәрсәләр? (*урманнар)*

– Почему здесь не -лар/-ләр добавили, а -нар/-нәр? (*потому что слово заканчивается на <u>Н)</u>***(**<u>Карточкалар)</u>

– Бу нәрсә? (*урам)*

– Болар нәрсәләр? *(урамнар)*

<u>**Икенче күнегү.**</u>

**1.Тыңла һәм истә калдыр.**

<u>**Аудио:**</u> Бу шәһәр. Шәһәр зур. Шәһәрдә урамнар киң.

Бу авыл. Авыл кечкенә. Авылда урамнар тар.

а) Аудио 1 тапкыр тыңлана. Сүзлек өстендә эш алып барыла. Укытучы тәрҗемә итә: киң–широкий, тар– узкий (ишарәләр белән күрсәтә: киң – кул-

ларны җәябез, тар – кулларны якынайтабыз). Укучылар белән яңа лексиканы ишарәләр белән күрсәтеп, кабатлыйбыз.

б) Аудио тагын бер тапкыр тыңлана. Аннан укытучы тактада рәсемнәр курсәтеп (киң урам һәм тар урам рәсемнәре), яңа лексиканы татарча әйтә, укучылар русча тәрҗемәсен әйтәләр.

в) **”Сорау уйла**!” Укучылар шул рәсемнәргә сораулар уйлыйлар һәм җавап бирәләр. Мәсәлән, бу урам нинди? Бу урам киңме? Һ.б.

**2.“Кем матуррак сөйли?”** Укытучы сыйныфны ике командага бүлә. Беренче команда шәһәр турында сөйли, икенче команда авыл турында сөйли. Укучылар яхшы, матур сөйләүчене сайлап алалар.

– Кем бик матур, дөрес сөйләде? (*укучыларның җаваплары)*. Бу командага көчле алкышлар!

**3. “Ишарәләр белән күрсәт!”** Укытучы текстны истә калдыру максатыннан лексик берәмлекләрне ишарәләр белән күрсәтә һәм укучылар белән берничә тапкыр аларны кабатлап, ныгыта: “шәһәр” – кулларны югары күтәрәләр, “авыл” – баш өстендә “түбә” өчпочмак ясыйлар, “зур” – зур түгәрәк, “кечкенә” – кечкенә түгәрәк ясыйлар; “тар” – кулларны бер–берсенә якынайталар, “ киң” – кулларны як–якка җәяләр.

– Хәзер шул текстны ишарәләр белән күрсәтеп, сөйлибез (*бер укучы сөйли, икенче укучы ишарәләр белән күрсәтеп бара)*.

**Ял итү:**

Укытучы аудиоязманы куя. Укучылар басып, текстны диктор артыннан ишарәләр белән күрсәтеп, сөйләп баралар.

**<u>Өченче күнегү</u>**

**1. “Диалогны тыңла!”** Укытучы аудиоязманы бер тапкыр тыңлата, аннан сүзлек өстендә эш алып бара: “яши” берәмлегенең тәрҗемәсен әйтә, һәм бу сүзне укучылардан тартым белән төрләндереп, шулай ук ишарәләр белән күрсәтеп, кушымчаларга басым ясап, кабатлата ( мин яшим–укучы үзенә күрсәтә. Син яшисең – укучы партадашына күрсәтә. Ул яши –артта утырган сыйныфташына күрсәтә).

**Аудио:**

- Син кайда яшисең?
- Мин шәһәрдә яшим. Ә син кайда яшисең?
- Мин авылда яшим.

**2.“Тәрҗемә ит!”** Укучылар диалогны чылбыр буенча тәрҗемә итәләр.

**3. “Син кайда яшисең?”** Укытучы ике укучыга шәһәр һәм авыл рәсемнәрен бирә. Укучылар аудиоязмадагыча диалог төзеп, сөйлиләр.

**4. “Нинди?”** Укытучы шәһәр, авыл, юл, елга, бина, урам рәсемнәрен күрсәтә. Укучылар предметның нинди икәнен әйтергә тиешләр. Мәсәлән, урам киң, матур, озын, зур.

**Теманы ныгыту.**

1).**”Туп!” уены.** Яңа лексик берәмлекләрне һәм структураларны кабатлап китү максатыннан, укытучы укучылардан туп ярдәмендә тәрҗемәләрен сорый: сүзне русча әйтеп, тупны укучыга бирә, укучы

тәрҗемәсен әйтеп, кире укытучыга тапшыра. Әгәр тәрҗемәне әйтә алмаса, партадашы булыша. Шулай ук татарчадан русчага тәрҗемәне сорарга була.

2).**”Дөрес – ялгыш” уены**. Укытучы укучыларны ике төркемгә бүлә. Такта алдына ике урындык куя. Бер урындык “дөрес”, икенчесе “ялгыш”. Укытучы карточкалар ярдәмендә дәрестә өйрәнгән лексиканы дөрес яки ялгыш әйтә. Укытучы дөрес әйтсә, чираттагы укучы “дөрес” урындыгына, сүзнең тәрҗемәсен әйтеп, барып утыра. Укытучы ялгыш әйтсә, укучы “ялгыш” урындыгына утыра һәм дөрес җавапны бирә.

**Эш дәфтәре белән эш.**

- Укучылар, эш дәфтәрен ачыгыз, 8 нче күнегүне эшлибез. (*Укучылар тиешле рәсемнәрне уклар белән тоташтыралар.)*

**III.Рефлексия.**

**1. Рефлексив кабатлау:**

- Укучылар, бүген без дәрестә нәрсәләр турында сөйләштек? О чем сегодня на уроке говорили? *(шәһәр, авыл турында)*

- Нинди яңа сүзләр белдек? Какие новые слова узнали на татарском языке?

Аннан дәрес башындагы презентацияне яңадан күрсәтә һәм укучыларга темага кагылышлы сораулар бирә:

- Бу шәһәрме?(*юк, бу авыл)*
- Авылда урамнар нинди?(*авылда урамнар тар*)
- Бу нәрсә? *(шәһәр)*
- Шәһәрдә урамнар тармы?(*юк, шәһәрдә урамнар тар түгел, шәһәрдә урамнар киң)*
- Бу нәрсә? (*бина*)
- Биналар нинди? (*зур, матур*) һ.б.

**2.Бәя. Үзбәя.**

- Бүген дәрестә бик яхшы эшләдегез! Сез тырыш укучылар!

Дәресебез тәмам. Сау булыгыз!

# ТӨРЛЕ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР НИГЕЗЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ

## СЫЙНЫФТАН ТЫШ УКУ. АБДУЛЛА АЛИШ ӘКИЯТЕ. УТЛЫ ЙОМЫРКА

***Хәмидуллина Люция Сәетгәрәй кызы,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*169 нчы урта мәктәпнең югары квалификацион*
*категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Башлангыч сыйныфта Альберт Яхин методологиясе нигезендә дәрес эшкәртмәсе тәкъдим ителә. Язучы Абдулла Алиш иҗатын өйрәнгәндә, әлеге дәрес сыйныфтан тыш уку буларак икенче сәгать итеп үткәрелә.

**Дәреснең технологик картасы**

| **Предмет** | **Әдәби уку** |
|---|---|
| Тема | Каршыякларның урын алыштыруы. Өйрәнелә торган әсәр: Абдулла Алиш әкияте. Утлы йомырка. |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | Ш.: Укучыларның тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавы һәм кабул итүе, аларда әйләнә-тирәгә шәхси караш формалаштыру аша әсәрнең тәрбияви әһәмиятен аңлау.<br>М.: Халык иҗатына мөрәҗәгать итү аша белем алу, шуның аша билгеле бер эшчәнлекне оештыру, үтәлгән эшкә бәя бирү.<br>П.: Әкият эчтәлеген өйрәнү аша каршы якларның урынын алыштыру алымын табу, тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлау, материалны модельләштерү. |
| Дәреснең тибы | Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру. |
| Эшне оештыру | Фронталь, төркемдә. |
| Чыганаклар | 1. Утлы йомырка. Абдулла Алиш әкияте. 2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. ТКН, 1981. 3. Мәхмүтов Хуҗи. Язылмаган кануннар. Казан, 1995. 4. Әдәплелек дәресләре. Көч һәм рух тамырлары. “Мәгариф” нәшрияты, 2000. |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|
| Оештыру<br>Мотивлаштыру | Уңай психологик халәт тудыру. Бер сәгать фикер өйрәтү җитмеш ел акыл җыюдан файдалырак дигән гыйбарә бар. Фикерләүнең кеше сәламәтлеге, аң үсеше өчен әһәмиятле булуын беләбез. Без бүгенге дәрестә дә шул юнәлештә эшләвебезне дәвам итәрбез. (*Дәреснең темасы һәм дидиактик максаты әйтелә*). | Сыйныф эшкә әзерләнә. | Фикер туплау, шуның аша билгеле бер эшчәнлекне оештыру.<br>Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү. |
| Белемнәрне актуальләштерү | Алда үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне искә төшерү.<br>1. Төркемнәрдә киңәшеп, искә төшерегез әле: экиятләргә ничек анализ ясыйбыз? | Көтелгән җавап: вакыйгаларга бүлеп каршы якларны билгелибез, нәтиҗә ясыйбыз. | Тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлау.<br>Укучыларда әйләнә-тирәгә шәхси караш формалаштыру. |
| | 2. Сүзлек өстендә эш. (Экранда укытучы аңлатуында бирелә) | Укучылар укыйлар:<br>Җим – кош-кортлар өчен махсус әзерләнгән ризык.<br>Харап булу – бәхетсезлеккә төшү, берәр күңелсез хәлгә очрау.<br>Текәлеп карау – бик нык игътибар итеп, туп-туры карау .<br>Колаклар ут кебек яну – колак кызару. | |
| | 3. Өй эшен искә төшерү. | Укучы искә төшерә. 1.Тапкырлык турында 4-5 мәкаль табарга. (*ярым иҗади)*<br>2.Әкият нигезендә рәсем ясарга. (*иҗади*)<br>3.“Утлы йомырка” әкиятен укып килергә. (мәҗбүри) | |
| Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү | Бүгенге дәрестә без Абдулла Алишның “Утлы йомырка” әкиятен өйрәнәбез. Киңәшегез әле, эшне ничек оештырырбыз икән? | Көтелгән җавап:катнашучыларны табарбыз, әкиятны вакыйгаларга бүләбез; сюжетын үз сүзләребез белән сөйләрбез; әкиятнең ни турында булуын - темасын | Уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп вакыйгаларны аерып алу нигезендә җавап формалаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ачыкларбыз; авторның укучысына җиткерергә теләгән фикерен табарбыз. | Фикерне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>Эшчәнлекне контрольгә алу. |
| | Әкият эчтәлеген сөйләгез. | Берәү сөйли, башкалар тулыландыра | |
| | Әкият эчтәлеген вакыйгаларга бүлегез. | Тактада һәм дәфтәрләрдә түбәндәге схема нигезендә эшчәнлек эчтәлеге модельләштерелә. Көтелгән җаваплар:<br>1) Әбинең ак тавыгы бар.<br>2) Йомырка югалу.<br>3) Әбинең текәлеп карап сөйләве.<br>4) Малайның серне чишүе.<br>5) Харап булудан нык курку.<br>6) Әбинең серне чишүе. | |
| Проблеманы (авырлыкны) чишү проектын төзү | Вакыйгаларны модельгә салыгыз. | | Тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлау, материалны модельләштерү. |
| Белемнәрне беренчел ныгыту | Вакыйгаларга тулырак тукталыйк һәм әкиятнең эчтәлеген ачыйк. Биремнәр. (*Җаваплар экранда бирелә бара).*<br>Беренче вакыйганы тулысынча сөйләгез. Вакыйгага кыскача исем бирегез.<br>Икенче вакыйганы тулысынча сөйләгез.<br>Өченче вакыйганы тулысынча сөйләгез.<br>Дүртенче вакыйганы тулысынча сөйләгез<br>Бишенче вакыйганы тулысынча сөйләгез.<br>Алтынчы вакыйганы тулысынча сөйләгез. | Берәү сөйли, башкалар тулыландыра. Укучыларның җаваплары.<br><br>1) Көтелгән җавап: ак тавык.<br>2) Көтелгән җавап: йомырка югалу.<br>3) Көтелгән җавап: хәйлә.<br>4) Көтелгән җавап: курку.<br>5) Көтелгән җавап: нык курку.<br>6) Көтелгән җавап: сер чишелү. | Әкият эчтәлеге аша тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлау.<br>Билгеле бер эшчәнлекне оештыру, үтәлгән эшкә бәя бирү. |
| Сәламәтлекне ныгыту минуты *(күзләргә күнегүләр ясау)* | | | |
| Ныгыту | 1.Вакыйгалар бер-берсенә охша- | Көтелгән җавап: охшаган да, охшамаган | Укучыларның тормыш |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ганмы?<br>2.Охшаш вакыйгаларны берләштерегез һәм бер исем бирегез.<br>3. Әби куркуын күрсәтә белде, курку малайга чүчте. Малайның куркуга төшүенең сәбәбен әйтегез.<br>4. Дәреснең темасын искә төшерик. Каршылыклы яклар кемнәр алар?<br>5. Каршы якларның урын алыштыруында әбинең роле зур булды. Санап чыгыгыз әле, әби нинди сыйфатларга ия? | да.<br>Көтелгән җавап: курку һәм хәйлә.<br>Көтелгән җавап: әби хәйләсе.<br>Көтелгән җавап: әби һәм малай.<br>Көтелгән җавап: акыллы итеп уйлый белә, чагыштыра, хәйлә кора белә.<br>Теманың эчтәлеген ачу өчен әкият кулландык. Язучы үзенең иҗатында халкыбызның элек-электән акыллы, укымышлы, зирәк кешеләрнең хөрмәткә лаек булуын күрсәтә белгән. Әлеге әкият моңа мисал булып тора. | кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавы һәм кабул итүе, аларда әйләнәтирәгә шәхси караш формалаштыру аша әкиятләрнең тәрбияви әһәмиятен аңлаулары. |
| Нәтиҗә | 1. Әкият нәрсә турында, темасын ачыклагыз. Әби өлкән яшьтә булса да, үзенең теләгәненә ирешә алды. Әлеге эшнең нәтиҗәләрен атагыз?<br>2. Авторның укучысына җиткерергә теләгән фикерен табарбыз. Әкиятнең эчтәлеге нәрсә турында?<br>3. Үзегезгә ошаган өзекләрне сәнгатьле итеп укып күрсәтегез. | Көтелгән җавап: әби тормышны күп күргән, акыллы, тәҗрибәле, уйлый белә, чагыштыра, хәйлә кора белә һ.б.<br>Көтелгән җавап: каушап калмасаң, башыңда акылың булса, син тормышта авыр очракларда да җиңүгә ирешә аласың (*экранда җавап чыга*). Мәкальләр нигезендә нәтиҗә ясала. Мисаллар. 1) Кара эшне караңгыда эшләсәң дә яктыга чыгар. 2) Кыңгыр эш кырык елдан соң дә беленә. 3) Хыянәтле кеше куркак була. 4) Үз гаебен таныган кеше – зур батыр. 5) Хәйләсез дөнья файдасыз, һ.б.<br>Нәтиҗәне дәфтәрләргә язалар.<br>Укучылар үзләренә ошаган өзекләрне сәнгатьле итеп укып күрсәтәләр. | Укучыларның тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавы һәм кабул итүе, аларда әйләнәтирәгә шәхси караш формалаштыру аша әкиятләрнең тәрбияви әһәмиятен аңлаулары.<br>Үз уңышлары / уңышсызлыклары сәбәпләре турында фикер йөртүләре.<br>Үз эшчәнлекне контрольгә алулары. |
| Рефлексия | 1. Нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә). Ничек эшләдек? (*чишү юллары искә төшерелә*). Нинди нәтиҗә ясадык? | Сюжетын сөйләдек, вакыйгаларга бүлдек, охшаш вакыйгаларны берләштердек, каршы якларның бәйләнешен таптык, әкиятнең эчтәлеген ачыкладык. | Үз уңышлары / уңышсызлыклары сәбәпләре турында фикер йөртүләре.<br>Язучы иҗаты аша белем алу, билгеле бер эшчәнлекне оештыру аша үтәлгән эшкә бәя |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | бирү. |
| Белемнәрне бәяләү | 1. Дәрестәге эшчәнлеккә үзбәя.<br>2. Соңгы нәтиҗә, укытучы бәясе. | Укытучы критерий бирә, шул нигездә балалар үз-үзләренә билге куялар, ягъни үз эшчәнлекләренең кайсы критерийга туры килүен билгелиләр. | Универсаль критерий:<br>Нәрсә эшләргә тиеш идек? Ничек эшләдек? Нинди нәтиҗә ясадык? дигән сорауларга җавап алу.<br>а) тактадан, эш дәфтәрләренән файдала-нып сөйләп бирә алса - «3»;<br>б) үзлегеннән һәм онытканда карап алып сөйли алса - «4»;<br>в) терәк конспекттан файдаланмыйча гына сөйли алса - «5». |
| Өй эше | Өйгә эш 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә. | 1. Алдагы дәресләрдән дә чыгып, әдәбият теориясен кабатларга, контроль эшкә әзерләнергә.<br>2. Үз тирәгездә шундый күренешләр белән очрашканыгыз булмадымы, мисаллар белән дәлилләгез..<br>3. Иҗади эшчәнлеккә – рәсем ясагыз. | Репродуктив, конструктив, иҗади эшчәнлеккә нигезләнгән. |
| Энергизатор | Алдыгызда открыткалар. Дустыгызга атап иң матур теләгегезне шунда языгыз әле. | Барысы да баса. Теләкләрне тәртип буенча тапшыралар. Җитәкләшәләр. Бергә: “Без бүген дә булдырдык!” | Әйләнә-тирәгә шәхси караш формалаштыру. |

## ЗАТ АЛМАШЛЫКЛАРЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ. КИЛЕШЛӘР БЕЛӘН ТӨРЛӘНЕШЕ

(6 нчы сыйныф, татар төркеме)

***Денисова Гөлүсә Рәшид кызы,***
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 37 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, "Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы" Бөтенроссия конкурсы номинациясе җиңүчесе*

**Максат:**

1) **Дидактик максат:** зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнү үзенчәлеген үзләштерә белүенә шартлар тудыру.

2) **Үстерелешле максат:** укучыларның уйлау (фикерләү), логик фикерләү (гомумиләштерү) үсеш өчен җирлек тудыру.

3**) Тәрбияви максат:** төркемнәрдә дустанә мөнәсәбәттә белем күнекмәләре үсеше өчен җирлек тудыру.

**Предметара бәйләнеш**: татар теле, инглиз теле, рус теле.

**Дәрес тибы**: яңа белемнәр ачу.

**Танып белү эшчәнлеген оештыруда кулланылган чаралар:** Максимов Н.В, Хәмидуллина М.З. Татар теле: рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 6 нчы сыйныфы өчен уку әсбабы. – Казан: 2015, электрон һәм акбур тактасы; эш дәфтәрләре; контроль үлчәү материалы (карточкалар),QR кодлар.

**Танып белү эшчәнлеген оештыру формасы:** фронталь, индивидуаль, парлап, төркемнәрдә.

**Танып белү эшчәнлеген оештыру методы:** проблемалы сорау, тикшерүле метод.

**Планлаштырылган нәтиҗәлелек:**

**Предмет нәтиҗәлеге:** зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнү үзенчәлеген танып белү.

**Метапредмет нәтиҗәлелеге:**

**а) регулятив –** уку мәсьәләсен китереп чыгару, зат алмашлыкларының үзенчәлеген ачыклау, рефлексия ясау, үзбәя куюда катнашу;

ә**) коммуникатив** – төркемдә эшләү барышында, аралашу күнекмәләре үсеше өчен җирлек тудыру; бер-берсен тыңлый, ишетә, фикерләрен дәлилле әйтә белү, башкаларның фикерен тулыландыру, өйрәнелгән материал нигезендә әдәби сөйләмне үзләштерү;

**б) танып белү –** өйрәнелгән материалны модельдә күрсәтү һәм модельдән файдаланырга өйрәнү.

**Шәхес буларак үсеш нәтиҗәлелеге** – социаль (иптәшләренә, үзүзләренә матур мөнәсәбәт), эмоциональ (үз кичерешләрен иптәшләре киче-

реше белән килештерә белү) үзүсеш өчен шартлар тудыру; үз эшчәнлекләрен адекват бәяләргә өйрәнү.

**Дәрес барышы**

**I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.**

1) Исәнләшү. Хәерле көн, кадерле укучылар! Татар теле дәресен башлыйбыз.

2) Уңай психологик халәт тудыру

Карагыз әле, балалар, тәрәзәдә язгы яктылык, кояш ничек матур елмая. Әйдәгез , без дә бер-беребезгә шулай елмаеп исәнләшик. Күрегез әле, класс бүлмәсе яктырып, җылынып та киткәндәй булды. Серлелеге, сафлыгы, якты кояшы белән яз хакимлек иткән март көнендә сезнең белән очрашуыма мин бик тә шатмын. Мин барыбызга да уңышлар телим. Бүгенге дәресебез эшлекле, күңелле, файдалы һәм дустанә мөнәсәбәттә узар дип ышанам.

3.) Белемнәрне тигезләү – актуальләштерү

Балалар, сезгә татар халкының бер мәкален укып китәсем килә :

Тел дигән дәрья бар, дәрья төбендә энҗе - мәрҗән бар. Белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр.

Балалар, тел дәрьясының гаҗәеп кыйммәтле, хикмәтле хәзинәсе нәрсә икән?

Фикер алышу. Нәтиҗә: белем – ул байлык, шуңа күрә безгә тырышып укырга кирәк. Укучылар, без тел гыйлеменең морфология бүлеген өйрәнәбез. Алдагы дәресләрдә алмашлык сүз төркеме белән таныштык. Алмашлыкларның ясалышын, төркемчәләрен беләбез. Хәзер сезгә аларны искә төшерергә кирәк булачак. Әйдәгез әле, өйрәнгәннәрне искә төшереп, тест эшләп алыйк. *(Тестны тикшерү өчен, мин пликкерс кушымтасын (приложениесен) кулланам, телефон аша кулларындагы кодлардан төшереп, җавапларын алам*).

**Слайд**

1. Алмашлык нинди сүз төркеме?
а) мөстәкыйль сүз төркеме;
б) бәйләгеч сүз төркеме;
в) модаль сүз төркеме.

2. Алмашлык дип нинди сүзләрне атыйлар?
а) предметны белдергән;
б) сөйләмдә исем, сыйфат, сан, рәвешләргә күрсәткән;
в) предметның билгесен белдергән.

2.Һәркем, беркем, һичкая - төзелеше ягыннан болар нинди алмашлыклар?
а) парлы алмашлыклар;
б) ясалма алмашлыклар;
в) кушма алмашлыклар.

3.Тезмә алмашлыклар ничек языла?
а) сызыкча аша;
б) һәр сүз аерым;

в) бергә кушып.

Укучылар, кайберләрегездә хаталар бар. Әйдәгез әле, тагын бер кат искә төшереп үтик. Игътибарыгызны электрон тактага юнәлтик әле.

**Слайд**

Кемнәрнең хаталары булды, зинһар өчен, игътибар белән тыңлап утырыгыз. Кем миңа алмашлыкның төшенчәсен әйтеп үтә?

**Көтелгән җаваплар :** исемне, сыйфатны, сан, рәвешне алмаштырып килә торган мөстәкыйль сүз төркеме.

Төркемчәләрен кем санап китә ?

**Көтелгән җаваплар:** зат, тартым, күрсәтү, сорау, билгеләү, билгесезлек, юклык алмашлыклары.

Ясалышлары ягыннан нинди алмашлыкларга бүленәләр?

**Көтелгән җаваплар:** тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә алмашлыклар.

Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

**Слайд**

Укучылар, сезгә үзем иҗат иткән “Сүзләр...” исемле шигыремне укып китәсем килә. Игътибар белән тыңлавыгызны, шигырьдә нәрсә турында сүз баруын ачыклавыгызны һәм кызыл төс белән язылган алмашлыкларга карап, бүгенге дәреснең темасын билгеләвегезне сорыйм.

Сезгә әйтәм! Сүзләр дә кешеләрдәй,
Аларның да шул, була төрлесе.
Яхшы, яман, гайбәт, гаделләре,
Тәмле сүзләр. Була төрткелесе.
Сүз белән яралап та була,
Сүз белән була дәвалап.
Бер сүз җитә юкка чыгарырга,
Телеңдәген әйт, син, гел уйлап!

Шигырь нәрсә турында?

**Көтелгән җаваплар:** сүзләр турында.

Ничек уйлыйсыз шушы шигырем белән мин сезгә нәрсә әйтергә теләдем икән?

**Көтелгән җаваплар:** әйтәсе сүзне уйлап әйтергә.

Бик дөрес, укучылар. Начар сүзләр әйтеп кешеләрне үпкәләтергә, рәнҗетергә ярамый. Һәр әйтәсе сүзегезне уйлап әйтегез. Шигырьдә нинди алмашлыклар кулланылган?

**Көтелгән җаваплар:** сезгә, син.

**Слайд**

Төркемчәсе ягыннан бу нинди нинди алмашлыклар?

**Көтелгән җаваплар:** зат алмашлыклары.

Нинди сорауларга җавап бирәләр?

**Көтелгән җаваплар:** кемгә? Кем?

Әйе, балалар, сорауларын дөрес билгеләдегез.

Бу нәрсә сораулары?

**Көтелгән җаваплар:** килеш сораулары.

Димәк, нинди нәтиҗә ясый алабыз?

**Көтелгән җаваплар:** зат алмашлыклары килеш белән төрләнә.

Дәресебезнең темасы нинди булыр дип уйлыйсыз?

**Көтелгән җаваплар:** зат алмашлыкларының үзенчәлекләре. Килеш белән төрләнеше.

Темадан чыгып, үзебезгә нинди максат куябыз инде?

**Көтелгән җаваплар:** зат алмашлыкларын килеш белән төрләндерә белергә.

Куйган максатыбызга ирешер өчен нәрсә эшләрбез икән укучылар?

**Көтелгән җаваплар:** күнегүләр, биремнәр эшләрбез.

Бик дөрес, бүгенге дәрестә без зат алмашлыкларының үзенчәлекләре белән танышырбыз, аларның җөмләдә кулланылышын карарбыз, сүзлек составын баетырбыз.

**Слайд**

Укучылар без ничә зат алмашлыгы беләбез. Кулларыгызны күтәреп җавап бирәбез.

**Көтелгән җаваплар:** мин, син, ул, без, сез, алар**.**

Татар телендә зат алмашлыкларының лексик составы зур түгел, алар барысы алты сүздән тора. Балалар зат алмашлыкларының парлашып килүен ничек аңлыйсыз?

**Көтелгән җаваплар:** берлек һәм күплек санда**.**

Мин - без

Син - сез

Ул - алар

**Слайд**

Әйдәгез әле, зат алмашлыкларын рус, инглиз телләренә тәрҗемә итик әле.

**Көтелгән җаваплар: I, we, you, you,he, she, it, they.**

**Я, мы, ты, вы, он, она, оно, они.**

Хәзер төркемнәрдә эшләп алыйк.

Беренче төркем, мин алмашлыгын кулланып, үзе турында ике җөмлә төзи. Икенче төркем, син алмашлыгын кулланып, дустына һәм таныш булмаган кешегә мөрәҗәгать итә.

Өченче төркем Гөлназ сүзен тиешле алмашлыклар белән алыштыра.

Тикшерәбез, һәр алмашлыкка анализ бирәбез. Нәтиҗә чыгарабыз.

**Слайд.**

Гөлназ – акыллы һәм тәртипле укучы, бик яхшы укый. Гөлназ дәресләргә һәрчак әзерлек белән килә. Гөлназны сыйныфташлары да ярата, укытучылары да мактый. Гөлназ яхшы дус та, Гөлназ һәрчак ярдәмгә әзер.

Әйдәгез, тикшерәбез. Димәк, нәтиҗә чыгарабыз. Син алмашлыгы урынына сез алмашлыгын нинди очракларда кулланабыз?

**Көтелгән җаваплар:**

- олы кешегә мөрәҗәгать иткәндә;
- белмәгән кешегә эндәшкәндә;
- берничә кеше белән сөйләшкәндә;
- ихтирам йөзеннән.

Мин алмашлыгын һәр җөмләдә дә куллансак, җөмләләребез ничек чыга?

**Көтелгән җаваплар:** мактану төсмерендә.

Алмашлыклар сөйләмне кабатлаудан коткаралар, аны матур һәм яңгырашлы итәләр.

Укучылар, ничек уйлыйсыз, зат алмашлыкларының мәгънәсе нинди икән, алар нәрсә белдерә?

**Көтелгән җаваплар:** мәгънәсе – сөйләшүдә катнашучы затларны белдерәләр.

**Слайд**

Кайсы зат сөйләүче?

**Көтелгән җаваплар:** мин, без.

Тыңлаучы зат кем?

**Көтелгән җаваплар:** син, сез.

Сөйләмдә катнашмый?

**Көтелгән җаваплар:** ул, алар.

**Слайд**

Әйдәгез, китапка мөрәҗәгать итик әле. Билгеләмәне кем укый?

Укучылар зат алмашлыклары сөйләмдә нинди кайсы сүз төркемен ачыклап килә дидек әле?

**Көтелгән җаваплар:** исем сүз төркемен.

Укучылар нинди сүз төркеме килешләр белән төрләнде?

**Көтелгән җаваплар:** Исем.

Башта килешләрне искә төшереп китик әле. Алар ничә һәм нинdiләр?

Әйдәгез, **укучы** сүзен килешләр белән төрләндерик.

**Көтелгән җаваплар: Б.к. укучы, и.к. укучының, ю.к. укучыга, т.к. укучыны, ч.к. укучыдан, у.-в.к. укучыда.**

**Слайд**

Балалар, эшебезне парларда башкарырбыз. Әлеге биремне интернет челтәрендәге LearningApps.org интерактив биремнәр конструкторы аша башкарырбыз. “Зат алмашлыклары“ дип аталган биремнәр җыелмасына кереп, беренче төркем **мин** алмашлыгын, икенче төркем **син** алмашлыгын, өченче төркем **ул** алмашлыгын төрләндерә. Эшебезне парларда башкарганга күрә, бер – берегез белән киңәшләшеп, уйлашып эшләгез. Уңышлар сезгә, балалар !

Зат алмашлыкларының үзенчәлекләрен ачыклау.

Таблицага карап, бергәләп нәтиҗә чыгарыйк.

Б.к. кем? мин, син, ул

И.к.кемнең? минем, синең, аның

Ю.к. кемгә? миңа, сиңа, аңа

Т.к. кемне? мине, сине, аны

Ч.к. кемнән? миннән, синнән, аннан

У-в.к. кемдә? миндә, синдә, анда.

Укучылар, әйдәгез әле, акыллы белем чыганагы - китапка мөрәҗәгать итеп, эшебезнең дөреслеген тикшерик. Зат алмашлыклары төрләнеше белән исемнәрнең төрләнеше арасында аерма бармы?

**Көтелгән җаваплар:** иялек һәм юнәлеш килешендә.

Укучылар, игътибар итегез әле, мин, син алмашлыкларының төрләнешендә нинди үзенчәлек бар?

**Көтелгән җаваплар:** иялек килешендә минем, юнәлеш килешендә миңа, сиңа.

Юнәлеш һәм төшем килешләрендә фонетик үзгәреш барлыкка килә:

Мин+га миңа

Син+га сиңа

Мин+не мине

Син+не сине

Иялек кушымчасы -ем (минем) тартым кушымчасына аналогия рәвешендә үзгәргән дип санала.

Ул алмашлыгының борынгы тамыры (-ән/ -ин) формасында булган. (Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Региональные реконструкции, 2002: 319). Килеш белән төрләнгәндә III зат алмашлыгының тамыры үзгәрә.

Укучылар, еш кына сөйләмдә миңга, сиңга, миндән, синдән дип сөйләшүләр очрый. Бу хаталарны булдырмас өчен, безгә килеш белән төрләнешне яхшы белергә кирәк.

**Ул** алмашлыгының төрләнешендә нинди үзенчәлек бар?

**Көтелгән җаваплар:** Ул алмашлыгының борынгы тамыры (-ән/ -ин) формасында булган. Килеш белән төрләнгәндә III зат алмашлыгының тамыры үзгәрә. Модельга игътибар итик әле.

**Слайд**

Физкультминут.

Мин (*укучы ике кулының да баш бармагы белән үзенә күрсәтә.*)

Син (*имән бармаклары белән як-якка күрсәтә.*)

Ул (*ике кулын сузып, алга күрсәтә.)*

Бердәм.

**Слайд**

Дәреслек белән эш.

259 нчы күнегү.

Җәяләр эчендәге алмашлыкларны тиешле килешләргә куеп күчереп языгыз.

I төркем

Сез еракта, ләкин (мин) күңелем һәрвакыт (сез) белән.

II төркем

Мин (сез) бервакытта да телемнән төшермим.

III төркем

Мин ( сез) сагынам, юксынам. (И. Гази)

2. Модельләштерү – ысул аерып алу, дәрестә башкарылган эшне кыскача язуда күрсәтү.

III. Рефлексия, бәя этабы.

Балалар, төркемнәрдә сөйләшеп, түбәндәге сорауларга җавап әзерләгез әле.

- нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә);
- ничек эшләдек? (чишү юллары искә төшерелә);
- нинди нәтиҗә ясадык? ($Н = н_1 + н_2 + н_3$), дигән сорауларга җавап бирү.

2. Дәрестәге эшчәнлеккә үзбәя.

Балалар, дәрестә эшләвегезне үзегез бәяләрсез, кем шушы модельгә карап сүзләрне куллана ала, ул үзенә “3”ле билгесе куя, кем модельгә карамыйча сүзләрне куллана ала, ул “4”ле куя, кемнәр модельгә карамыйча җөмлә төзи ала, алар “5”ле билгесе куя.

Кемнәр үзенә “5” ле билгесе куйды, кемнәр “4”ле, кемнәр “3” ле.?

“5” – ?

“4” – ?

“3” – ?

Рәхмәт. Үзбәя бик гадел булды.

3. Өйгә эш алу.

Өйгә эш 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә:

Репродуктив эшчәнлеккә – 169 нчы бит, 259 нчы күнегү (2нче һәм 4 нче җөмләләр)

Конструктив эшчәнлеккә – нокталар урынына алмашлыклар куеп, сүзтезмәләрне күчереп язарга:

... яратам.

... горурланабыз.

... бардыгыз.

... балкып тора.

... яшәгәннәр.

... сөйләдең.

Иҗади эшчәнлеккә - зат алмашлыкларын кулланып, кроссворд, ребус төзергә.

Бүген дәрестә нәтиҗәле, тырышып эшләгән укучыларга “5”ле билгесе куям. Дәресемне Р.Фәхреддин сүзләре белән тәмамлыйсым килә. “Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас вә мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрне дә үзегез җыярсыз”. Тәрбияле булып үсегез, балалар. Сау булыгыз!

# ТӘРТИП САНЫ
(4 нче татар сыйныфы)

***Галиева Гөлназ Шамил кызы,***
*Казан шәһәре Совет районы*
*Абдулла Алиш исемендәге 20нче*
*гимназиянең беренче квалификацион*
*категорияле татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы, “Иң яхшы татар теле һәм*
*әдәбияты укытучысы”, Бөтенроссия*
*конкурсы җиңүчесе*

**Максат**: тәртип саны белән танышу, ясалышын аңлау; укучыларның сөйләм телләрен, иҗади фикерләү сәләтен, танып-белү активлыгын үстерү; туган телгә, туган җиргә хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Предмет нәтиҗәләре:** тәртип саннарын тану, дөрес язу һәм сөйләү күнекмәләрен камилләштерү.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:** туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту; сөйләмне камилләштерүгә омтылу; җаваплылык хисе тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре:**

**Регулятив:** билгеле һәм билгеле булмаганны чагыштырып, уку бурычын кую; нәтиҗәле алымнарны сайлап, уку эшчәнлеген оештыра белү; үзтикшерү, үзбәя күнекмәләренә ия булу.

**Танып белү:** кирәкле мәгълүматны эзләп табу; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен таба белү; уй-фикерне язма һәм әйтмә формада аңлап оештыру.

**Коммуникатив:** аралашу максатына туры китереп, үз фикерен тулы һәм төгәл итеп җиткерә алу; төркемдә, парда, күмәк эшләгәндә хезмәттәшлек итә белү.

**Дәрес тибы:** яңа материалны аңлату.

**Предметара бәйләнеш:** әдәбият, әйләнә-тирәне өйрәнү, математика.

**Укыту методы**: проблемалы ситуация тудыру, тикшерү.

**Эшне оештыру формалары:** күмәк, индивидуаль, парда, төркемдә эшләү.

**Материал һәм җиһазлау:** дәреслек (Татар теле: туган телдә башл. гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен д-к., 4 нче с-ф. И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова, “МӘГАРИФ-Вакыт” нәшр., 2014. – 111 б.: рәс. б-н.), рәсем, карточкалар, ноутбук, мимио студио.

## Дәреснең технологик картасы

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| Оештыру, мотивлаш-тыру | Дәресне оештыру.Уңай психологик халәт тудыру.<br>- Исәнмесез, укучылар!<br>- Кәефләрегез ничек?<br>Уң як күршегезгә "бишне" биреп исәнләшегез әле. | Исәнләшәләр. Сорауларга җавап бирәләр. | КУУГ: сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. |
| Актуальләштерү | - Укучылар,"5"ле нинди сүз төркеменә карый?<br>- Сез сан турында ниләр беләсез?<br>- Кем бу җаваплар белән килешә? Кемдә башка фикерләр бар?<br><br>- Өй эшен, мимио студио пультлары белән тикшереп, микъдар саны хакында белгәннәребезне искә төшерик. | Укучылар сан турында белгәннәрен сөйләп бирәләр. Бер-берсен тулыландыралар.<br>Һәр укучы, электрон кушымта ярдәмендә, өй эшен яктырткан биремнәрне - тестны пультлар белән эшли, дөрес җавапны күреп, кагыйдәләрне карап, хаталарын төзәтә, уңыш картасына билге куялар. | ТБУУГ: өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү.<br>РУУГ: җавапларның дөреслеген контрольдә тоту.<br>КУУГ: коллектив фикер алышуда катнашу. |
| Уку мәсьәләсен кую | -Укучылар, һәр төркемнең өстәлендә карточкалар ята. Анда табышмаклар язылган. Җавабын табып, ак биткә язып куегыз. Алдыгызда яткан сүзлек, җыентыкларны кулланып, җавабыгызны дәлилләгез.<br>Ике иҗекле сүз ул.<br>Синонимы - атна.<br>Дусларыңа аңлат,<br>Бик тиз генә тап та.(....)<br><br>"Наступила" дигән сүзне<br>Сез татарча әйтегез.<br>"т" ны "д" га алыштырсаң<br>Килеп чыгар нинди сүз? (....)<br><br>Төшеп калган сүзне тапсаң,<br>Халык фикерләрен укырсың. | Язган җавапны күрсәтәләр, аңлаталар. Җиде сүзен тактага беркетәләр. | ШУУГ: үзбилгеләнү.<br>ТБУУГ: сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аңлау, төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүматны табу.<br>КУУГ: фикерләшү, сорау куя белү.<br>РУУГ: фаразлау, уку мәсьәләсен кую. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | “.. . кат үлчә, бер кат кис”<br>“... буын бабаңны бел”(...)<br><br>- Җавапны тапкач сөендегезме?<br>- Шатланып, сөенеп йөргән кеше хакында халык ничек әйтә?<br>Җиденче белән җиде сүзен чагыштырыгыз.<br>Алар икесе дә микъдар санымы?<br>Без бүген дәрестә нишләрбез? | - Әйе.<br>Тактадагы рәсемгә карап җавап бирәләр.<br>- Күкнең җиденче катында булу.<br>- Юк.<br>Дәрестә өйрәнәсе теманы фаразлап әйтәләр. | |
| Уку мәсьәләсен адымлап чишү | 1.Төшенчәне аңлау.<br>- Парларда **җиде** һәм **җиденче** саннарының охшаш һәм аермалы якларын табыгыз.<br>- Җиде саны - микъдар саны буларак төгәл исәпне белдерә, ә җиденче саны нәрсәне белдерә?<br>-Төгәлрәк җавапны табу өчен, такта янына кызларны чакырам.<br>Физкультура дәресендәге кебек итеп тезелеп басыгыз һәм татар телендә саналыгыз. Калганнар җиденче кызның исемен әйтегез.<br>- Моны белү өчен нишләдек?<br>- Дөрес. Саналу тәртибен белдергән -нчы,-нче кушымчасы ялганып ясалган; ничәнче? күпме? никадәр? соравына җавап биргән мондый саннар ничек атала?<br>- Дәреслектән кагыйдәне табып, укып чыгабыз һәм бер-беребезгә сөйләп, истә калдырабыз.<br><br>2.Тәртип саны кушымчаларын дөрес ялгау.<br><br>Тактада бирелгән микъдар саннарыннан тәртип саны ясап языгыз. Тәртип саннары кушымчаларын чагыштырып, аерманың сәбәбен аңла- | Тамыр, кушымчаларын күрсәтеп, сүзләрнең ясалышы ягыннан аермалы һәм охшаш яклар әйтелә. Сорауларының төрле булуы ачыклана.<br>Укучыларның җаваплары тыңланыла.<br><br>Укучылар саный, утыручы укучылар җиденче кызның исемен әйтә.<br>- Тәртип буенча санадык.<br><br>-Тәртип саны .<br>Дәреслек белән эш.<br><br>Дәфтәргә число, көн исеме, тәртип саннарын ясап язу, тикшерү, калын һәм нечкә кушымчаларның ялгану тәртибен аңлату.<br>Истәлекле даталар турында сөйләшү. | ШУУГ: тәртип саннарының әһәмиятен аңлау.<br>ТБУУГ: ысулны, кагыйдәләрне кулланып, тәртип санын тану, гамәлләр кылу.<br>РУУГ: тәртип санын тану ысулын төзү.<br><br>КУУГ: парда, төркемдә киңәшләшеп эшләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тыгыз. Бу саннар нинди истәлекле даталар белән бәйле икәнен ачыклагыз.<br><br>3.Тәртип саннарын тану ысулын чыгару.<br>Дәреслек белән эш.<br>- Абдулла Алиш хакында язылган көнегүне табыгыз.<br>- Беренче җөмләдә тәртип саннары бармы?<br>- Ничек таптыгыз?<br>Тактага ысулны язып кую. Парларда сөйләп ныгыту.<br>Ял минуты.”Кулъяулык” уены. | Укучылар текстны укыйлар. 1 нче төркем тәртип саннарын, 2 нче төркем тәртип саннары белән саналмышларны, 3 нче төркем тәртип саннарын табып, текст ахырындагы сорауларга да җавап әзерли.<br><br>Укучылар көйгә хәрәкәтләнәләр, берберенә кулъяулык тапшыралар. Көй туктаганда кемдә кулъяулык кала, шул микъдар саны әйтә, калганнар аннан тәртип санын ясый. | |
| Яңа белемнәрне беренченыгыту. | Тәртип саннарын сөйләмдә дөрес куллану.<br>- Сыйныф бүлмәсендәге сәгатькә күз салыгыз әле. Вакыт күпме?<br>Дөрес. Сәгатьнең теле 12 дән башлап 30 минутка кадәр урнашканда элек тәртип саны белән сәгатьне, аннан соң микъдар саны белән минутны әйтәбез.<br>Тактадагы биремне эшлибез.<br><br>-Тәртип саннарын тагын кайларда очратырга мөмкин, алар ни өчен кирәк? | 10 нчы 15 минут<br>Һәр укучы сәгать рәсеме һәм цифралар белән бирелгән вакыт аралыгын сүзләр белән язып куя, бер-берсенең эшен тикшерә, уңыш картасына билге куя.<br>Укучылар тәртип саннарын куллану очракларын әйтәләр, әһәмиятен ачыклыйлар. | ШУУГ: тәртип саннарының әһәмиятен аңлау.<br>ТБУУГ: биремне аңлау, нәтиҗә ясау.<br><br>РУУГ: җавапларны бәяләү, хаталарны аңлау, төзәтү. |
| Рефлексия | - Бүгенге дәрестә без нинди саннар хакында сөйләштек?<br>Тәртип саннары турында белгәннәрегезне төркемдә модельләштерегез.<br>Уңыш картасына карап үзегезгә билге куегыз. | Тактага модельләр беркетелә. Тикшерелеп, тулыландырыла. | ТБУУГ: гомумиләштерүләр ясау, нәтиҗә чыгару, мәгълүматны схема рәвешендә бирү.<br>РУУГ: җавапларны бәяли белү, үзбәя.<br>КУУГ: үз фикереңне дәлилле итеп җиткерү.<br>ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне бил- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | геләү. |
| Өй эше бирү | Өй эше бирү. Аңлату. Алдагы дәрескә кызыксыну уяту.<br>1.Тәртип саны турында кагыйдәләрне кабатларга, 33нче бит;<br>2.Күнегү 46, 35 нче бит.<br>3.Иҗади эш.* “Татарстан сулыклары” | Өй эшен язып алу. Аңлашылып бетмәгән өлешләрен ачыклау. | ТБУУГ: дифференциацияләнгән биремне аңлау.<br>РУУГ: эшчәнлекне оештыра белү, планлаштыру.<br>ШУУГ: табигатьне саклауның әһәмиятен аңлау. |

## ТАМЫР ҺӘМ КУШЫМЧАЛАР
(5нче сыйныф, татар төркеме)

***Кадыйрова Лилия Әмир кызы,***
*Казан шәһәре Киров районы*
*153 нче урта гомуми белем мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар теле дәресенең технологик картасы**

| | |
|---|---|
| Максат | Тамыр Һәм кушымчалар турында белемнәрне ныгыту, тулыландыру. |
| Дәрес мәсьәләләре | 1. Белем бирү: укучыларның тамыр һәм кушымчалар белән таныштыру, кушымчаларның төрләре белән таныштыру, укучыларнын фикер йөртә белү сәләтен үстерүне дәвам итү.<br>2. Фикерләү сәләтен үстерү: логик фикерләү, уйлау сәләтен, уку активлыгын, диалогик, монологик сөйләмне үстерү.<br>3.Тәрбияви: Изгелек эшләү – изге эш булуына инану. |
| Көтелгән нәтиҗә | Танып белү: Яхшыны яманнан аера белү, изгелек эшләү.<br>Коммуникатив: класс белән эшләгәндә сыйныфташлар фикерен исәпкә алып эш итү.<br>Шәхси: дәрескә уңай мөнәсәбәт һәм кызыксыну формалаштыру. |
| Предметара бәйләнешләр | Әдәбият |

| | |
|---|---|
| Чыганаклар<br>-төп<br>-өстәмә | Дәреслек: Татар теле: Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең татар төркемендәге 5нче с-фы өчен дәреслек/Ф.Ф.Харисов,Ч.М.Харисова. - Казан: Мәгариф, 2012.<br>Интерактив такта, проектор, ноутбук, теоретик материаллар белән презентация, таратма материаллар. |
| Эш урынын оештыру | Индивидуаль, фронталь, парларда эшләү. |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Һәр этапның өйрәтү һәм үстерү биремнәре** | **Универсаль уку эшчәнлеге** | **Һәр этапның диагностик биремнәре** |
|---|---|---|---|---|---|
| Оештыру, мотивлаштыру. Максат: яңа материалны үзләштерүгә кызыксындыру тудыру. | Исәнләшү, дәресне оештыру. Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру. | Сыйныфны әзерләү. Укучылар бер-берсен сәламлиләр. | Ана телебездә камил сөйләргә, үз фикереңне белдерергә өйрәнү. | *Шәхси*: эшчәнлекне башкаруга әзерлек, сорауларга җавап бирү өчен мәгълүмат туплау.<br>*Танып белү*: белемнәрне камилләштерү. | Сүз ясалышы бүлегендә нәрсәләр өйрәнелә? |
| Актуальләштерү. Максат: яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру. | Укучыларның тирәк белемнәрен яңадан барлау һәм өстәмәләр кертү. | Укучылар әзерләп килгән сорауларын бирәләр. | Сорауларга дөрес җаваплар. | *Танып белү*: алган белемнәрне кабатлау. | Ясалышлары ягыннан нинди кушымчалар була? Нәрсә ул тамыр? Нәрсә ул кушымча? |
| Физкультминут Максат: физик һәм рухи ял итү, яңа белем туплауга әзерлек булдыру. | Күнегүләрне күрсәтү, аңлату.<br>” Ояңны тап” уены | Укытучы артыннан күнегүләрне кабатлыйлар. | Музыка куела. | *Шәхси*: шәхесара мөнәсәбәтләр урнаштыра белү; танып-белү: үтәлергә тиешле биремнәрне төрле чаралар ярдәмендә белдерү.<br>*Регулятив*: нинди юнәлештә камилләшү зарурлыгын анлау.<br>*Коммуникатив:* иптәшләреңә карата яхшы мөнәсәбәт бел- | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | дерү. | |
| Яңа материалны өйрәнү, уку мәсьәләсен кую. Максат: яңа белемнәрне кабул итү. | Яңа белемнәр кабул итүне оештыру. | Яна белемнәрне алу. | Бирем дәреслектәге күнегү ярдәмендә үтәлә. | *Шәхси*: белем алуда уңай мотивация формалаштыру шарты буларак, яңа эшчәнлек төрләрен үзләштерү.<br>*Танып белү*: универсаль, логик гамәлләрне аерып ала белү.<br>*Регулятив*: проблеманы аерып ала белү;<br>*Коммуникатив*: үз фикерләрен әңгәмәдәшенә җиткерә алу, сөйләм телен үстерү. | Кушымчалар нинди функция үти? |
| Беренчел ныгыту. Максат: яңа белемнәрне дәреслектәге күнегүләр ярдәмендә ныгыту мөмкинлеге булдыру. | Укучыларны биремне үтәү ысуллары белән таныштыру.Укучыларның биремнәрне ничек үтәүләрен күзәтү. | Бу сүзләрнең кайсы кисәкләре уртак?<br>Эшлә, эшче, эшлекле; белә, белемле, белгеч, белдекле; күңелле, күңелсез, күңелләр.<br><br>Кушымчалар өстәп языгыз:<br>Мин иртән торды... һәм тәрәзә... карады... . Урам... кар яуган. Бала... кар тәгәрәтеп уйный.. . Минем дә уйныйсы... кил... . Мин киен... алар янына чыкты... .<br>Җөмләләр дөрес бул- | Таратма карточкалардагы биремнәрне төркемнәрдә эшлиләр, ян-як парларының эшләренә бәя бирәләр. | *Танып белү:* төшенчәләрнең асылына төшенү, сорауларга төгәл җавап формалаштыру.<br>*Коммуникатив*: үз фикереңне әңгәмәдәшеңә җиткерә алу, әңгәмәдәшеңнең эшенә бәя бирә белү. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сын өчен нәрсәләр өстәдек? | | | |
| Мөстәкыйль (практик контроль) эш.<br>Максат: яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану мөмкинлеге булдыру. | Мөстәкыйль яки парлап башкарыла торган биремнәрне аңлату. | Биремнәрне мөстәкыйль рәвештә телдән башкару. Авырсынган очракта парлап башкарырга мөмкин. | Дәреслектән 250 нче күнегү үтәлә. | *Шәхси*:иҗади процесста катнашу;<br>*Танып белү*: кирәкле мәгълүматны эзләү;<br>*Регулятив*: биремне үтәүдә аеруча нәтиҗәле ысул сайлау.<br>*Коммуникатив*: эшлекле мөнәсәбәт урнаштыру, нәтиҗәле хезмәттәшлек итү. | Нинди килеш кушымчаларын беләсез? Нинди тартым кушымчаларын беләсез? Нинди зат-сан кушымчаларын беләсез? |
| Нәтиҗәләрне бәяләү.<br>Максат: белем дәрәҗәсен ачыклау. | Дәрестә төркемнәрнең һәм аерым укучыларның аеруча активлыгын билгеләү. | Укучылар үзләренә бәя бирәләр. | Изгелек турында әңгәмә. | *Шәхси*: нәтиҗә ясый, карар кабул итә белү.<br>*Танып белү*: үз-үзеңә бәя бирә белү.<br>*Коммуникатив*: сыйныфташыңны тыңлый белү | |
| Рефлексия. Максат: алган белемнәрне бәяләү | Дәрестә алган яңалыкларны кабат искә төшерергә булышу. | Дәрестә алган яңалыкларны санап чыгалар. Сорауларга җавап бирәләр. | Дәрестә алган яңалыклар, яңа белемнәр турында әңгәмә корыла. | *Шәхси*:үз эшчәнлегеңә бәя бирү сәләте.<br>*Танып белү*: белемнәрне эзлекле рәвештә бәяләү.<br>*Регулятив:* белемнәрне тәртипкә салу, үзләштерелгән һәм үзләштерергә тиешле материалны тану.<br>*Коммуникатив*: үз фикереңне аңлаешлы итеп җиткерә белү. | |
| Дәресне йомгаклау. | | | | *Шәхси:* | Ни өчен кешеләр изге- |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Максат: алган белемнәрнең тормышта куллану әһәмиятен ачыклау. | | | | мөнәсәбәтләрдә һәм социаль рольләрдә ориентлаша белү.<br>*Танып белү*: фикер үстерелешен дәлилләүнең логик чылбырын төзү.<br>*Регулятив*: нинди юнәлештә камилләшү зарурлыгын ачыклый белү.<br>*Коммуникатив*: әйләнә-тирәдәгеләр белән продуктив уртак гамәлләр оештыра алу. | лек эшләргә тиешләр? Усаллык аша матурлыкка килеп буламы? |
| Өй эше, тәкъдимнәр. | Өй эшен башкару ысулларын аңлату. Өй эшен укучыларга ике вариантта тәкъдим итү. | Үзләренә ошаган вариантны сайлыйлар һәм көндәлекләренә язалар. | а)252, 254нче күнегү.<br>б) “Тамыр һәм кушымчалар дөньясында” дигән темага кечкенә генә хикәя төзегез. | *Шәхси*: тормышта үз урыныңны табарга әзерләнү.<br>*Танып белү*: алган белемнәрне мөстәкыйль тулыландыра белү.<br>К*оммуникати*в: өй эшенә кагылышлы фикер алышуда катнашу. | |

# ЭНДӘШ СҮЗСЕЗ ЭШ КӨЙСЕЗ. ЭНДӘШ СҮЗЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ҖӨМЛӘДӘГЕ УРЫНЫ, АЛАР ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ

(8 нче сыйныф, татар төркеме)

***Гобәйдуллина Зөлфия Равил кызы,***
*Казан шәһәре Мәскәү районы*
*9 нчы гимназиянең татар*
*теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:** эндәш сүз турындагы белгәннәрне системага салу һәм өйрәнүне дәвам итү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Метапредмет нәтиҗәләре**:

танып белү: язма һәм телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү; өлешләрдән бербөтенне төзи белү; гомумиләштерү.

коммуникатив: үз карашыңны, фикереңне формалаштыру; бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килә белү; әңгәмәдәшкә сорау бирә һәм җавабын тыңлый белү; төп фикерне аерып ала белү.

регулятив: ку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның буенча эшләү; куелган мәсьәлә буенча үз эшчәнлегеңне планлаштыру.

**Предмет нәтиҗәсе:** эндәш сүзләр турында өйрәнгәннәрне ныгыту, камилләштерү (эндәш сүзләрнең җөмләдәге урынын, алар янында тыныш билгеләрен өйрәнү).

**Дәрес тибы**: яңа белем ачу дәресе.

**Метод һәм алымнар:** әңгәмә, дәреслек белән эшләү, биремнәр үтәү, “Килешү картасы”, кластер, синквейн, кроссенс алымнары, Эр Ар Грайд структурасы.

**Принциплар:** фәннилек, аңлылык һәм активлык, аңлаешлылык һәм көч җитү, системалылык һәм эзлеклелек, укучыларның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алу, күрсәтмәлелек, аралашу.

**Дәрес материаллары һәм җиһазлар:** программа, дәреслек, кулланмалар, компьютер, экран, рәсем, мәкальләр язылган пазллар, кроссенс һәм Эр Ар Грайд структурасы өчен карточкалар.

**Предметара бәйләнеш**: татар әдәбияты, әйләнә-тирә дөнья, әхлак дәресе.

**Педагогик технология**: шәхескә юнәлдерелгән.

**Дәреслек:** Р.Ә.Асылгәрәева, Р.А.Юсупов, М.К. Зиннуров.Татар теле. 8 сыйныф. Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен). – Казан: Татар кит. нәшр., 2014.

**Укучылар белән эшләү формасы**: индивидуаль, фронталь.

**Дәрес барышы**

**1. Мотивлаштыру.**

***(Хәсән Туфанның «Кемнәр сез?» шигыреннән өзек Фоат Галимуллин башкаруында, аудиоязмада тыңлана*****).**

Кемнәр сез?

Безнең дәваммы?

Һәм безнең нәселме сез?

Тукайлар изге йоласын

Үтәргә әзерме сез?

Дәресебезне әдәбият галиме, укытучыларның укытучысы, кабатланмас тавышлы Фоат ага Галимуллинның бөек шагыйребез Хәсән Туфан шигыре аша мөрәҗәгате белән башладык. Күңел кылларыгызны тибрәттеме? Күңелегездә нинди җавап туды? Ә ни өчен кычкырып җавап бирмәдегез? (**чөнки миннән сорамадыгыз**) Димәк, сезнең күңелегезгә тагын да тирәнрәк үтеп керү һәм сездән җавап ишетү өчен, мөрәҗәгать үткән дәресләрдә өйрәнгән **Эндәш сүзләр** белән башланырга тиеш икән.

**II. Актуальләштерү этабы**.

Без бүген сезнең белән сөйләмебезнең бик әһәмиятле кисәге турында алган белемнәребезне тагын да камилләштерербез, аның җөмләдәге урынын, янындагы тыныш билгеләрен күзәтербез. Дәресебезне мин “Эндәш сүзсез эш көйсез” дип атадым. Сез минем белән бәхәсләшә аласыз. Ул бит җөмләнең оештыручы үзәге дә түгел, хәтта иярчен кисәге дә түгел. Ул нинди кисәк? (***Модаль кисәк***) Дәресебез бик кызу темпта барачак, ул бик кыска, безнең үзләштергән һәм үзләштерәчәк белемебезнең күләме бик зур. Әйдәгез, башлыйбыз.

Эшебезне бер гыйбрәтле хикәяттән башлыйк әле:

**Бер балыкчы белән студент көймәдә елга кичәләр. Студент бик сүзчән егет булып чыга, ул балыкчыдан сорап куя: - Сез югары математиканы яхшы беләсезме? -Юк, кая инде ул безгә югары математика, безгә югары белем эләкмәде инде... - Ии, сез гомерегезнең чиреген югалткансыз икән, бәлки астрономияне яхшы беләсездер? - Ансын да аз гына.... - Иии, сез гомерегезнең яртысын югалткансыз бит, ничек яшәргә надан килеш.!!!**

**– Шулвакыт, давыл чыга, хәзер инде балыкчы сорый:**

**– Йөзә беләсеңме?**

**– Юуук!**

**– Ыграк тотын, югыйсә гомереңне тулысынча югалтырсың!**

Балалар, бу мактанчыкка нәрсәләр әйтергә телисез? Фикерләрегезне **Килешү картасына** язып куегыз да, берләштерегез, уртага уртак фикерегезне языгыз. Аннан безгә әйтерсез.

***(Фикерләр тыңлана*****). Әйе, балалар, тормыш – диңгез, без кораблар. Кешедән көләргә ярамый. Белмәгәнне өйрәтергә кирәк. Кемдер спортчы, кемдер галим**.

**Студент сезне ишетерме? Минемчә, юк, чөнки сезнең җөмләләрегездә эндәш сүз булмады, әйдәгез әле, кабат эндәшик.**

Бу мактанчык сезнең сүзегез белән килешерме соң? Юктыр. Сез каян беләсез, сез әле кечкенә диячәк. Ә мин сезне кыска һәм оста итеп җавап бирергә өйрәтәм. Алдыгыздагы пазлларны җыйсагыз, мәкаль табарсыз һәм мактанчыкның авызын ябарсыз. Мәкаль ул – халык акылы, беркем дә тулы бер халыктан акыллырак була алмый. Бер баш яхшы, ике баш яхшырак.

**2.Ахырда көлгән шәп көлә.** ***(Татар халык мәкале)***

Иртән **кешедән көлсәң**, кичен **үзең көлкегә калырсың. (Татар халык мәкале)**

**Не плюй в колодец, пригодится воды напиться. (*Рус халык мәкале*)**

Игътибар итегез әле, рус һәм татар халык мәкальләре, ә фикерләребез уртак.

Без әле бу мәкальләргә җөмлә буларак әйләнеп кайтырбыз. Белгәннәребезне искә төшереп алыйк. (***Укучылар такта янына чыгалар, түгәрәк буенча йөреп кабатлыйлар)***

**1) Сораулар.**

Эндәш сүз җөмләнең нинди кисәге?

Модаль сүз нәрсә белдерә?

Эндәш сүз нәрсә белдерә?

Эндәш сүз нәрсә белән белдерелә?

Составы ягыннан эндәш сүзләр нинди була?

Җансыз әйберләргә эндәшү күренеше ничек атала?

Зат алмашлыгы эндәш сүз була аламы?

Белгәннәребезне тәлгәшләргә (кластер) урнаштырыйк.

Белгәннәребезне тәлгәшкә җыйыйк әле! Эндәш сүз - модаль кисәк – җыйнак, җәенке – җанлы предметка, җансыз предметка, матур сыйфатлар белән, интонация белән әйтелә, **җөмләнең теләсә кайсы урынында кулланыла, өтер белән аерыла, көчле тойгы белән әйтелсә, ! билгесе куела, аннан соң яңа җөмлә башлана.**

**III. Яңа белем ачу этабы.**

**1. Тактадагы җөмләләргә карыйк әле!**

**Әнкәй**, җибәр мине ерак сәяхәткә, күңел диңгезләрен күрим...

Мин очраттым юлда сине, **бәхетем минем**!

Кайда сез, **гөлләр**?

**И горур гүзәл!** Шагыйрьне шул талант өчен ярат!

Йә, әйт, **дустым**, мин сәерме?

**Диңгез ярының горур кызы!** Әйтче, ярда ни эзлисең?

(*Рәдиф Гаташ. "Егерме дүрт йолдыз һәм унҗиде диңгез" поэмасыннан*)

Сорауларга җавап эзлик.

1) Эндәш сүзләр җөмләнең кайсы урыннарында килгән?

***(Җөмлә башында, уртасында, ахырында)***

2) Эндәш сүзләр янында нинди тыныш билгеләре куелган?

1. Эндәш сүз җөмлә кисәкләреннән **өтер** белән аерыла.

2. Көчле тойгы белән әйтелгән эндәш сүздән соң **өндәү билгесе** куела, җөмлә баш хәрефтән башлана.

3. Бер гомуми интонация белән әйтелгән **и ымлыгы (ай, әй, ай, о)** өтер белән аерылмый.

4. Гомуми интонация белән әйтелмәгән **ымлык** өтер белән аерымлана (әй, Габдулла!)

Нәтиҗә ясыйк.

***(Дәреслектән кагыйдә укыла, фикерләр раслана*)**

**Тәлгәшкә өч түгәрәк беркетелә**.

**IV. Ныгыту этабы.**

**1.Тактадагы мәкальләргә әйләнеп кайтыйк. Эндәш сүзләрне төрле урыннарга куеп эндәшеп карыйк.**

- Иртән кешедән көлсәң, кич үзең көлкегә калырсың. (**Студент иптәш**, иртән кешедән көлсәң, кич үзең көлкегә калырсың! Иртән кешедән көлсәң, **студент иптәш**, кич үзең көлкегә калырсың. Иртән кешедән көлсәң, кич үзең көлкегә калырсың, **студент иптәш**! **Студент иптәш!** Иртән кешедән көлсәң, кич үзең көлкегә калырсың!)

**2. Дәфтәрдә беренче җөмләне үзгәртеп язу.**

**3. а) Кроссенс чишү.**

1) **Җырларым!** Сез шытып йөрәгемдә

Ил кырында чәчәк атыгыз! (М. Җәлил) (каурый каләм, йөрәк)

**3)** **Әй авыл**, син мең шәһәрдән

Мең кабат ямьле вә хуш.(С.Рәмиев) ( авыл өе)

3) Елмай, **сеңлем**, кояш булу, бик килешер сиңа! (Г. Морат)

4) Авырмыймы, ярдәм кирәк мәллә,

Һәммәсен дә миңа сөйлә, **Көн**!(М.Әгъләмов)

5) Азмы җырлар яздым синдә, **Казан**,

Гомерем дә синдә өзелер. (М.Әгъләмов) (кремль)

6) Җитәр, **Вакыт**, юкны сөйләмә! (М.Әгъләмов) (сәгать)

7) **Мөэминнәр,** бары тик хәләл белән тукланыгыз! (Коръән) (мәчет)

8) Чәчкә алып килде кем дисәм, Син икәнсең, **Тормыш**, исәнме! (С.Сөләйманова) (юл)

9) Эндәш сүз (уртадагы рәсем)

Җавапларны чагыштыр һәм бәялә!

**б) Җавапларны тикшерү, үзбәя.**

**IV.Өй эше бирү һәм аңлату.**

1) Синквейн язарга. **(Эндәш сүз. Җыйнак, җәенке. Дәшә, чакыра, белдерә. Эндәш сүз - модаль сүз. Эндәш сүз сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерә. Мөрәҗәгать)**

2) Минем сайтка кереп, “Эндәш сүзләр” темасы буенча алган белемнәрне тикшерергә, “5”ле билгесе алырга.

**V. Рефлексия**

Хәзер дәрестә өйрәнгән кагыйдәләрне ничек үзләштерүегезне Эр Ар Гайд структурасы ярдәмендә тикшерик. Укучылар, сезгә раслаулар язылган

карточкалар таратам. Раслау белән килешсәгез “+”, әгәр килешмәсәгез “ - ” билгесе куегыз.

| **Раслау** | **Килешәм/ килешмим** |
|---|---|
| Эндәш сүз – җөмләнең модаль кисәге. | |
| Җансыз әйберләргә эндәшү сынландыру дип атала | |
| Эндәш сүз җөмлә кисәкләреннән **өтер** белән аерыла. | |
| Көчле тойгы белән әйтелгән эндәш сүздән соң **өндәү билгесе** куела, җөмлә баш хәрефтән башлана. | |
| Бер гомуми интонация белән әйтелгән **и ымлыгы (ай,әй, ай,о)** өтер белән аерылмый. | |
| Зат алмашлыгы җөмләдә эндәш сүз булып килә. | |
| Гомуми интонация белән әйтелмәгән **ымлык** өтер белән аерымлана. | |

Укучылар, бергә тикшереп карыйк. Раслау дөрес булса, миңа елмаеп җавап бирегез. (Барлык җаваплар да дөрес булган укучыларга “5”ле билгесе куела, хаталары булган укучылар теманы, өйдә кагыйдәләрне укып, ныгыталар).

**VI. Йомгаклау.**

Димәк, балалар, бүгенге эшебезгә нәтиҗә ясагач, нинди фикергә киләбез, эндәш сүзсез сөйләп аңлашу җиңелме, мөмкинме? (**Юк, мөмкин түгел**). Эндәш сүзне җөмләнең кайсы урыннарында куллана алабыз? Эндәш сүз башка җөмлә кисәкләреннән нинди тыныш билгеләре белән аерымлана? (*Җаваплар тыңлана*)

Укучылар, бүгенге дәресебез нәтиҗәле үтте, актив катнашуыгыз өчен рәхмәт. Сәламәт булыгыз!

## МИКЪДАР САНЫ. ТӘРТИП САНЫ

(5 нче сыйныф, рус төркеме)

***Нәфыйкова Алия Ринат кызы,***
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы*
*119 нчы урта гомуми белем мәктәбенең*
*беренче квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:** коммуникатив мәсьәләдән чыгып, фикерне төгәл итеп җиткерү, аралашу күнекмәләрен үстерү.

**Дәрес максатлары:**

**Белем бирү максаты:**

- Микъдар саны. Тәртип санынары белән таныштыру. Тәртип санының кушымчаларын өйрәнү.

**Үстерү максаты:**

- саннарны сөйләмгә кертү, биремнәр ярдәмендә ныгыту, сөйләм телен үстерү, сүзлек запасын баету

**Тәрбия бирү максаты:**

- балаларда бердәмлек, ярдәмчеллек хисен уяту.

**Көтелгән нәтиҗәләр:** тәртип саннарын кушымчалар ялгап ясый һәм тәрҗемә итә алу, алган белемнәрне актив кулланышка кертү, тема буенча диалогка чыгу. Тәртип саннарының исемнәр белән куллану үзенчәлекләрен истә калдыру.

Универсаль уку гамәлләре формалашу:

***Танып белү*** универсаль уку гамәлләре*:*

- фикерләүне үстерү белән бәйле психологик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү.

***Коммуникатив*** универсаль уку гамәлләре**:**

- әңгәмәдәшеңнең сөйләмен тыңлый, аның фикеренә туры килерлек җавап бирә белү.

***Регулятив*** универсаль уку гамәлләре**:**

- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү.

**Уку эшчәнлегенең төрләре:** карточкалар, рәсем буенча эш, гомуми нәтиҗә чыгару, әңгәмә, үрнәк буенча әйтү. Анализ ясау. Сорауларга җавап бирү.

**Җиһазлау:** ноутбук, проектр, презентация, таймер, таратма карточкалар, клей.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне үзләштерү.

**Контроль төрләре:** Сорауларга җавап бирү, телдән сөйләү, нәтиҗә чыгару, чагыштыру, парларда эш.

**Дәрес планы**

**I. Оештыру.** Уңай психологик халәт тудыру.

- Исәнмесез, укучылар! Хәлләрегез ничек?

**II. Актуальләштерү.** (*скайптан шалтыраган тавыш ишетелә*).

- Укучылар, ишетәсезме: безгә кемдер шалтырата? Кем икән ул? Беләсегез киләме? (*Шәвәлинең видеохаты карала*).

- Укучылар, Шәвәли безгә нинди уен уйныйбыз? – диде. Ә квест-уен нәрсә соң ул? Уйныйбызмы? Уйнар өчен безгә командаларга бүленергә кирәк. Зәңгәр – беренче команда, Кызыл – икенче, яшел – өченче.

- Беренче команда, сәлам! Икенче команда, сәлам! Өченче команда, сәлам!

- Беренче команда, сездә ничә кеше? Икенче команда, өченче команда, сездә ничә кеше?

**III. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.**

- Укучылар, экранга карагыз әле: сез нәрсә күрәсез? Квест уенын үткәндә без нәрсәләргә бәйле биремнәр үтәрбез икән? Әйдәгез, әлеге сорауларны тәрҗемә итеп карыйк. Ничә? Күпме? – Сколько? Ничәнче? – Который?

- Сорау һәм кушымчалар белән таныштык, димәк, уеныбызны башлый алабыз.

**1 нче каршылык.**

- Өстәлдәге саннарга нигә шундый кушымчалар ялганды икән? Төркемнәрдә уйлагыз, җавап бирегез.

2 нче, 4 нче, 7нче, 9 нчы, 8 нче, 6нчы.

**2 нче каршылык.**

- Икенче этапка килеп җиттек, ә анда безне биек таулар каршы алды, димәк, безгә күп көч кирәк булачак. Ә көч булсын өчен, без походка үзебез белән нәрсәләр алабыз соң? (*укучыларның фикере*). Сезнеңчә, минем рюкзакта ниләр бар икән? (*укытучы рюкзактан әйберләрне чыгара, укучылар атап бара*). Бик яхшы. Ә хәзер экрандагы биремне карыйк. Рәсемнәрне сүзләр белән күрсәт, микъдар саннарыннан тәртип саннарын ясагыз, сүз белән языгыз.

| | **Микъдар саны** | **Тәртип саны** |
|---|---|---|
| 1 | 7 | Җиденче |
| | 2 | Икенче |
| 2 | 3 | Өченче |
| | 12 | Уникенче |
| 3 | 8 | Сигезенче |
| | 24 | Егерме дүртенче |

**3 нче каршылык**

“Пантомима” уены. Алдагы этап – урман! Урманда без нәрсәләрне очратырга мөмкинбез? (*укучыларның фикере*). Ә безнең командаларга нәрсәләр очрады икән, хәзер белербез.

Һәр командадан бер укучы чыга, карточкаларны ала һәм анда язылганнарны пантомима ярдәмендә күрсәтә. Мәсәлән, *урманда 3 тиенне очраттык.*

**4 каршылык**

Парларда эшләү. Карточкаларда бирелгән схемалар буенча диалоглар төзү.

***- Гаиләңдә ничә кеше?***

***- Гаиләмдә ... кеше.***

***- Ничәнче катта яшисең?***

***- ... катта яшим.***

***- Синең ничә дустың бар?***

***- Минем ... дустым бар.***

**5 каршылык**

- Хәзер соңгы-бишенче-этапка килеп җиттек. Барлык каршылыкларны да узып барасыз.

- Ә ул каршылыкларны узарга сезгә нәрсә ярдәм итә соң? Шуны белеп китик әле. Өстәлдәге кәгазь битләренә сүзләрне ябыштырырга кирәк. Беренче, икенче, өченче, сезгә нәрсә ярдәм итте: дуслыкмы, акылмы, җитезлекме (быстрота)?

Шулай ук, дәрес аңлашылган булса, ! билгесе, аңлашылмаса, ?, аңлашылып, бераз сораулар калса, ?! билгеләрен куярга кирәк.

(*Командаларның фикере тыңлана*.)

**IV. Рефлексия.**

Димәк, микъдар саны нинди сорауларга, ә тәртип саны нинди сорауларга җавап бирә, укучылар?

- Без барлык каршылыкларны да үтеп чыктык. Шулай булгач, Шәвәлинең фикерен тыңлыйк. Афәрин! Хәзер жетоннарыгызны санагыз, кемдә нинди жетон күбрәк? Кызыл жетон күбрәк булучылар – беренче, шәмәхә – икенче, алсу – өченче урынга лаек була. (*Укучыларга төсләр буенча медаль тапшырыла).*

**V. Йомгаклау.**

- Барыгызны да котлыйм, киләчәктә уңышлар телим! Сау булыгыз!

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЕ БУЕНЧА ФДББС ТАЛӘПЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНЕП ТӨЗЕЛГӘН ТЕХНОЛОГИК КАРТА

***Тарханова Гүзәлия Инсаф кызы,***
*Казан шәһәре Вахитов районы*
*96 нчы гимназиянең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

### Аңлатма язуы

Дәреснең технологик картасы – ФГОСны тормышка ашыруның инновацион инструменты. Ул дәресне оештыруның нигезен тәшкил итә, фәнни тел белән әйткәндә, дәрес конспектының график варианты булып тора. Технологик карта дәреснең һәр этабын зур төгәллек белән планлаштырырга ярдәм итә, чөнки ул этапларның һәрберсе билгеле бер максатка юнәлтелә һәм анда төрле методлар, алымнар куллану карала. Һәр технологик картаның башлам өлеше (шапкасы) була. Анда предмет, УМК (үрнәк программалар, дәреслек) күрсәтелә.

**Дәреснең технологик картасы**

Предмет: татар әдәбияты

Сыйныф: 8 нче татар төркеме

УМК: 1. “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа” (Ф.Х. Җәүһәрова. Казан, 2013).

2. “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа” (төзүче авторлары: Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2014 ел).

3. Дәреслек. Татар әдәбияты, 8 нче сыйныф / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина, Ә.Н. Сафиуллина. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2015.

4. Ноутбук, проектор, экран, слайдлар, фонохрестоматия, картина репродукциясе.

| | |
|---|---|
| Тема | Шәриф Камалның “Буранда” хикәясендә ана һәм бала проблемасы |
| Дәреснең максатлары | 1. Хикәяне анализлау өчен шартлар тудыру.<br>2. Мостафаның анасына булган мөнәсәбәтен һәм аның ялгышларын ачыкларга ярдәм итү.<br>3. Ата-ананы хөрмәт итү – бәхет чыганагы булуын аңларга булышу. |
| Дәреснең бурычлары | 1. Белем бирү максаты: хикәянең төп фикерен укучы аңына җиткерү өчен шартлар тудыру.<br>2. Фикерләү сәләтен үстерү максаты: анализлау, чагыштыру, гомумиләштереп, нәтиҗә ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү.<br>3. Тәрбия бирү максаты: ана хакын хаклау – яшәешнең нигезе икәнлегенә ышандыру. |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | 1. Предмет нәтиҗәләре: хикәянең темасын аңлау һәм формалаштыру, идеясен күрсәтү.<br>2. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүри икәнлеген аңлау һәм геройның гамәлләре аша яхшыны начардан аерырга өйрәнү.<br>3. Метапредмет нәтиҗәләр:<br>- регулятив: әсәрнең төп проблемасын табу, герой эшчәнлеген бәяләгәндә, үзеңнең һәм башкаларның фикерен дөрес бәяләү, төркемнәрдә эшләгәндә, төрле мисаллар белән үз фикереңне дөрес коррекцияләү;<br>- танып-белү: булган белемнәргә таянып, мәкальәйтемнәр аша “ана хакы” төшенчәсенә кагылышлы |

| | |
|---|---|
| | мәгълүматны табу һәм анализлау һәм чагыштыру аша аны бәяләү, әсәрнең төп фикерен табу һәм формалаштыру, гомуми нәтиҗәне чыгару;<br>- коммуникатив: “Анасыз тормыш – буш тормыш” дигән фикерне истә тотып, төп нәтиҗәне чыгару эшчәнлегендә катнашу, әңгәмә барышында төрле җавапларны тыңлый белү һәм үз фикереңне белдерү. |
| Предметара бәйләнешләр | Рәсем сәнгате, татар теле, музыка |
| Ресурслар:<br>- төп<br>- өстәмә | Төп: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен дәреслек). 8 нче сыйныф, 1 нче кисәк.<br>Өстәмә: слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, ноутбук. Фонохрестоматия: П.И. Чайковскийның “Ел фасыллары. Кыш” (анасы янына ашыгучы Мостафаны тоткарлаучы буран авазлары). Рәссам Р. Сәлаховның “Ак әби” (ана образын күрсәтү өчен) картинасы репродукциясе. |
| Эшне оештыру | Төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү. |
| Төп төшенчәләр | Тема, идея, ана һәм бала проблемасы, әхлак, анализлау, чагыштыру, гомуми нәтиҗә. |
| Педагогик технологияләр | Өлешчә тикшеренүгә корылган әңгәмә, тәнкыйди фикерләү. |

| Дәрес тибы | | Яңа белемнәр үзләштерү.<br>Искәрмә: дәрес планы 45 минутка исәпләнеп төзелде. | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Эшкә этәргеч бирүче сораулар һәм тәкъдимнәр** | **Укучы эшчәнлеге** | **Белем бирү һәм фикерләү сәләтен үстерү (дәреслек, предмет материалы)** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
| <u>Мотивлаштыру</u><br>1 мин.<br>Максат: уңай психологик халәт тудыру. | Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту. | Талгын гына музыка уйный (П.И.Чайковский.“Ел фасыллары. Кыш.)<br>сорау бирелә: дәресебез уңышлы булсын өчен нишлибез?<br>Тәкъдимнәр: һәр фикерне тыңлыйбыз, бер-беребезгә ярдәм итәбез. | Дәрестә төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерү: башкаларны тыңла, үз фикереңне ачык әйт, игътибарлы бул. | Шәхси эшчәнлек: дәреслек һәм эш дәфтәрләрендәге язмаларны барлау. | **Шәхескә кагылышлы:** әдәп-әхлак кагыйдәләрен искә төшерү, бер-береңә уңышлар теләү. |
| <u>Өйдә укылган әсәрне аңлауларын тикшереп карау.</u><br>2 мин. | Искәрмә: “Буранда” хикәясе алдан ук өйдә укыла. Шуңа таянып, әсәрне ничек аңлауларын тикшерү өчен сорау куела:<br>хикәяне ничә өлешкә бүлеп була? Кыскача эчтәлеген сөйләгез, төп фикерләрегезне белдерегез. | Өлешләр арасында нинди бәйләнеш бар? | Ике өлешкә бүлеп була:<br>а) Мостафа әнисе янына кайтырга омтыла;<br>б) буран аркасында әнисен исән көе күрү теләге тормышка ашмый. Берничә җөмлә белән аларны сөйлиләр, төп фикерне әйтәләр. | Үз фикереңне әйтү өчен, төрле дәлилләр сайлый белү, аларны раслау. | **Танып-белү:**<br>а) укылган тексттан кирәкле мәгълүмат алу;<br>б) текстны мөстәкыйль укыганда, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү;<br>в) эчтәлеккә караган объектларны тану, аерып алу, (бала елавы, Мостафаның максаты, буран) |
| <u>Актуальләштерү</u><br>2 мин. | Укучыларның әзерлек дәрәҗәсе аларның җавапларында | Үзлектән укыган “Буранда” хикәясенең сюжетыннан сез нәрсә | Укучыларның фикерләре: а) Шәриф Камалның “Буранда” | Дәреслектәге өзек буенча чорга бәя бирү. Ситуацияне ачыклау. | **Танып-белү:** музыка ни турында, буран күренешен |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Максат: яңа белем алуга әзерлек дәрәҗәсен билгеләү, күнекмәләрне конкретлаштыру. | чагыла, моны аңлау өчен шартлар тудырыла: эш барышында укучыларга сораулар бирелә, җаваплары тыңлана.<br>Яңа белем алуга әзерлекне тикшерү соравы: әсәр герое янәшәсендә нинди символик образ бар? Хикәядә ул нинди роль уйный? | аңладыгыз? Төп герой кем? Башка геройлар белән мөнәсәбәтен, бәйләнешен ничек аңлатырга? | хикәясен укыганда, мин Мостафаның кичерешләрен аңларга тырыштым.<br>б) Ул әнисен озак еллар күрмәгән, аның янына ашыга.<br>в) Герой белән ана арасында тирән чокыр ята сыман, герой аны үтеп чыгарга тиеш.<br>Буран – символик образ. Ул геройның юлын бүлә. | | күзаллау һәм фикер белдерү.<br>**Шәхескә кагылышлы:** уку эшчәнлегендә берберсе һәм укытучы белән хезмәттәшлек оештыру.<br>**Регулятив**: һәр төркемнең бәясен тыңлап, вакыйганы тормыш белән бәйләп, беренче нәтиҗәне чыгару, алдагы адымнарны фаразлау.<br>**Коммуникатив:** төркемнәр хезмәттәшлегенә ирешү. |
| <u>Уку мәсьәләсен кую һәм теманы ачыклау.</u><br>3 мин. | **Слайд №1.**<br>Яшь бала елый. Тышта буран. Мостафа йоклый алмый.<br>Проблемалы сорау: бу өч күренешне нәрсә берләштерә? Тема нәрсә турында? | “Бала усал” дигән җөмлә белән Мостафа ни әйтергә тели? | Бала елавы Мостафаның кичерешләре белән тәңгәл килә: бала усал. Бу аның үзе турында. Буран-каршылык.<br>Тема бала һәм ана турында. | Фикереңне кыска һәм матур итеп әйтү, дәреслектән мисаллар китерү: буран турында уку. “Бала усал” җөмләсенең кат-кат кабатлануына игътибар итү, аның мәгънәсен аңлау. | **Танып-белү:** гади ситуацияләрне бәяләп, геройның күңел кичерешләрен күрә белү, аны дөрес бәяләү. |
| <u>Уку мәсьәләсен адымлап чишү.</u><br>10 мин. | **Слайд №2.**<br>Мостафа егерме ел күрмәгән анасы янына ашыга. Ана- | Мостафа ни өчен анасы янына егерме ел буена бер тапкыр да кайтмаган? | Төп нәтиҗә чыгарыла. Буранга (каршылыкка) карамастан, Мостафа анасы яны- | “Сез аналар... Һәммәгез дә шулаймы? Бала өчен газапланасыз?”җөмләсе аша геройның күңел кичере- | **Коммуникатив:** төркемнәрдә эшләү, үз фикереңне башкаларга сөйләп |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | сының үлем түшәгендә ятуын ул белми, тик күңеле нидер сизенә. | | на кайтырга тиеш. Ул үзенең ялгышуын аңлаган. Дусты аның өчен атлы кеше эзләп таба. Мостафа юлга чыгарга әзерләнә | шләрен ничек аңлатып була? | аңлату.<br>**Регулятив:** герой-ның эш-гамәленә бәя бирү.<br>Танып-белү: анализ ясап, төп нәтиҗәне чыгару: Мостафа үз хатасын аңлады һәм аны төзәтергә әзер. |
| | **Слайд №3.** Мостафа буранлы юлдан бар-ганда, бала чагын һәм анасына карата эшләгән гамәлләрен исенә төшерә.<br>Ни өчен? | “Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада” мәкален ничек аңлый-сыз? Ул бу темага ту-ры киләме? | Укучыларның фи-керләрен тыңлау:<br>- кечкенә Мостафа анасын яраткан, тик аны әнисенә каршы котыртканнар.<br>- Анасының ак читле зәңгәр кульяулыгын да хәтерли. Яраткан анасы белән бәйле бу детальнең хәтердә калуы анасын яратуга ишарә булып тора. Мостафа балачак усаллыгы өчен газа-плана, тизрәк кайтып, анасыннан гафу үте-нергә тели. | Булган белемнәрдән чыгып, яңа фикерне фор-малаштыру: аналар һәм балалар арасында килеп чыккан аңлашылмаучы-лык – кешеләрнең иң зур ялгышы. Мостафа егерме ел узгач кына моны аңлый. Вакытында кай-тып җитә алмаса, ул го-мер буе үкенәчәк. | **Шәхескә кагы-лышлы:** аналар һәм балалар проблемасы турында үз фике-реңне әйтә белү. Мәкальгә таянып аңлату.<br>**Коммуникатив:** төркемнәрнең фи-керләренә мөнәсәбәтеңне бел-дерү. |
| | **Слайд №4.** Мостафа анасын исән килеш күрә алмый: ул соңга кала. Төп каршылык – буран – бу очрашуны теләми төсле. Сәбәбе нидә? | Хикәянең иң ошаган өлеше кайсы?<br>Юлда очраган буш чиләкле хатын һәм козгын тавышы хикәядә нинди роль уйный? | Һәр төркемнең җавабыннан соң, уртак фикерләр тыңлана:<br>а) буш чиләкле хатын очрау эшнең барып чыкмавына ишарә итә. Козгын тавышы | Фикерләрне үз мисалла-рыңа таянып раслау. | **Танып-белү:**<br>әдәби күренешләр (буш чиләк, козгын тавышы) аша укучы халык сынамышла-рына бәя бирергә, аларны анализларга |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | куркыныч буласын белдерә, ди халык сынамышлары.<br>б) әгәр ул анасын исән килеш күргән булса, анасы аны гафу итәр иде. Автор моны гафу итми. | | өйрәнә.<br>**Регулятив:** тиешле нәтиҗәгә килүдә эзлеклелекне саклау. |
| | **Слайд №5.**<br>Автор ана белән баланы очраштырмый. | Мостафага бирелгән “җәза” үзен акламы? Автор артык кискен эш итә түгелме? | Мостафа зур гөнаһ кылган: сау-сәламәт вакытында, мөмкинлеге булса да, анасы янына кайтмаган. Автор моны кичерми, чөнки герой хатасын аңларга һәм үкенергә тиеш. Шулай булмаса, тормышта кеше мондый хаталарны еш кабатлар иде. Төп нәтиҗә: кеше сабак алырга тиеш. | Укучылар алдына куелган сораулар аларны фәлсәфи фикер йөртергә, уйланырга өйрәтә. | **Шәхескә кагылышлы:** һәр укучы фикерен мөстәкыйль формалаштыра.<br>**Коммуникатив:** уртак фикергә килү.<br>**Танып-белү:**<br>һәр төркем үз фикерен белдерә, аларның җаваплары тыңлана, чагыштырып, уртак нәтиҗә чыгарыла. |
| <u>Аңлау өчен авыр тоелган сорауны ачыклау өчен сынап карау этабы.</u><br>4 мин.<br>Максат: укучының нинди авырлык белән очрашуын билгеләү, аның шәхси фикере формалашуга юнәлеш бирү. | Сөйләгәннәрдән чыгып, проблемалы сорау куела: анасы белән Мостафаның бәхетсез язмышында кем гаепле? | Кешеләрнең бәхете бер төрлеме? | Төркемнәрдәге аерым укучылар фикерләрен белдерәләр. Сораугa берьяклы гына җавап бирү авыр, төп фикергә килергә кыенсыналар. | Төп геройның характерында нинди яхшы һәм кимчелекле яклар булуын ачыкларга тырышу. | **Регулятив:** хикәя вакыйгаларын хәзерге тормыш белән бәйләп чагыштыру.<br>**Шәхескә кагылышлы**: “ана белән бала мөнәсәбәте” төшенчәсен хәзер ничек аңларга? соравы буенча фикер белдерү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | **Коммуникатив**: төркемнәрдә бердәм хезмәттәшлек итү. |
| <u>Ял итү.</u><br>Максат: укучыларны ял иттерү.<br>2 мин. | Физминутка үткәрүгә җаваплы укучының эшен оештыру. | | Күнегүләр ясыйлар. | | **Регулятив:** күнегүләрне дөрес эшләүне контрольдә тоту. |
| <u>Яңа белемне куллану.</u><br>6 мин.<br>Максат: “Ана белән бала бәхете” төшенчәсенең асылына төшенү һәм хикәя персонажлары мисалында аңлату. | **Слайд №5.**<br>Аналарны һәрвакыт хөрмәт итәргә. Ана сиңа тормыш биргән. Ул – баланың төп таянычы.<br>Укытучы сораулар бирә, эшнең эзлеклелеген тәэмин итә.<br>Укучылар игътибарына эпиграф тәкъдим ителә:<br>Бәхетле бала анасы белән яши. | Мостафа ялгышы нидә?<br>“Бала усал” җөмләсен әйткәндә, герой ниләр кичерде икән? | Шәхси фикерләр тыңлана, төркемнәрдә тикшерелә. Укучылар төп нәтиҗәне ясыйлар: геройның ялгышы – анасын хөрмәт итәргә өйрәтелмәүдә (моңа тирә-яктагылар, бигрәк тә атасы гаепле) һәм өйрәнергә теләмәүдә. “Бала усал” җөмләсе белән ул үзенең гамәлләренә нәтиҗә ясый. | Хикәя буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, фикер җиткерү, аны расларга тырышу. | **Регулятив:** автор карашын аңлата торган сүзләр аша объектив һәм субъектив мөнәсәбәтләрне ачыклау.<br>**Коммуникатив:** фикернең ачык итеп әйтелүенә ирешү.<br>**Танып-белү:** төп нәтиҗәне чыгару, дәлилләү, логик фикерләп, нәтиҗә ясау. |
| | **Слайд №6.**<br>Бәхет ул аналарның табан астында.<br>(Мәкаль.)<br>Анаңны хөрмәт ит!<br>(Яһүд халык мәкале.) | Мостафа ялгышын ни өчен соң аңлый? | Төркемнәрдә эшләү.<br>Төп нәтиҗәне чыгару:<br>Кеше яшь вакытта кайбер нәрсәләргә бик өстән генә карый. Мостафа да анасы янына кайтуга артык әһәмият бирмәгән. Гомер узган саен, кеше тәҗрибә туплый | Дәреслекнең тиешле өзекләреннән мисаллар уку. | **Шәхси:** герой халәтен тоеп, үз кичерешләреңне чагылдыру.<br>**Танып-белү:** әйтелгәннәргә нигезләнеп, чираттагы нәтиҗәне чыгау. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | һәм үзенең эшгамәлләренә дөрес бәя бирә башлый. | | |
| <u>Беренчел ныгыту</u><br>2 мин.<br>Максат: яңа белемнәрне биремнәрдә куллану, сөйләм аша белдерү. | Сораулар куела: син хикәядән ни аңладың? | Хикәядә сөйләнгән хәлнең сәбәбе нәрсәдә? | Төркемнәрдә укучылар бәхәсләшеп, берберсенә ярдәм итешеп, фикерләрен белдерәләр: әниләрнең кадерен белергә, рәнҗетмәскә кирәк. | | **Танып-белү:** төркемнәрдә сәбәпнәтиҗә бәйләнешен китереп чыгару, аны мисалларга нигезләнеп исбатлау.<br>**Шәхси:** фикереңне дәлилләү. |
| <u>Үз-үзеңне тикшерү өчен мөстәкыйль эш.</u><br>2 мин.<br><br>Максат: үзләштерелгән белемнәр буенча нәтиҗә ясау. | Тикшерү соравы куела. Ул дәреслектә каралмаган һәм көтелмәгән җаваплар бирүне таләп итә: тормышта әти-әнисез яшәргә мәҗбүр ителгән балалар бар. Аларга кем ярдәм итәргә тиеш? | Тикшерү өчен төп сорау: анасын хөрмәт итмәгән балаларга сезнең мөнәсәбәтегез нинди? | Төркемнәрдәге һәр укучының фикере тыңлана һәм системага салынып, дәфтәрләргә языла: | Охшаш фикерләрне гомумиләштерү, уртаклыкларын табу. | **Регулятив:** төрле гаиләләрне чагыштырып карау, нәтиҗә ясау.<br>**Танып-белү**: укучыларның тормышка карашларын формалаштыру.<br>**Шәхси:** һәр баланың үз фикерен ачык белдерүе, дәлилләп, үз нәтиҗәсен ясавы. |
| <u>Белемнәрне системага салу.</u><br>5 мин.<br><br>Максат: алган белемнәрне куллану һәм ныгыту. | Хикәядә автор әйтергә теләгән төп фикер нинди? | Мостафа тормыштан нинди сабак алыр? | Һәр төркем аерым эшли, аннан соң берәр укучы тыңлана: үзең бәхетле булу гына җитми, сине тудырган анаң турында да күбрәк уйларга кирәк.<br>Мостафа сабак алыр һәм үз балаларын дөрес тәрбияләр, ала- | Чыгарылган нәтиҗәләрне дәфтәрләргә язып кую. | **Танып-белү:** алган белемнәрдән тиешле нәтиҗәләр чыгару күнекмәләрен формалаштыру.<br>**Коммуникатив:** төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү.<br>**Шәхси:** эш барышында үз фикереңне белдерү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | рны аналарын хөрмәт итәргә өйрәтер. | | |
| <u>Рефлексия</u><br>2 мин.<br>Максат: үз эшчәнлегенә кире кайтып бәя бирү. | Үз эшеңне бәяләүгә юнәлтелгән сораулар куела: кечкенә Мостафага мин ни әйтер идем? | Укучылар, сез бүген нәрсә турында өйрәндегез? | Һәр төркемнең үз җавабы тыңлана: үз анаңның кадерен бел, аны хөрмәт ит. | Моңа охшаш әсәрләрне искә төшерү (Ә.Еники “Әйтелмәгән васыять”) һәм фәлсәфи нәтиҗә чыгару: безне көтеп яшәгән аналар һәрвакыт гафу итәрләр, ә без үз-үзебезне гафу итә алырбызмы? | **Регулятив:** аңлашылмаган якны ачыклау, бергәләп эшләгәндә, бердәм карар кабул итә белүнең әһәмиятен аңларга булышу. |
| | **Слайд № 7.**<br>Р.Сәлаховның “Ак әби” рәсеме күрсәтелә. | Нинди нәтиҗә ясадыгыз? | Төп нәтиҗә: әниләр өчен без һәрвакыт бала булып калырбыз. | Барлык эш процессын күздән кичереп, төп нәтиҗәне чыгару: ана кадерен белмәгән кешенең бәхете булмас! | **Шәхси:** һәр баланың шәхси нәтиҗәгә ирешүе.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдә актив катнашу. |
| <u>Дәресне йомгаклау.</u><br><u>2 мин.</u><br>Максат: бер-береңнең эшен бәяләү, билгеләр кую. | Укытучы укучылар белән берлектә эшкә йомгак ясый. | Укучылар, үзбәяләрегезне карагыз һәм билгеләрегезне куегыз. | Һәр төркемнең эшенә һәм индивидуаль чыгышларга, үз эшләренә укучылар бәя бирәләр, билге куялар. | Укучылар бер-берсенә рәхмәт белдерәләр. | **Шәхси:** үз эшеңә объектив бәя бирә белү һәм тәнкыйть күзлегеннән карау. |
| <u>Өй эше бирү һәм теләкләр.</u><br>2 мин. | 1. “Ана күңеле балада...” темасына инша язу.<br>2. Бала һәм ана мөнәсәбәтләренә бәйле мәкальләр туплау.<br>3. “Әнием – иң кадерле кешем” темасына мәкалә язу. | Укучылар, дәрес тәмам. Дәрестә яхшы эшләвегез өчен рәхмәт. | | | **Шәхси:** үз мөмкинлегеңнән чыгып, өй эше алу. |

# ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН СЫЙФАТ ФИГЫЛЬ

(7 нче сыйныф, татар төркеме)

***Арсланова Әнисә Дәүли кызы,***
***Ханнанова Миләүшә Хатыйп кызы,***
*Казан шәһәре Идел буе районы 35нче лицей – “Галактика” мәгариф үзәгенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

“Хәзерге заман сыйфат фигыль” темасына эш программасында 2 дәрес вакыт бирелгән. Әлеге дәрес – беренче дәрес.

**Максат:** 1) Хәзерге заман сыйфат фигыльне өйрәнү.

2) Укучыларның хәтерен камилләштерү; фикерләү сәләтен үстерү.

3) Әниләргә карата хөрмәт тәрбияләүгә юнәлеш бирү.

**Дәрес тибы:** яңа теманы өйрәнү дәресе.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

***Шәхескә кагылышлы:*** телне өйрәнүгә кызыксыну һәм әниләргә карата игътибар уяту; сөйләмеңне камилләштерүгә омтылу; төркемнәрдә эшләгәндә бер-берсенә игътибарлы булу; җаваплылык хисе тәрбияләү.

***Метапредмет:***

*Танып-белү:* сыйфат фигыль турында мәгълүматны эзләп табу; уй-фикерне язма һәм әйтмә формада аңлап һәм иректе оештыру.

*Коммуникатив:* диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү; коммуникатив максатка нигезләнеп, сыйфат фигыльләрне дөрес, урынлы куллану; үз фикереңне җиткерә белү, парларда эшли белү.

*Регулятив:* дәрес барышында үз эшчәнлегеңне контрольдә тоту.

***Предмет:*** Хәзерге заман сыйфат фигыльне таный һәм куллана белү, сыйфат фигыльләргә морфологик анализ ясау тәртибе белән танышу, рус телендәге “Причастие настоящего времени” белән хәзерге заман сыйфат фигыльнең охшаш һәм аермалы якларын табу.

**Материал һәм җиһазлау:** Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7 нче с-ф./ Р.К.Сәгъдиева, Г.Ф.Харисова, Л.К.Сабирҗанова, М.Ә.Нуриева; [рәссамы Л.Хисамова]. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2015. – 215б.: рәс.б-н, презентация.

## Дәреснең технологик картасы

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре: шәхси (Ш), регулятив (Р), коммуникатик (К), танып-белү (ТБ) |
|---|---|---|---|
| I. Оештыру, мотивлаштыру | Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.<br>- Исәнмесез, укучылар. Кәефләрегез ничек? Әйдәгез, бер-беребезгә елмаеп, хәерле көн телик.<br>-Укучылар, тәрәзәгә карыйк әле. Бүген көн нинди?<br>- Сезнең кәефләрегез дә бүгенге кояш кебек матур, күтәренке булсын.<br>Көтелгән нәтиҗә: укучыларның бер-берсен, укытучыны сәламли һәм һава торышы турында фикерләрен җиткерә белүләре. | Исәнләшү. Дәрескә әзерлекне күрсәтү. Укытучыны сәламләү, сорауларга җавап бирү, сөйләм эшчәнлегенә кушылу. | *ШУУГ:* дустанә мөнәсәбәт, укучыга хөрмәт тудыру, үзмаксат кую.<br>*КУУГ:* сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. |
| II. Актуальләштерү | Өй эшен тикшерү.<br>Язма эшләрен укыту.<br>Көтелгән нәтиҗә: өйрәнгән фигыльләрне дөрес куллану, эзлекле рәвештә һәм мәгънә бөтенлеген саклап, язма һәм телдән фикерләрен җиткерә белүгә ирешү. | Әниләренә язган теләкләрен укыту, фикер алышу. | *ТБУУГ:* үзләренең язма эшләреннән сыйфат фигыльләрне таба, кулланылыш үзенчәлекләрен аңлата белү.<br>*ШУУГ:* үз уңышларының яки уңышсызлыкларының сәбәпләре турында фикер алышу. |
| III. Уку мәсьәләсен кую | 1.Мәкальләр белән эш.<br>- Мәкальләрне укыгыз, мәгънәләренә игътибар итегез.<br>Үз анасын ярата торган кеше, башка аналарны мыскыл итмәс.<br>Үз анасын зурлаучы бала, кеше анасын хурламас.<br>Әниләргә хөрмәт турында фикер алышу.<br>Көтелгән нәтиҗә: мәкальнең мәгънәсен аңлап, | 1. Мәкальләрне сәнгатьле уку, мәгънәсен аңлату.<br>2. Сыйфат фигыльләрне табу, сораулар кую.<br>3. Сорауларга җавап бирү, эзләнү, нәтиҗә чыгару.<br>4. Әниләргә карата игътибарлылык турында фикерләрен җиткерү. | *ТБУУГ:* уку мәсьәләсен аңлау; хәзерге заман сыйфат фигыльнең төп билгеләрен аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру.<br>*КУУГ:* үз фикерләрен дәлилле итеп җиткерү.<br>*РУГГ:* уку мәсьәләсен кую, фаразлау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | телдән әниләр турында фикерләрен җиткерә белү.<br>2. Уку мәсьәләсен кую һәм максатын ачыклау.<br>- Сораулар куеп, фигыльләрне табыйк әле. (нишләмәс? - мыскыл итмәс; нишли торган? – ярата торган; нишләмәс? – хурламас; нишләүче? - зурлаучы).<br>- Төркемчәләрен дә билгеләгез әле. (мыскыл итмәс, хурламас – хикәя фигыльләр)<br>- Кайсы фигыльләрнең төркемчәләрен ачыклый алмадыгыз? (ярата торган, зурлаучы)<br>- Ярата торган, зурлаучы фигыльләре кайсы сүзләрне ачыклап киләләр һәм аларга тагын нинди сорау куеп карап була? (нинди кеше? - ярата торган кеше; нинди бала? - зурлаучы бала)<br>- Ә нинди соравына кайсы сүз төркеме җавап бирә? (сыйфат)<br>- Сез ничек уйлыйсыз, фигыль сорауларына да, сыйфат сорауларына да җавап биргәч, болар нинди фигыльләр икән? (сыйфат фигыльләр)<br>- Укучылар, әлеге фигыльләр кайсы вакытта башкарылган эшне белдерәләр? (хәзерге заманда)<br>- Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез? (хәзерге заман сыйфат фигыльләр)<br>Көтелгән нәтиҗә: өйрәнелгән фигыльләр арасыннан сораулар куеп, хәзерге заман сыйфат фигыльләрне таба һәм аера белү. | | |
| IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү | 1.Хәзерге заман сыйфат фигыльләрнең ясалышын аңлату.<br>- Укучылар, нокталар урынына тиешле кушымчаларны һәм сүзләрне куеп укыгыз әле. | 1.Төшеп калган кушымчаларны һәм сүзләрне куеп, сүзтезмәләрне уку.<br>2. Хәзерге заман сыйфат фигыльнең ясалышын аңлату. | *ТБУУГ:* хәзерге заман сыйфат фигыльнең кушымчаларын аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Әнисен хөрмәт ит... бала;<br>Әниләр көненә багышлан... ... шигырьләр.<br>- Димәк, хәзерге заман сыйфат фигыльләр ничек ясала икән? (-учы/ -үче; -а/-ә торган)<br>- Юклыкта да әйтеп карагыз әле. (хөрмәт итмәүче бала;<br>багышланмый торган шигырьләр)<br>Укучылардан кагыйдәне әйттерү һәм аннан соң гына слайдтан кагыйдәне бергә уку.<br>Көтелгән нәтиҗә: хәзерге заман сыйфат фигыльләрнең барлык һәм юклык төрен ясый белү.<br>2. Әниләр көне турында әңгәмә кору.<br>Көтелгән нәтиҗә: әниләр көне турында, өйрәнгән фигыльләрне кулланып, телдән сөйләм күнекмәләре булдыру. | 3. Сорауларга җавап бирү, эзләнү, нәтиҗә чыгару, фикерләшү.<br>4. Әниләр көне турында фикерләр җиткерү. | *КУУГ:* коллектив фикер алышуда катнашу, үз фикерләрен дәлилле итеп җиткерү.<br>*РУГГ:* бәйләнешле сөйләм, үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү. |
| Динамик пауза (ял минуты) | | | |
| V. Яңа белемнәрне беренчел ныгыту | 1. Дәреслек белән эш.<br>-Укучылар, дәреслектән 72 нче күнегүне табып, игътибар белән укып чыгыгыз. Текстта сүз нәрсә турында бара? (Әниләр көне турында)<br>- Хәзерге заман сыйфат фигыльләрне табып, үзләре ачыклап килгән сүзләр белән күчереп языгыз.<br>Көтелгән нәтиҗә: хәзерге заман сыйфат фигыльләр ачыклап килгән сүзләрне таба белү<br>2. Рус телендәге “Причастие настоящего времени” белән хәзерге заман сыйфат фигыльне чагыштырып фикер алышу.<br>- Телдән русчага тәрҗемә итеп карыйк әле.<br>- Ә бу рус телендә нинди сүз төркеменә керә? (причастие)<br>Укучылар, татар телендә без сыйфат фигыльне | 1. Күнегүне сәнгатьле уку, Әниләр көненә багышланган чаралар турында фикерләрен җиткерү.<br>2. Хәзерге заман сыйфат фигыльне табу һәм үзләре ачыклаган сүзләре белән язып алу.<br>3. Рус теленә тәрҗемә итү, рус теленнән “Причастие” турында белемнәрен искә төшереп, татар теле белән чагыштыру. | *ТБУУГ:* үзеңнең белем системасында ориентлаша белү;<br>*КУУГ:* мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү;<br>*РУГГ:* биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | фигыль сүз төркеменең нәрсәсе буларак өйрәнәбез? (төркемчәсе)<br>- Димәк, рус телендә ул сүз төркеме буларак, ә татар телендә фигыль төркемчәсе буларак өйрәнәбез.<br>Көтелгән нәтиҗә: Рус телендәге “Причастие” һәм татар телендәге “Хәзерге заман сыйфат фигыль”нең аермалы һәм охшаш якларын белү. | | |
| VI. Яңа белемнәрне ныгыту | Тактада һәм дәфтәрләрдә эш.<br>-Укучылар, сезгә электрон тактада “Сүзләр гөлләмәсе” бирелә. Сез шул сүзләрдән җөмлә төзергә тиеш. Әлеге җөмләдән сыйфат фигыльне табып, аңа үрнәк буенча, бергәләп морфологик анализ ясарбыз.<br>Сүзләр: якын, торган, сүзеннән дә, бармы, икән, әни, йөрәктән, сүз, чыга.<br>- Башта лексик билгеләрен атыйк (предметның эше аркылы билгесен белдерә).<br>- Морфологик билгеләрен атагыз әле. (Хәзерге заманда, барлыкта)<br>- Синтаксик билгеләрен билгелибез. (җөмләдә аергыч)<br>Көтелгән нәтиҗә: хәзерге заман сыйфат фигыльләргә морфологик анализ ясый белү. | 1. Бер укучының тактада, калганнарының дәфтәрләрдә эше.<br>2. Морфологик анализ тәртибе белән танышу.<br>3. Сыйфат фигыльгә морфологик анализ ясау үзенчәлекләре турында фикер алышу. | *ТБУУГ:* үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.<br>*КУУГ:* мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү.<br>*РУГГ:* биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү, фикерләрен төгәл һәм дөрес итеп әйтә белү.<br>*ШУУГ:* үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау. |
| VII.Өйгә эш бирү | Өй эшен аңлатып бирү.<br>1.76 нчы күнегү (хәзерге заман сыйфат фигыльне табып, дәфтәрләргә күчереп язарга).<br>2. 74 нче күнегү(хәзерге заман сыйфат фигыльне табып, морфологик анализ ясарга).<br>3. Хәзерге заман сыйфат фигыльләр кулланып, “Әниләр көне” темасына хикәя язып килергә. | 1. Өй эшен язып алу.<br>2. Өй эшенең аңлашылып бетмәгән өлешләрен ачыклау. | *ТБУУГ:* дифференциацияләнгән биремне аңлау.<br>*РУУГ:* эшчәнлекне оештыра белү.<br>ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау. |
| VIII. Рефлексия | 1. Дәрестә алган яңа белемнәрне билгеләтү. | 1.Сорауларга җавап бирү, нәтиҗә ясау. | *ТБУУГ:* Хәзерге заман сый- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Дәрескә гомумиләштереп нәтиҗә ясау.<br>- Бүгенге дәрескә куелган максатыгыз үтәлде-ме?<br>- Бүгенге дәрестә нәрсәләргә өйрәндегез?<br>- Дәрестә кемнәр турында сөйләштек?<br>2. Белемнәрне бәяләү.<br>3. Алдагы дәрескә проблема кую:<br>- Хәзерге заман сыйфат фигыльләр үзләре ияргән сүздән башка килә алалармы икән? Уй-лап килегез әле.<br>4. Дәресне тәмамлау. | 2.Сыйныфташларының, үзләренең белемнәрен бәяләү.<br>3. Саубуллашу. | фат фигыль турында алган белемнәргә нәтиҗә ясый белү.<br>*КУУГ:* үз фикерләрен дәлил-ле итеп җиткерү.<br>*РУУГ:* үзбәя бирү (мета-предмет нәтиҗәләр). |

## ТАТАРСТАН – МИНЕМ ТУГАН ЯГЫМ
(2 нче сыйныф, әдәби уку, рус төркеме)

***Касыймова Эльмира Ринат кызы,***
***Андреева Елена Васильевна,***
*Казан шәһәре Идел буе районы*
*52 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

| | |
|---|---|
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр**: туган якка карата сакчыл һәм ихтирамлы караш бул-дыру һәм аны сакларга өйрәнү теләге формалаштыру.<br>**Метапредмет нәтиҗәләр:**<br>**Танып-белү УУГ**: җөмләләр төзү, төркемнәрдә эшләү, логик фикерләү күнекмәсен үстерү.<br>**Коммуникатив УУГ**: башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү, сорауларга җавап бирү.<br>**Регулятив УУГ**: күрсәтмәләрне истә тотып эшләү, укытучы һәм укучылар арасында уртак эшчәнлек оештыра белү, эшчәнлеккә үз бәя бирә белү. |

| | |
|---|---|
| | **Предмет буенча**: бер-береңнең яшәү урынын сорый һәм кайда яшәгәнеңне әйтә белү; Татарстан шәһәрләренең , елгаларының атамаларын әйтә белү; Татарстанда яшәгән хайваннарны әйтә белү. |
| **Дәреснең тибы** | Өйрәнелгән белемнәрне йомгаклау дәресе. |
| **Төп төшенчәләр** | Татарстан шәһәрләре, елгалар, хайван атамалары. |
| **Предметара бәйләнеш** | Татар теле, әйләнә-тирә дөнья, тарих. |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, индивидуаль, парлап һәм төркемнәрдә эшләү. |
| **Чыганаклар** | Дәреслек, Хәйдәрова Р.З., Галиева Н.Г., Әхмәтҗанова Г.М. Күңелле татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирүче оешмалар өчен дәреслек. 2 нче сыйныф.- Казан: “Татармультфильм”, 2013., 107 нче бит. |
| **Җиһазлау** | Ноутбук, проектор, презентация, карточка, сүзләр, рәсемнәр. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|
| **Оештыру, мотивлаштыру** | 1) Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.<br>2) Балалар, хәзер мин сезгә бәяләү критерийлары өләшәм. Дәрес ахырында сез үзегезгә билге куярсыз.<br>**1 СЛАЙД.**<br>- Хәерле көн,укучылар! | Исәнләшү. Дәрескә әзерлекне күрсәтү. Укытучыны һәм килгән кунакларны сәламләү, сорауларга җавап бирү, сөйләм эшчәнлегенә кушылу. | **ШУУГ**: үзмаксат кую.<br>**КУУГ**: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. |
| **Фонетик зарядка.** | Ә хәзер, укучылар, телләребезне шомартып алыйк. Экранда язылган сүзләрне тыңлыйбыз һәм кабатлыйбыз.<br>**2 СЛАЙД.**<br>-Зә-зә-**Зәй.**<br>-Ча-чал-**Чаллы.**<br>-Чи-чиста-**Чистай.**<br>-Бө-бөгел–**Бөгелмә.**<br>-Ка-каз-**Казан.** | Укучылар укытучы артыннан кабатлыйлар.<br>-Зә-зә-**Зәй.**<br>-Ча-чал-**Чаллы.**<br>-Чи-чиста-**Чистай.**<br>-Бө-бөгел–**Бөгелмә.**<br>-Ка-каз-**Казан.** | **КУУГ**: дөрес әйтелеш кагыйдәләрен үтәү.<br>Башкаларның сөйләмен тыңлый белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Актуальләштерү.** | Барыбыз бергә кабатлыйбыз! Укучылар, кем матур итеп укырга тели? Бер укучы укый. Ә без сезнең белән бәялибез. Игътибар белән тыңлагыз! Аннары комплимент әйтәбез. Укучылар, менә бу кызыл төс белән язылган сүзгә игътибар итик әле. Бу сүзләр турында сез нәрсә әйтә аласыз? (*укучылар җавабы: бу сүзләр - шәһәр исемнәре. Әйе, дөрес балалар! )*<br>- Ә хәзер тактада эленгән рәсемнәргә карыйбыз. *(тиен, ат, туп, алма, ромашка, су, такта, алма, нарат рәсемнәре)*<br>(Рәсемнәрнең беренче хәрефләрен генә тактага чыгып язабыз! (*тактада эшлиләр*) | - Арсен, син дөрес укыдың!<br>- Миша, син матур укыдың!<br><br>Укучылар өстәлдә яткан карточкаларны алып тактада Татарстан сүзен дөрес җыярга тиеш.<br>Һәр рәсемнең беренче хәрефләрен вертикаль рәвештә язып баралар. | |
| **Уку мәсьәләсен кую.** | **3. СЛАЙД.**<br>- **Нинди сүз килеп чыкты?**<br><br>Афәрин, укучылар! Сез бик дөрес әйттегез!<br><br>- Димәк, укучылар, дәрестә без бүген нәрсә турында сөйләшәчәкбез?<br>- Әйе, Татарстан безнең туган ягыбыз.<br>**4.СЛАЙД.**<br>**Татарстан – безнең туган ягыбыз.**<br>- Сез яхшы укучылар!<br><br>**1.**Укучылар, безгә кунакка Шүрәле дә килгән! (Рәсеме тактага эленә)<br>- Шүрәле кем әле ул?<br>- Ул кайсы әкият герое?<br>- Укучылар бу әкиятне кем язган?<br>- Г.Тукай кем ул?<br>- Шүрәле сезгә биремнәр дә алып килгән. Әйдәгез, Шүрәлегә ярдәм итәбез.<br>- Болар нәрсәләр? ***(тактага эленә)*** | ***ТАТАРСТАН*** (укучылар җавабы)<br><br>- Туган як, Татарстан турында.<br>- Татарстан - безнең туган ягыбыз. (укучылар җавабы)<br><br>- Әкият герое.<br>- Шүрәле әкиятеннән. | **ТБУУГ**: Сүзләр ярдәмендә дәреснең темасын ачу.<br>**РУУГ**: күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу.<br>**КУУГ**: тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү.** | - Ә өйләрдә нәрсә сурәтләнгән?<br>- Дөрес, укучылар! Ә хәзер, әйдәгез, өстәлдә яткан сүзләрне дөрес итеп өйләргә урнаштырыйк!<br>***1нче өй.***Казан, Алабуга, Яр Чаллы, Әлмәт, Минзәлә, Түбән Кама.<br>***2нче өй.*** Идел, Кама, Агыйдел, Нократ.<br>***3нче өй.*** Төлке, аю, бүре, куян, тиен.<br>**Нәтиҗә. Бу елгалар, шәһәрләр кайда урнашкан?**<br>**Ә Татарстан- безнең туган ягыбыз. Яхшы, укучылар, сез булдырдыгыз!**<br>Шүрәленен беренче биремен үтәдек. Азрак ял итеп тә алыйк.<br>**2.Физкультминутка.**<br>Кара әле, үскәнем, ничек куян сикерә?!<br>Менә шулай, менә шулай, шулай куян сикерә!<br>Кара әле, үскәнем, ничек йөри аюлар?!<br>Менә шулай, менә шулай, шулай йөри аюлар!<br>Кара әле, үскәнем, ничек кошлар очалар?!<br>Менә шулай, менә шулай, шулай кошлар очалар!<br>**3.** Дәреслек белән эш. 106 нчы бит, 9 нчы күнегү.<br>Эшне төркемнәрдә эшлиләр.<br>- Где он живет?<br>- Есть ли в Татарстане леса?<br>- Какие реки есть в Татарстане?<br>- Ты любишь свой родной край?<br><br>- Миша, син дә туган ягыңны яратасыңмы?<br>- Айдар, син дә туган ягыңны яратасыңмы?<br>Нәтиҗә. Әйе, укучылар, мин дә туган ягымны яратам. Чөнки ул - безнең өй. Без туган ягыбызны яратырга, сакларга тиешбез. | - Әкиятне Г.Тукай язган.<br>- Габдулла Тукай безнең бөек шагыйребез.<br><br>- Өйләр!<br>-Шәһәр, елга, хайваннар.<br>***(Укучылар тиешле сүзләрне тиешле өйләргә урнаштыралар.)***<br><br>***1нче өй.***Казан, Алабуга, Яр Чаллы, Әлмәт, Минзәлә, Түбән Кама.<br>***2нче өй.*** Идел, Кама, Агыйдел, Нократ.<br>***3нче өй.*** Төлке, аю, бүре, куян, тиен.<br><br>- Татарстанда.<br><br>Укучылар бу биремне дәфтәрләрендә үтиләр. Аннары басып җавап бирәләр. | **РУУГ**: кагыйдә, инструкцияләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.<br><br>**ТБУУГ**: уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү.<br><br>**РУУГ**: үзрегуляция. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Диалогик сөйләм күнекмәләрен камил-ләштерү.** | **4.** Укучылар, хәзер Шүрәленең икенче биремен үтибез. Һәр төркемгә рәсемнәр өләшәм.<br><br>1нче төркем - шәһәрләрне, 2нче төркем - елгалар-ны, 3нче төркем,– хайванннарны табып, карталар-га ябыштырырга тиешләр.<br>-Укучылар, ә без кайсы шәһәрдә яшибез?!<br>- Ә Казан нинди шәһәр?<br>- Ә безнең Казанда нинди елга ага?<br>- Идел нинди елга?<br>- Ә урманнарыбызда нинди хайваннар яшиләр?<br>-Укучылар, шәһәрләр, елгалар, урманнар чиста булсын өчен, без нишләргә тиеш?<br>-Әйе, укучылар безнең 2017нче ел - экология елы. Безнең бурычыбыз шәһәрләрне, елгаларны, ур-маннарны пычратмау. Сез табигать турында онытмас өчен, Шүрәле сезгә кечкенә генә бүләкләр алып килгән.(*эмблемалар тагып чыгам*) | - Син кайда яшисең?<br>- Татарстанда урманнар бармы?<br>- Татарстанда нинди елгалар бар?!<br>- Син туган ягыңны яратасыңмы?<br><br>- - Әйе, мин туган ягымны яратам.<br><br>Укучылар төркемнәрдә эшлиләр. Аннары такта янына чыгып сөй-лиләр.<br><br>**1НЧЕ ТӨРКЕМ.**<br>- Татарстанда Казан, Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре бар! Без Казан шәһәрендә яшибез. Казан - чиста, матур, зур шәһәр.<br><br>**2НЧЕ ТӨРКЕМ.**<br>- Татарстанда Идел, Кама, Нократ, Агыйдел елгалары бар. Ә Казанда Идел елгасы ага. Идел – зур, матур, чиста елга.<br><br>**3НЧЕ ТӨРКЕМ.**<br>- Урманнарда аюлар, бүреләр, төлкеләр, пошилар, куяннар, тиен-нәр яшиләр. | **Предмет буенча**: сүзләрне аңлап, диалог төзи белү.<br>**РУУГ:** башкаларның сөйләмен аңлау, үз эшчән-лекләрен планлаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | - Шәһәрләрне, елгаларны, урманнарны пычратмаска, чүп ташламаска. | |
| **Уку эшчәнлеген йомгаклау. Рефлексия.**<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>**Индивидуаль рефлексия.**<br><br><br><br><br><br><br>**Өй эше.** | Укучылар, без дәрестә нәрсә турында сөйләштек? Хәзер мине игътибар белән тыңлыйсыз! Әгәр сез килешсәгез басасыз, килешмисез икән урында каласыз!<br><br>- Дәрестә шәһәрләр, елгалар, хайваннар турында сөйләштек.<br>- Дәрестә без уйнадык.<br>- Дәрестә йокладык.<br>- Татарстан турында сөйләштек.<br>- Дәрестә туган якны саклау турында сөйләштек.<br>**5.СЛАЙД.**<br><br>Укучылар, мин сезгә дәрес башында бәяләү критерийларын тараткан идем. Хәзер әйдәгез һәрберегез үзегезгә бәя бирегез.<br>Укучылар, кем үзенә бишле куйды, мин сезгә 1нче өй эшен тәкъдим итәм. Кем “4”ле билгесе куйды, аларга мин 2нче өй эшен тәкъдим итәм. Ә кем инде үзенә “3”ле билгесен куйды, аларга мин 3нче өй эшен тәкъдим итәм.<br>**6. СЛАЙД.**<br>1.Туган як турында 3 җөмлә язарга.<br>2.Туган як темасына рәсем ясарга.<br>3. 7 нче күнегү, 106 нчы бит. | <br><br><br><br><br><br><br>басалар<br><br>басалар<br><br>урында калалар<br><br>басалар<br><br>басалар<br><br><br><br><br>Укучылар үзләренә билге куялар.<br><br><br><br>Өй эше биременең аңлашылып бетмәгән урыннарын ачыклыйлар, язып куялар. | **КУУГ**: күршең белән хезмәттәшлек итү.<br><br>**ШУУГ**: үз уңышларың уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү.<br><br>**ТБУУГ:** фикерне аңлы һәм ирекле рәвештә телдән әйтеп бирү.<br><br>**КУУГ**: әңгәмәдә катнашу, фикерләреңне дәлилли белү.<br><br>**РУУГ:** бәяләү, хаталарны табып төзәтү.<br><br><br><br><br><br><br><br>**ТБУУГ**: белем дәрәҗәсеннән чыгып өй эшен сайлап алу.<br>**РУУГ**: аңлау, эшчәнлекне оештыра белү (өйдә). |

## Эчтәлек

**Шәмсетдинова Р. Р., Зиннәтуллин Р. К.** ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЗАМАНЧА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР..............................3

**Абдулбариева Т. А.** В.Н. МЕЩЕРЯКОВА АВТОРЛЫК ПРОГРАММАСЫ НИГЕЗЕНДӘ УКЫТУ ....................................................................................13

**Галиева З. Ш.** ЯШЕЛЧӘЛӘР. КИРӘК. КИРӘКМИ СҮЗЛӘРЕ .................................16

**Бикмөхәмәтова Л. З.** БОЕРЫК ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ӘЙТЕЛЕШЕ ҺӘМ АНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ........................................................................20

**Гаязова Ф. К.** ҖИЛӘК-ҖИМЕШ, ЯШЕЛЧӘЛӘР. ТАРТЫМ КУШЫМЧАЛАРЫН СӨЙЛӘМДӘ КУЛЛАНУ...........................................................26

**Габделбариева Т. А.** "СИНЕҢ... ? МИНЕМ..." ТӨЗЕЛМӘСЕ. -МЫ, -МЕ СОРАУ КИСӘКЧӘЛӘРЕН СӨЙЛӘМДӘ КУЛЛАНУ ..................................................30

**Зарипова Л. Ф**. МИНЕМ, СИНЕҢ, АНЫҢ АЛМАШЛЫКЛАРЫН КУЛЛАНУНЫ СӨЙЛӘМДӘ НЫГЫТУ ..........................................................34

**Бәхтиев Р. Ф., Якупов Р. Н., Маркова Э. М.** "СӘЛАМ" УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКТЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ......................................................37

**Кашафетдинова Г. В**. "ШӘҺӘР. АВЫЛ" ТЕМАСЫНА 1НЧЕ ДӘРЕС .....................40

**Хәмидуллина Л. С**. СЫЙНЫФТАН ТЫШ УКУ. АБДУЛЛА АЛИШ ӘКИЯТЕ. УТЛЫ ЙОМЫРКА..........................................................................45

**Денисова Г. Р**. ЗАТ АЛМАШЛЫКЛАРЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ. КИЛЕШЛӘР БЕЛӘН ТӨРЛӘНЕШЕ ....................................................................50

**Галиева Г. Ш**. ТӘРТИП САНЫ ..........................................................57

**Кадыйрова Л. Ә**. ТАМЫР ҺӘМ КУШЫМЧАЛАР........................................61

ЭНДӘШ СҮЗСЕЗ ЭШ КӨЙСЕЗ. ЭНДӘШ СҮЗЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ
**Гобәйдуллина З. Р**. ҖӨМЛӘДӘГЕ УРЫНЫ, АЛАР ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ.....................................................................................66

**Нәфыйкова А. Р**. МИКЪДАР САНЫ. ТӘРТИП САНЫ.................................70

**Тарханова Г. И**. ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЕ БУЕНЧА ФДББС ТАЛӘПЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНЕП ТӨЗЕЛГӘН ТЕХНОЛОГИК КАРТА .....................73

**Арсланова Ә. Д., Ханнанова М. Х.** ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН СЫЙФАТ ФИГЫЛЬ ..........83

**Касыймова Э. Р., Андреева Е. В.** ТАТАРСТАН – МИНЕМ ТУГАН ЯГЫМ............88

**ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНӘ**

**ЗАМАН ТАЛӘБЕ**

Форм. бум. 60х84 1/16. Гарнитура Times.
Усл.печ.л. 5,9

Печатается в авторской редакции

Институт развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
Сайт: irort.ru e-mail: irort2011@gmail.com